# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2024 4 (44)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

*Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т.,
СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА


### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Хөсәинова А.Я.* Татар теленең урта диалектында дорсаль тартыкларның кулланылыш үзенчәлекләре. . . . . . . . . 7

*Гыйлемшин Ф.Ф., Гыйлемшина А.Г.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар теленә тәрҗемә ителгән кыйсса жанрындагы әсәрләрдә соматизмнарның кулланылыш үзенчәлекләре *(«Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир», «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә» һәм «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрләре мисалында)* . . . . . . . . . . .15

*Сәфәров Р.Т.* Бастырылмаган «Русча-татарча хәрби сүзлек» . . . .23

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Абдуллина Д.М.* Аһ, туган каумем газиз... *(Татар әдәбияты классигы Дәрдемәнднең тууына 165 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .31

*Сәлахова Э.К.* Г. Исхакый һәм аның замандашлары публицистикасында милләтне саклау проблемалары . . . . . . . .42

*Бәдретдинов Р.Ф.* Язучы Афзал Таһировның «Солдатлар» романы: проблематикасы, үзенчәлекләре һәм әдәбият тарихындагы урыны .51

*Заһидуллина Д.Ф.* Әмирхан Еники прозасы: поэтик ачышлар . . .60

*Миңнуллина Ф.Х.* 1950 еллар татар драматургиясендә заман һәм герой *(Н. Исәнбәт, Г. Насрый, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов иҗатлары мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . .65

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Брусько З.М.* Киндер чәчсәң, күлмәк киярсең... *Татар халкының киндер эшкәртү өмәләрен фольклор яссылыгында тикшерү* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .73

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Зәкиева Р.Г.* Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оешуга 30 ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .82

*Хәлиуллин И.Х.* Тарихи хәтер: асылы, формалары, структурасы, татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә чагылышы, язмышы . . . . .89

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Гыйниятуллина Л.М., Мөхәрләмова Г.Н.* Туган (татар) телне һәм әдәбиятны укыту барышын цифрлаштыру . . . . . . . . . . .96

*Шәкүрова М.М.* Укырга-язарга өйрәтүдә Г. Ибраһимовның методик системасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

### СӘНГАТЬ

*Хәбетдинова М.М., Миндиәрова Ә.Р.* Татар әдәбияты һәм сәхнәсендә С. Гыйззәтуллина-Волжская образы . . . . . . . 108

*Горюнова Н.М.* Лениногорск шәһәрендәге скульптуралар . . . . 117
*Джумаева Ф.Ш.* Ибн Фадлан «Язмалар»ындагы сюжетларның хәзерге заман Татарстан нәкышендә чагылышы . . . . . . . . . . 125
*Умәров Д.И.* Урта Идел Буе татарлары хореографик фольклорының җирле үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

**ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Закирова И.Г., Гыйлемҗанова Г.Г.* Татар музыкасы һәм фольклор белгече Илгиз Кадыйровка 85 яшь . . . . . . . . . 139
*Гарипова Л.Ш., Булатова Ә.К.* Мордовия Республикасы татар авылларына фәнни сәфәр нәтиҗәләреннән . . . . . . . . . . . . . 143

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Насипов И.С.* Мәшһүр галим, күренекле язучы һәм олуг шәхес *(С.Ш. Поварисовның тууына 100 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . 153
*Габидуллина Ф.И.* Гадилек һәм галимлек үрнәге *(Ә.М. Закирҗановның 65 яшьлек юбилее уңаеннан)* . . . . . . . . 159

**ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР**

*Гали Рәхим.* Әш-шәркыять. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Пудакова О.В.* «Татарский костюм. Российский этнографический музей» альбом-каталогына рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . 176

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Хусаинова А.Я.* Особенности употребления дорсальных согласных в среднем диалекте татарского языка . . . . . . . . . . . 7
*Гилемшин Ф.Ф., Гилемшина А.Г.* Особенности использования соматизмов в произведениях жанра кысса, переведенных на татарский язык в конце XIX – нач. XX века *(на материале произведений «Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир», «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә» һәм «Әбүгалисина кыйссасы»)* . 15
*Сафаров Р.Т.* Неопубликованный «Русско-татарский военный словарь» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .23

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Абдуллина Д.М.* О, мой народ, как ты дорог мне! *(к 165-летию со дня рождения татарского литературного деятеля Дэрдменда)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .31
*Салахова Э.К.* Проблема сохранения идентичности в публицистике Г. Исхаки и его современников . . . . . . . . . . .42
*Бадретдинов Р.Ф.* Роман «Солдаты» Афзала Тагирова: проблематика, особенности и место в истории татарской литературы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .51
*Загидуллина Д.Ф.* Проза Амирхана Еники: поэтические особенности . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .60
*Миннуллина Ф.Х.* Татарская драматургия 1950-х годов: эпоха и герой *(на примере творчества Н. Исанбета, Г. Насрыя, Ю. Аминова, Ш. Хусаинова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .65

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Брусько З.М.* Помочи по переработке конопли у татар как объект фольклорного исследования . . . . . . . . . . . . . . .73

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Закиева Р.Г.* 30 лет со дня образования Института татарской энциклопедии и регионоведения . . . . . . . . . . . . . . . . . .82
*Халиуллин И.Х.* Историческая память: суть, формы, структура, отражение в произведениях татарского устного народного творчества, судьба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .89

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Гиниятуллина Л.М., Мухарлямова Г.Н.* Цифровизация процесса обучения родному (татарскому) языку и литературе. . . . . . . . .96
*Шакурова М.М.* Методические системы обучения грамоте Г. Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

## ИСКУССТВО

*Хабутдинова М.М., Миндиярова А.Р.* Образ С. Гиззатуллиной-Волжской в татарской литературе и на сцене . . . . . . . . . . . 108
*Горюнова Н.М.* Скульптура Лениногорска . . . . . . . . . . . . . . 117
*Джумаева Ф.Ш.* Отражение сюжетов «Записок» Ибн Фадлана в современной живописи Татарстана . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
*Умеров Д.И.* Локальные особенности хореографического фольклора татар Среднего Поволжья . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Закирова И.Г., Гилемьянова Г.Г.* К 85-летию этномузыковеда Ильгиза Кадыйрова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
*Гарипова Л.Ш., Булатова Ә.К.* Материалы по комплексной научной экспедиции в Республику Мордовия . . . . . . . . . . . 143

## ПЕРСОНАЛИИ

*Насипов И.С.* Известный ученый, писатель и личность *(к 100-летию со дня рождения С.Ш. Поварисова)*. . . . . . . . . 153
*Габидуллина Ф.И.* В нём просвещенья дух благородный... *(к 65-летию А.М. Закирзянова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Гали Рахим.* Аш-шаркиййат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## НОВЫЕ КНИГИ

*Пудакова О.В.* Рецензия на альбом-каталог «Татарский костюм. Российский этнографический музей» . . . . . . . . . . . . . . . . 176

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***А.Я. Хөсәинова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ УРТА ДИАЛЕКТЫНДА ДОРСАЛЬ ТАРТЫКЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В данной статье рассматриваются особенности употребления дорсальных согласных – велярных /k/, /g/, /x/, /ŋ/ и увулярных /q/, /ʁ/, /χ/, /N/, в среднем диалекте татарского языка. Специфика использования заднеязычных и глубокозаднеязычных согласных исследуется на материалах, собранных авторами во время комплексных экспедиций и из диалектных словарей татарского языка. Проводится сравнительный анализ использования данных согласных в говорах среднего диалекта татарского языка с татарским литературным языком и другими диалектами татарского национального языка.

**Ключевые слова:** дорсальные согласные, велярные консонанты, увулярные консонанты, средний диалект татарского языка, фонетические чередования, диалектная фонетика.

This article discusses the features of the use of dorsal consonants – velar /k/, /g/, /x/, /ŋ/ and uvular /q/, /ʁ/, /χ/, /N/, in the middle dialect of the Tatar language. The specifics of the use of back-lingual and deep-Western consonants are studied on the materials collected by the authors during complex expeditions and from dialect dictionaries of the Tatar language. A comparative analysis of the use of these consonants in the dialects of the middle dialect of the Tatar language with the Tatar literary language and other dialects of the Tatar national language is carried out.

**Keywords:** dorsal consonants, velar consonants, uvular consonants, middle dialect of the Tatar language, phonetic alternations, dialect phonetics.

Диалектларны бербөтен система буларак өйрәнү; аларны лингвистик география объекты буларак тасвирлау, генетик һәм структур планда чагыштырма анализлау; татар теленең диалект системасы үсешенең эчке закончалыкларын билгеләү; аларның үсешенә йогынты ясаган экстралингвистик факторларны ачыклау һәм ареаль лингвистика күзлегеннән өйрәнү кебек мәсьәләләр хәзерге татар диалектологиясенең актуаль проблемалары булып тора.

Ареаль лингвистика методлары ярдәмендә экстралингвистик сәбәпләр контекстында, телнең башка формалары кебек үк, диалектларны да катлаулы һәм каршылыклы система буларак өйрәнергә мөмкин. Телнең тотрыклы катламын – авазлар системасын ареаль аспектта өйрәнү тел һәм халык тарихына кагылышлы күп кенә мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итә. Һәр татар диалектының һәм сөйләшенең тел күренешләре үзенчәлеген аңлату тел системасын тәшкил иткән барлык структур элементларны анализлауны сорый. Татар әдәби теленә һәм аның сөйләшләренә хас тартыклар татар милли телен тасвирлаганда

кулланыла торган элементларның берсе булып тора. Авазлар системасын чагыштырма планда өйрәнү аларның гомуми һәм төрле билгеләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Әлеге тикшеренү кысаларында татар теленең урта диалекты сөйләшләрендә тел арты һәм увуляр тартыкларның кулланылыш үзенчәлекләре каралды. Мисаллар авторның кыр методы белән җыелган материалларыннан, шулай ук татар теленең диалектологик сүзлекләреннән алынды.

Татар телендәге /k/, /g/, /x/ тел арты тартыкларының артикуляциясе, рус телендәге калын /$k^j$/, /$g^j$/, /$x^j$/ авазлары белән чагыштырганда, алдарак урын ала, әмма йомшак авазлар позициясенә кадәр барып җитми [Шараф, 1927, с. 86–87]. Шулай итеп, татар телендәге /k/, /g/, /x/ тел арты тартыклары, рус телендәгедән аермалы буларак, каты һәм йомшак аңкау чигендә ясалалар.

/k/ авазы – шаулы, йомык, веляр шартлаулы саңгырау тартык. Позиция ягыннан чикләнмәгән. Сузыктан башланган аффикслар кушылганда яңгыраулаша, бу орфографиядә чагыла, мәсәлән, *barak* «барак» – *baragɯ* «его барак». Язуда *к* хәрефе белән билгеләнә.

Татар теленең касыйм сөйләшендә барлык позицияләрдә /k/ авазын йомык бугаз тартыгы белән алыштыру – хәзерге төрки телләрнең берсендә дә күзәтелми торган күренеш. Кайбер галимнәр фикеренчә, касыйм сөйләше тарихында зур роль уйнаган фин-угор субстраты йогынтысы /k/ авазының төшеп калу очраклары касыйм сөйләше белән генә чикләнми һәм, аерым алганда, «Kitäb al-idräk» мәмлүк-кыпчак сүзлегендә теркәлгән [Щербак, 1970, с. 168].

Тюркологиядә электән касыйм сөйләшендә тел арты /k/ авазы бөтенләй юк, дигән фикер бар. Л.Т. Мәхмүтова аның дөрес түгеллеген дәлилли. Беренчедән, ул күпчелек рус алынмаларында сакланып калган: *saruɕka* < «сорочка», *kaluşa* < «калоши», *kælitkæ* < «калитка», *znæweskæ* < «занавес», *əskæmikæ* < «скамейка», *kænʏşnæ* < «конюшня», *əstækæn* < «стакан», *malatuk* < «молоток» һ. б. Икенчедән, бу аваз гарәп һәм фарсы чыгышлы кайбер сүзләрдә дә кулланыла: *$n^j$ikah,* орф. никах «брак»; *qaber,* орф. кабер «могила»; *kæfen,* орф. кәфен «саван»; *fæqr,* орф. фәкыйрь «бедняк» һ. б. [Махмутова, 1955, с. 154]. Өченчедән, татар әдәби теле, күрше төбәкләрдә таралган татар сөйләшләре, шулай ук рус теле йогынтысында хәтта сөйләшнең үз сүзләрендә, бигрәк тә яшьләр һәм урта буын кешеләре телендә, ул яңадан торгызыла: *kanat,* орф. канат «крыло»; *siker,* орф. сикер «прыгай»; *ike,* орф. ике «два»; *ɕerekæj,* орф. чирки «комар»; *kʏl,* орф. күл «озеро» һ. б.

/g/ авазы – шаулы, йомык, веляр, яңгырау тартык. Позиция ягыннан чикләнмәгән. Язуда *г* хәрефе белән билгеләнә.

Тел арты йомык /g-/ авазы угыз анлаутына хас һәм, кайбер галимнәр фикеренчә, бабатөрки яки борынгы бабатөрки халәтенә кадәр реконструкцияләнә [Сравнительно-историческая грамматика..., 2006, с. 67], баба кыпчак анлаутында кулланылмаган [Сравнительно-

историческая грамматика..., 2006, с. 276]. Татар, башкорт телләрендәге сүзләр һәм аваз ияртемнәренең чикләнгән саны өчен хас: *güδäl*/ *gʏzæl,* төр. диал. *gözen* < **güŕel* «матур, матурлык, яраткан (красивый, красота, любимая)»; *giδ-/giz-* < **geŕ-* «йөрергә, аша узарга (ходить, проходить через)» [Сөләйманова, 2016, б. 213].

Урта диалектның кайбер сөйләшләрендә, мәсәлән, касыйм, әстерхан, тепәкәй һ. б., ул алынма сүзләрдә очрый: *gerep* < «гриб» – тат. әд. *gømbæ,* орф. гөмбә; *gʏrşi* < «горшок» – тат. әд. *ɕʏlmæk*, орф. чүлмәк; *lægʏşkæ* < «лягушка» – тат. әд. *baqa,* орф. бака; *gel* – тат. әд. *gøl*, орф. гөл «цветок» һ. б.

/x/ авазы – шаулы, өрелмәле, саңгырау веляр спирант. Позиция ягыннан чикләнмәгән. Язуда *х* хәрефе белән күрсәтелә.

Борынгы татар теле һәм аның диалектлары өчен тел арты саңгырау /x/ авазы хас булмаган. Хәзерге татар сөйләшләрендә бу аваз әлегә кадәр тулысынча үзләштерелмәгән. Мондый очракларда ул әйтелеш формасы буенча якын булган тел арты яки тирән тел арты саңгырау /q/ /k/ белән алыштырыла. Әлеге күренеш төрле дәрәҗәдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә күзәтелә. Аеруча казан арты сөйләшләр төркемендә еш очрый. Бу сөйләшләр төркеменнән тыш ул пермь, нократ һ. б. сөйләшләр өчен дә хас. Көнбатыш Себер ареалындагы татар сөйләшләрендә бу үзенчәлек системалы характерга ия. Минзәлә һәм бөре сөйләшләрендә әлеге күренеш аерым сүзләрдә күзәтелә: *jomaq* – тат. әд. *ojmax*, орф. оҗмах; *aqiræt* – тат. әд. *axiræt,* орф. ахирәт, *køkømæt* – тат. әд. *xøkømæt*, орф. хөкүмәт; *qut͡sa* – тат. әд. *xuʒa*, орф. хуҗа; *qatɯn* – тат. әд. *xatɯn*, орф. хатын. *bu qatɯn bik zaʁar* (зәһәр) *ʒɯrɯʁan* (җырларга яратучан). – Бу хатын җырларга бик яратучы (түбән кама керәшен татарлары сөйләше). *qatɯnɯ ket͡sʏt͡sæk ære zor* – Хатыны кечкенә генә, ире зур (бараба диалекты), *qatɯnɯŋ belæn jaqşɯ sʏlæ* – Хатының белән яхшы сөйләш (мәләкәс сөйләше).

Н.А. Баскаков үзенең тикшеренүләрендә, башта тел арты тартыклары мәгънә аеру функциясенә ия булмаган күпсанлы аллофонлы бер фонема белән күрсәтелгән дигән нәтиҗә ясый. Биредә төп фонема итеп /k/ авазы бирелә, ә аның аллофоннары сыйфатында түбәндәге тартыклар санап үтелә: /g/, /q/, /γ/, /x/ һ. б. Консонантлар системаның үсеше процессында әлеге авазлар мөстәкыйль мәгънә аеручы фонемаларга әверелә. Н.А. Баскаков /*x*/ аллофоны төрки телләрдә тартыклар үсешенең баштагы чорларында, ә /q/ аллофоны соңрак чорларында мөстәкыйль фонемага бүленеп чыга дигән нәтиҗәгә килә [Баскаков, 1988, с. 106].

/ŋ/ авазы – йомык, борын, веляр, сонант. Татар сүзләрендә сүз башы позициясендә сирәк очрый, ягъни төрки анлаутка хас түгел. Орфографиядә *ң* хәрефе белән билгеләнә.

Галимнәр билгеләгәнчә, хәзерге татар телендә /n/ авазы /k/, /q/, /g/, /ʁ/ алдында /ŋ/ га кучә [Татарская грамматика 1995, с. 91]. Мәсәлән, *æŋkæj* – тат. әд. *ænkæj,* орф. әнкәй; *isæŋgeræ* – тат. әд. *isææn-geræʏ,* орф. исәнгерәү һ. б.

Урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә палатальләшкән тел арты /ŋ/ алгы рәт сузыклар булган сүзләрдә очрый: *iŋ,* орф. иң; *tiŋ,* орф. тиң; *kiŋæş,* орф. киңәш һ. б. Кайбер очракларда, мәсәлән, тел арты тартыклары белән янәшә килгәндә, тел арты /ŋ/ авазының палатальләшмәгән варианты (увуляр *N* белән беррәттән) да кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *qabaŋ kʏlɛ,* орф. Кабан күле «озеро Кабан». Биредә тел алды /n/ регрессив ассимиляциягә дучар була.

Татар телендә увуляр авазлар язуда тел арты авазлары белән бер үк хәрефләр белән билгеләнә. Гадәттә әлеге авазлар арткы рәт сузыклары белән янәшә әйтелә, ләкин гарәп алынмаларында алгы рәт сузыклары белән янәшә дә кулланылырга мөмкин: бу очракта сузык бераз арткы рәткә этәрелә.

/ʁ/ һәм /q/ тирән тел арты тартыкларын куллану урта дилектның барлык сөйләшләренә хас күренеш. Казан арты сөйләшләре төркемендә ул үзенең системалылыгын саклый.

/q/ авазы – шаулы, йомык, увуляр саңгырау. Позиция ягыннан чикләнмәгән. Сузыкка башланган аффикс алдындагы позициядә яңгыраулаша, мәсәлән, *qabaq,* орф. кабак – *qabagɯm,* орф. кабагым. Язуда *к* хәрефе белән бирелә.

К.М. Мусаев фикеренчә, /k/ ~ /q/, /g/ ~ /ɣ/ фонемаларының фонологик статусы мәсьәләсе тюркологиядә иң бәхәслеләрнең берсе, тел арты /q/ башка телләр йогынтысына дучар булган изоляцияләнгән телләрдә һәм диалектларда сакланмаган [Сравнительно-историческая грамматика, 2002, с. 278]. «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков» (Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы) авторлары тарафыннан гуттураль /q/ борынгы төрки бергәлек таркалу чорында торгызыла [Сравнительно-историческая грамматика..., 2006]. Татар һәм башкорт телләрендә ул, кагыйдә буларак, арткы рәт сузыклары булган сүзләрдә кулланыла [Сөләйманова, 2016, б. 210].

Палатальләшкән /q/ варианты увуляр, йомык, саңгырау тартык булып тора, ләкин палатальләшмәгән тартыктан аермалы буларак, бераз алга китә, моны эксперименталь мәгълүматлар дәлилли [Байчура, 1959, б. 129].

/q/ ~ /χ/ чиратлашуы дөбьяз, лаеш, нурлат һ. б. сөйләшләрдә күзәтелә: *qatɯn* – тат. әд. *χatɯn,* орф. хатын; *patɯjq* – тат. әд. *fatɯjχ,* орф. Фатыйх; *qædiʙæ* – тат. әд. *χædiʙæ,* орф. Хәдичә (кеше исемнәре) һ. б.

Алынмаларда /χ/ ~ /q//k/ чиратлашуы күзәтелә: *waχɯt* – тат. әд. *waqɯt,* орф. вакыт «время»; *χædære* – тат. әд. *qadær,* орф. кадәр «до»; *teræχter* – тат. әд. *traktor,* орф. трактор «трактор»; *χælχuz* / χalχuz – тат. әд. *kolχoz,* орф. колхоз «колхоз».

Бастан сөйләшендә иҗек ахырындагы /q/ авазы еш кына /qχ/ тезмәсе белән алыштырыла: *toqχta* – тат. әд. *tuqta,* орф. тукта; *oqχta* – тат. әд. *uqɯta,* орф. укыта; *baqχsa* – тат. әд. *baqʙa,* орф. бакча; *joqχla* – тат. әд. *joqla,* орф. йокла һ. б.

/ʁ/ авазы – шаулы, өрелмәле, яңгырау увуляр спирант. Татар сүзләрендә сүз уртасында килә, мәсәлән, *suʁan,* орф. суган. Сүз башында гарәп алынмаларында очрый, мәсәлән, *ʁomɛr,* орф. гомер. Сүз ахырында саңгыраулаша, ләкин сузыктан башланган аффикс кушылганда, саңгырау тартык белән чиратлаша, бу орфографиядә чагыла, мәсәлән: *sɯk,* орф. сык – *sɯʁam,* орф. сыгам. Язуда *г* хәрефе белән күрсәтелә.

Татар әдәби теленнән аермалы буларак, тирән тел арты /ʁ/ авазы арткырак артикуляция вакытында барлыкка килә: *qarʁa,* орф. карга; *qabaq* орф. кабак; *qudɯru,* орф. кудыру һ. б.

/χ/ авазы – шаулы, өрелмәле, фарингаль саңгырау увуляр фрикатив. Борынгы татар сүзләрендә, гарәп алынмаларында очрый, мәсәлән, *χatɯn,* орф. хатын; *χolɯk,* орф. холык һ. б. Язуда *х* хәрефе белән билгеләнә.

Урта диалект сөйләшләрендә системалы рәвештә /χ/ ~ /h/ чиратлашуы күзәтелә: *χæm* – тат. әд. *hæm,* орф. һәм; *χawa* – тат. әд. *hawa,* орф. һава; *χiɕ* – тат. әд. *hiɕ,* орф. һич; *χær* – тат. әд. *hær,* орф. һәр «каждый»; *zæχær* – тат. әд. *zæhær,* орф. зәһәр; *ʂæχær* – тат. әд. *ʂæhær,* орф. шәһәр һ. б.

/N/ авазы – увуляр борын сонанты. Галим Ү.Ш. Байчура ясаган палатограммалар увуляр /N/ авазы артикуляциясенең фокусы палатальләшмәгән /q/ һәм /ʁ/ артикуляциясе булган урында икәнен күрсәтә. Рентген сурәтләрендә һәм схемаларда /N/ авазын әйткәндә йомылган урынның алгы чигенең, тел арты палатальләшмәгән /k/ авазын әйткәндәгегә караганда, түбәнрәк урнашканлыгы күренә [Байчура, 1959, б. 135]. Язуда *ң* хәрефе белән билгеләнә.

Башка увуляр тартыклар кебек үк, /N/ авазы арткы рәт сузыклары булган сүзләрдә дә әйтелә: *aN,* орф. аң; *soN,* орф. соң, *aNqau,* орф. аңкау; *maNʁaj,* орф. маңгай һ. б. Ул, аның алга этәрелгән /ŋ/ варианты кебек үк, анлаутта очрамый, ягъни әлеге авазның фонетик позицияләре бераз чикләнгән.

/n/ ~ /N/ чиратлашуы: *an* – тат. әд. *aN,* орф. аң; *qɯzɯmnɯn* – тат. әд. *qɯzɯmnɯN,* орф. кызымның; *barasɯn* – тат. әд. *barasɯN,* орф. барасың, *suʁasɯn* – тат. әд. *suʁasɯN,* орф. сугасың; *ʒin'ɛl* – тат. әд. *ʒiNɛl,* орф. җиңел, *'ɛn'ɛl* – тат. әд. *kʏNɛl,* орф. күңел; *ʒan'ɯ* – тат. әд. *jNa,* орф. яңа; *ʒan'ɯlɯɯ* – тат. әд. *jalʁɯʂ,* орф. ялгыш һ. б.

Гомуми төрки ареалына таралган булуына карамастан, төрки телләрдә /N/ авазының төрле дәрәҗәдә кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән, ул чуваш һәм якут телләренә хас түгел.

Татар теленең урта диалект сөйләшләрендә югарыда карап киткән авазларның түбәндәге чиратлашулары күзәтелә:

/n/ ~ /ŋ/: *ʒin* – тат. әд. *ʒiN,* орф. җиң; *mɛn* – тат. әд. *mɛN,* орф. мең; *kin* – тат. әд. *kiŋ,* орф. киң; *mina* – тат. әд. *miNa,* орф. миңа; *tan* – тат. әд. *taN,* орф. таң; *sinɛn* – тат. әд. *sinɛŋ,* орф. синең; *kɛmnɛn* – тат. әд. *kɛmnɛŋ,* орф. кемнең; *sizæsɛn* – тат. әд. *sizæsɛŋ,* орф. сизәсең; *kʏrgænsɛn* – тат. әд. *kʏrgænsɛŋ,* орф. күргәнсең һ. б. Бу күренеш дөбьяз сөйләшендә системалы характерга ия, биредә /N/ авазын куллану

шактый чикләнгән. Әлеге яктан аңа /N/ авазы бөтенләй кулланылмаган касыйм сөйләше якын.

/n/ ~ /ŋ/ чиратлашуы балтач сөйләшендә очрый: *babasɯnɯn* – тат. әд. *babasɯnɯN,* орф. бабасының; *bɛznɛn* – тат. әд. *bɛznɛŋ,* орф. безнең; *tøjœsɛn* – тат. әд. *tøjœsɛŋ,* орф. төясең; *una* – тат. әд. *aNa,* орф. аңа һ. б.

Тамырлар ахырында /n/, /ŋ/ авазларының комбинатор чиратлашуы шулай ук түбәндәге тиңдәшлекләрдә күзәтелә: *siŋ kɛm* – тат. әд. *sin kɛm,* орф. син кем?; *tøŋgœ* – тат. әд. *tøn* + афф. *gœ,* орф. төнге һ. б. [Байчура, 1959, б. 135].

Тартыкларның позиция үзгәрешләре аларның сүздәге торышына бәйле. Мәсәлән, /m/, /n/, /l/, /r/, /N/ сонор авазларыннан соң килгән /g/, /ʁ/ һәм /d/ авазлары саңгыраулаша:

*mq, mk: suʁɯmqa* – тат. әд. *suʁɯmʁa,* орф. сугымга; *qomqan* – тат. әд. *qomʁan,* орф. комган; *jamqɯr* < *jamʁɯr* – тат. әд. *jaNʁɯr,* орф. яңгыр; *imkœnkœn* – тат. әд. *imgœngœn,* орф. имгәнгән һ. б.

*Nq, Nk: sɯNqan* – тат. әд. *sɯnʁan* орф. сынган; *urmaNqa* – тат. әд. *urmanʁa* орф. урманга; *saNqɯrau* – тат. әд. *saNʁɯrau,* орф. саңгырау; *jalaNqas* – тат. әд. *jalanʁaɕ,* орф. ялангач; *maNqaj* – тат. әд. *maNʁaj,* орф. маңгай; *tøŋkœ* – тат. әд. *tøngɛ,* орф. төнге; *dœŋkœr* – тат. әд. *zœŋʁœr,* орф. зәңгәр; *imœnkœ* – тат. әд. *imœngœ,* орф. имәнгә һ. б.

Соңгы күренеш ике сүз тоташкан урында да күзәтелә: *susaʁan qɯna* – тат. әд. *susaʁan ʁɯna,* орф. сусаган гына һ. б.

Күпчелек сөйләшләргә интервокаль позициядә /g/, /ʁ/ авазларының төшеп калуы хас: *ʒɛrlœʏ / ʒɛgɛrlœʏ* – тат. әд. *ɛrlœʏ,* орф. эрләү, *tɛɛ* – тат. әд. *tɛgɛ* орф. теге; *ɕɯɯr* > *ɕɯr* – тат. әд. *ɕɯʁɯr,* орф. чыгыр; *ʒɯlɯp* – тат. әд. *jɯʁɯlɯp,* орф. егылып; *barmaaNʁa* – тат. әд. *barmaʁaNʁa,* орф. бармаганга; *nijœ* > *nœ* – тат. әд. *nigœ,* орф. нигә; *bʏwɛn* – тат. әд. *bʏgɛn,* орф. бүген; *tʏwɛl* – тат. әд. *tʏgɛl,* орф. түгел; *suwɯʂ* – тат. әд. *suʁɯʂ,* орф. сугыш һ. б.

Түбән Кама керәшен татарлары, тархан сөйләшендә һ. б. сөйләшләрдә /g/ авазы интервокаль позициядә дә төшеп кала: *taɯn* – тат. әд. *tagɯn,* орф. тагын; *tirmœn* – тат. әд. *tɛgɛrmœn,* орф. тегермен; *sœœt* – тат. әд. *sœʁat,* орф. сәгать; *tirmœn* – тат. әд. *tɛgɛrmœn,* орф. тегермән; *ʒoma* – тат. әд. *ʒomʁa,* орф. җомга; *tɛp* / *tɛɛp* – тат. әд. *tɛgɛp,* орф. тегеп; *tʏwœrœk* – тат. әд. *tʏgœrœk,* орф. түгәрәк; *ʒuwaltqan* – тат. әд. *juʁaltкan,* орф. югалткан һ. б.

Шулай ук сүз башында: *œdœt* – тат. әд. *ʁœdœt,* орф. гадәт; *ajɯp* – тат. әд. *ʁæjɛp,* орф. гаеп; *ʏmɛr* – тат. әд. *ʁømør,* орф. гомер «жизнь»; *zaip* – тат. әд. *zœʁijф,* орф. зәгыйфь; *arbɯz* – тат. әд. *qarbɯz,* орф. карбыз; *bajna* – тат. әд. *bajaʁɯnaq,* орф. баягынак һ. б. (пермь, минзәлә һ. б. сөйләшләр).

Гарәп алынмаларында: *azap* – тат. әд. *ʁazap,* орф. газап; *aptulla* – тат. әд. *ʁabdulla,* орф. Габдулла; *aptɯraχman* – тат. әд. *ʁabdraχman,* орф. Габдрахман; *usman* – тат. әд. *ʁosman,* орф. Госман (кеше исемнәре) һ. б.

Урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә (минзәлә, нократ, перьм, златоуст һ. б.) геминантларда (икеләтелгән тартыклар) да дорсаль тартыкларның төшеп калу күренеше күзәтелә:

/kk/ > /k/, /qq/ > /q/: *jørækæjεт* – тат. әд. *jørækkæεт,* орф. йөрәккәем; *эlkε* < *эlεkε* – тат. әд. *эlεkkε,* орф. элекке; *qarɞшqaj* – тат. әд. *qarɞшqqaj,* орф. карчыккай; *aqoʂ* – тат. әд. *aqqoʂ,* орф. аккош; *ɞшqan* – тат. әд. – *ɞшqqan,* орф. чыккан; *qшjтæt* – тат. әд. *qшjттæt,* орф. кыйммәт; *kækγk* – тат. әд. *kækkγk,* орф. кәккүк һ. б.

Урта диалектта дорсаль тартыкларның өстәлү күренеше дә күзәтелә, мәсәлән, /k/, /q/ авазларының өстәлүе (богырыслан, каргалы, минзәлә, эчкен сөйләшләрендә): *kεɞkεnik* – тат. әд. *kεɞkεnæ,* орф. кечкенә; *aqlan* – тат. әд. *alan* орф. алан, *pшʂqшldap* – тат. әд. *pшʂшldap* орф. пышылдап; *qшsqaq* – тат. әд. *qшsqa* орф. кыска; *iɞтasaq*/ *iɞтasaт*/ *iɞтasa* – тат. әд. *iɞтasaт* орф. ичмасам; *taʁшn daq* – тат. әд. *tagшn da* орф. тагын да; *jalʁanɞшq* – тат. әд. *jalʁanɞш* орф. ялганчы) һ. б. Шулай ук /q/, /k/ авазлары кайбер сүзләрдә – рәвешләрдә, бәйлекләрдә, кисәкчәләрдә сүз ахырында өстәлә: *barʁanɞшq* – тат. әд. *barʁanɞш* орф. барганчы; *kilgænɞεk* – тат. әд. *kilgænɞε* орф. килгәнче; *æjtmiɞæk* – тат. әд. æjtmiɞæ орф. эйтмичә; *ɞaqшrтajшnɞшq* – тат. әд. *ɞakшrтшjɞa* орф. чакырмыйча; *soraтшjɞшq* – тат. әд. *soraтшjɞa* орф. сорамыйча; *xædærεk, xætlεk* – тат. әд. *kadær* орф. кадәр; *ʂikεllεk* – тат. әд. *ʂikεllε* орф. шикелле; *kiɞægεnæk* – тат. әд. разг. *kiɞæ gεnæ* орф. кичә генә; *bajaʁшnaq* – тат. әд. *baja ʁшna* орф. бая гына; *ɞшraq* – тат. әд. *ɞшra* орф. чыра; *qшNʁшrawшq* – тат. әд. *kшNгшrau,* орф. кыңгырау; *ɞшqqanɞшq* – тат. әд. *ɞшkkanɞш* орф. чыкканчы; *kilgεnɞæk* – тат. әд. *kilgænɞε* орф. килгәнче; *xætlεk* – тат. әд. *xætlε* орф. хәтле; *xædærlεk* – тат. әд. *qadær* орф. кадәр һ. б. Шулай ук сүзнең башка позициясендә дә өстәлергә мөмкин: *эɞkεтnεk* – тат. әд. *эɞεтlεk* орф. эчемлек; *γrтæklæγ* – тат. әд. *γrтælæγ* орф. үрмәләү; *tulшq* – тат. әд. *tulш* орф. тулы; *sasшq* – тат. әд. *sasш* орф. сасы; *qшsqaq* – тат. әд. *kшska* орф. кыска; *joqaq* – тат. әд. *juqa* орф. юка һ. б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теленең урта диалекты дорсаль тартыкларның кулланылышында түбәндәге үзенчәлекләр белән характерлана:

1) тирән тел арты /q/, /ʁ/, /χ/ тартыкларының кулланылуы;

2) увуляр тартыкларның арткы рәт сузыклары белән янәшә әйтелүе;

3) /n/ тартыгының /k/, /q/, /g/, /ʁ/ авазлары алдында /ŋ/ га күчүе.

Алар билгеле бер дәрәҗәдә татар әдәби теленең әдәби нормаларында да чагылыш табалар. Бу үз чиратында әдәби тел һәм урта диалектның үзара тәэсир итешүенә бер дәлил булып тора.

**Әдәбият**

*Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка: Экспериментально-фонетический очерк. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1959. Ч. I. 183 с.

*Баскаков Н.А.* Историко-типологическая фонология тюркских языков / отв. ред. Э.Р. Тенишев. М.: Наука, 1988. 208 с.

*Махмутова Л.Т.* Фонетические особенности касимовского говора татарского языка // Материалы по диалектологии. Казань, 1955. С. 135–157.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / под ред. Э.Р. Тенишева, А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 912 с.

*Сулейманова Д.Д.* Историческая фонетика тюркских (башкирского, татарского) и баскского языков: сравнительно-сопоставительный анализ: дис. ... канд. филол. наук: 10.02.20 [Место защиты: Чуваш. гос. ун-т им. И.Н. Ульянова]. Уфа, 2016. 280 с.

Татарская грамматика: в трёх томах. Т. 1. Происхождение языка. Фонетика. Фонология. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 584 с.

*Шараф Г.* Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русским // Вестник научного общества татароведения. 1927. № 7. С. 65–102.

*Щербак А.М.* Сравнительная фонетика тюркских языков. Л.: Наука, 1970. 204 с.

***Хөсәинова Алина Җәмил кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'373

***Ф.Ф. Гыйлемшин,***
***А.Г. Гыйлемшина***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛГӘН КЫЙССА ЖАНРЫНДАГЫ ӘСӘРЛӘРДӘ СОМАТИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## («Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир», «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә» һәм «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрләре мисалында)

Данная статья посвящена анализу соматизмов, использованных в татарских произведениях кысса, переведённых со староосманского и арабского языков в конце XIX – начала XX века. В рассмотренных произведениях группа соматической лексики употребляется активно и занимает одно из основных мест. Среди активно используемых соматизмов необходимо выделить следующие лексемы: *baš* (баш) ‘голова’, *jöz* (йөз) // *čährä* (чәһрә) // *čyraj* (чырай) ‘лицо’, *küz* (күз) ‘глаз’, *awyz* // *ağyz* (авыз) ‘рот’, *tel* (тел) ‘язык’, *deš/teš* (теш) ‘зуб’, *sač* (чәч) ‘волосы’ и и др.

Ряд соматизмов, таких как *barmaq* (бармак) ‘палец’, *ajaq* (аяк) ‘нога’, *tez* (тез) ‘колено’, *tän* (тән) // *bädän* (бәдән) ‘тело’, представлены в номинативном значении словами тюркского происхождения, ставшими основной частью литературного языка.

В текстах мы не встречаем частого лексического варьирования, однако четко фиксируем разветвлённую семантическую деривацию. Семантические возможности, наблюдаемые в татарском языке, представлены в них в достаточно полном объеме.

В этой группе преобладает тюрко-татарская лексика. Единичные случаи заимствований, являющиеся показателями письменных литературных традиций, в этой тематической группе постепенно вышли из употребления.

**Ключевые слова:** соматическая лексика, *keše* ‘человек’, *baš* ‘голова’, *küz* ‘глаз’, *qul* ‘рука’, «Тутиname», «Калила и Димна», жанр кысса, литературный язык.

This article is devoted to the analysis of somatisms used in the Tatar works of qissa translated from Old Ottoman and Arabic languages at the end of the 19th – beginning of the 20th centuries. In the works reviewed the group of somatic vocabulary is actively used and occupies one of the main places. Among the actively used somatisms it is necessary to highlight the following lexemes: baš ‘head’, jöz // čährä // čyraj ‘face’, küz ‘eye’, awyz // ağyz ‘mouth’, tel ‘tongue’, deš/teš ‘tooth’, sač ‘hair’, etc.

A number of somatisms such as barmaq ‘finger’, ajaq ‘leg’, tez ‘knee’, tän // bädän (бәдән) ‘body’ are represented in a nominative meaning by words of Turkic origin which have become the main part of the literary language.

In the texts we do not encounter frequent lexical variation but we clearly detect extensive semantic derivation. The semantic possibilities observed in the Tatar language are represented in them in a fairly complete manner.

Turkic-Tatar vocabulary predominates in this group. Isolated cases of borrowing which are indicators of written literary traditions gradually fell out of use in this thematic group.

**Keywords:** somatic vocabulary, keše ‘person’, baš ‘head’, küz ‘eye’, qul ‘hand’ “Tutiname”, “Kalila and Dimna”, kyiss genre, literary language.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар әдәби теле барлыкка килә, милли әдәбият яңача үсеш ала, Көнчыгыш әдәбияты ядкәрләре татар теленә тәрҗемә ителә. «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир кыйссасы», «Әбүгалисина кыйссасы» кебек Шәрык дөньясының күркәм әсәрләре татар телендә дөнья күрә.

Бу мәкаләдә без XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарчага тәрҗемә ителгән кыйссаларда ‘кеше’ төшенчәсе белән бәйле лексиканың кулланылу үзенчәлекләрен тикшерәбез.

Өйрәнелә торган текстларда «кеше» синонимик төркеме *adäm* ‘адәм’, *insan* ‘инсан’, *keše* ‘кеше’, *šäxes* ‘шәхес’, *bändä* ‘бәндә’ һәм *zat* ‘зат’ терминнары белән белдерелгән.

Тикшеренүләр нәтиҗәсендә әлеге сүзләрнең әсәрләрдә туры мәгънәдә кулланылуы ачыкланды. Әмма, кыйссаларның үзенчәлекләренә карап, текстларда теге яки бу лексеманың активлыгы күзәтелә. Мәсәлән, «Мең дә бер кичә» экиятләрендә *адәм, кеше, инсан, шәхес* һәм *зат* сүзләренең еш кабатлануы күзәтелә: *Ul adäm wafat itde* [Әлҗилдүр-рәбигу, б. 136] ‘Ул адәм вафат булды’; *Ber adäm tora, qulynda cäjä berlän uq* [Әлф ләйлә, б. 77] ‘Бер адәм тора, кулында җәя белән ук...’; *Insan bundaj xatär waqytda joqlarmy* [Әлҗилдүс-сәдису, б. 209] ‘Инсан мондый куркыныч вакытта йоклыймы инде?’; *Ber qajyqğa benmeš keše kiler* [Әлф ләйлә, б. 77]. ‘Көймәгә утырган бер кеше килер’; *Ul šäxes säneŋ janyŋa kileb cansyz bulyb cirgä töšär* [Әлф ләйлә, б. 198] ‘Ул шәхес синең яныңа килеп, җансыз булып җиргә егылыр...’; *Ul zat kölmägä bašlab äjtde...* [Әлф ләйлә, б. 198] ‘Ул зат көлә башлап, болай диде...’.

Мисаллардан күренгәнчә, бирелгән контекстта бу сүзләрнең мәгънә төсмерләре әлләни аерылмый, алар барысы да гомумиләштерелгән семантикалы конкрет кешене белдерү процессында катнашалар.

«Кәлилә вә Димнә» әсәрендә *keše* ‘кеше’ лексемасы төрле фокуста кулланылган. Еш кына ул номинатив мәгънәдә очрый: *Allahy Täğalä kešene üksez qaldyrmasyn* [Кырык вәзир, б. 77] ‘Аллаһы Тәгалә кешене ятим итмәсен...»; *Ul keše ber jaqğa kitkäč tiz ük anyŋ urynyna kileb... utyrdy.* [Кәлилә вә Димнә, б. 35] ‘Ул кеше бер якка таба киткәч, (маймыл) тиз генә аның урынына килеп утырды...’.

Кайбер очракларда бу сүз туры мәгънәдә килеп, *saran* ‘саран’, *ğalim* ‘галим’ кебек аергычлар ярдәмендә, аңлатмалы яки билгеләүле контекстта кулланыла. Мәсәлән: *Saran keše dönja wä axirätdä xur bulyb, malyny fajdasyn kürmäs...* [Кәлилә вә Димнә, б. 27] ‘Саран кеше дөньяда да, ахирәттә дә хур булып, малының файдасын күрмәс’; *Oluğlyqqa ğalim keše lajyqraktyr* [Кәлилә вә Димнә, б. 20] ‘Галим кеше олылауга лаектыр’.

«Кәлилә вә Димнә» әсәрендә ‘кеше’ төшенчәсен белдерүдә *insan* сүзе дә актив очрый: *Insan watanyndan kiteb ğalim wä fazyllar belän saxäbät iteb kämalät tabmaq kiräklegenä išarät bar didelär* [Кәлилә вә Димнә, б. 12] ‘Инсан ватаныннан китеп, галим һәм фазыйльләр белән аралашып, камилләшүгә ирешү кирәклегенә ишарәт бар, диделәр’; *Cafany čikmägän insan safanyŋ qadren belmäs* [Кәлилә вә Димнә, б. 8] ‘Җәфаны күрмәгән инсан рәхәтнең кадерен белмәс’.

«Тутыйнамә» әсәрендә исә *keše* ‘кеше’ лексемасы өстенлек итә һәм туры мәгънәдә генә кулланыла: *Kešeneŋ hönär wä mäğrifäte bulğanda malğa ixtijacy bulmas* [Тутыйнамә, б. 5] ‘Кешенең һөнәре һәм мәгърифәте булганда малга ихтыяҗы булмас...’; *Tutyj üzenä qarağan kešegä šundyj jaqty jöze belän xuš ömidlek idär ide, här kürgän keše tutyjğa ğašyjq bulyb kitär ide* [Тутыйнамә, б. 56] ‘Тутый үзенә караган кешегә якты йөзе белән яхшы тәэсир итәр иде, һәр күргән кеше тутыйга гашыйк булып китәр иде...’; *Härmuz jortynda ber keše bar ide* [Тутыйнамә, б. 4] ’Хормуз сараенда бер кеше бар иде’.

«Әбүгалисина кыйссасы»нда ‘кеше’ төшенчәсен белдерүдә *keše* төрки сүзеннән тыш, *adäm* һәм *bändä* лексемалары да кулланыла. Мәсәлән: *Berničä kön ber jirdä qarar ideb sačyny kitäreb saqal wä tyrnaqlaryn kiseb adäm syjfatyna kerde* [Әбүгалисина, б. 17] ‘Берничә көн бер урында туктап, чәчен, сакал-мыекларын кисеп, адәм сыйфатына керде...’; *Bän ixsan itkänlärgä jaxšylyq itä torğan bändälärdän* [Әбүгалисина, б. 20] ‘Мин яхшылык иткәннәргә яхшылык итә торган бәндәләрдән’; *Bändä xatasyz bulmas* [Әбүгалисина, б. 47]. ‘Бәндә хатасыз булмас...’.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: өйрәнелгән әсәрләрдә *бәндә* сүзе хәзерге телгә хас кимсетүле мәгънәдә кулланылмый.

Кыйсса текстларында ‘кеше’төшенчәсе белән бәйле сүзләрнең тагын бер төркеме – соматик лексика (ягъни кеше тәненең төзелешенә бәйле терминнар) да шактый зур урын алып тора.

Кеше (яки хайван) гәүдәсенең тереклек өчен иң мөһим өлешләреннән берсе – баш, ул баш сөяге тартмасыннан һәм йөз (чырай) өлешеннән гыйбарәт [Татар теленең..., б. 432]. Тикшерелә торган әсәрләр текстларында әлеге төшенчә борынгы төрки *baš* «баш» [Әхмәтьянов, 1, б. 166] лексемасы ярдәмендә белдерелә, туры һәм күчерелмә (метафорик) мәгънәдә кулланыла: *Bašyn ajaqlary janyna bökeb, ülek kebek joqlady* [Әлҗилдүс-сәдисү, б. 208] ‘Ул, аякларын башын янына бөгеп куеп, үлек кебек йоклады’; *Mömkin qadär bašyŋny diwanalyqa salyb ğenlängän kešedäj bul...* [Тутыйнамә, б. 84] ‘Мөмкин

кадәр башыңны диванага салып, җенләнгән кешедәй бул'; *Uylyŋ bašyn kis, dide* [Кырык вәзир, б. 31] 'Улыңның башын кис, диде'.

Кайбер очракларда, *baš* лексемасының синекдохага әверелүе күзәтелә, ягъни баш «бәхетсезлекләр юнәлдерелгән объект булып тора» [Горды, с. 128]: *Bu bašyna kilgän jömlä bäla janyndayy wäzirdän buldy* [Әлф ләйлә, б. 139] 'Бу башына килгән барлык бәла-каза янәшәсендәге вәзирдән булды'; *Anyŋ da bašyna ber bälä kilmäsen* [Әбүгалисина, б. 8] 'Аның да башына берәр бәла килмәсен...'.

Тикшерелә торган әсәрләр текстларында 'йөз', 'бит' төшенчәсе *jöz* лексемасы һәм *cährä, čyraj* алынмалары ярдәмендә белдерелә: *matur jözeŋez ila bezlärne šad äjlä...* [Әлф ләйлә, б. 139] 'Матур йөзегез белән безне шатландыр'; *čebenlär baybannyŋ jözenä qunyb, joqlarya birmägännän* [Кәлилә вә Димнә, б. 75] 'Чебеннәр бакчачының йөзенә кунып, йокларга ирек бирмәгәч...'; *Čähräsendän padišah ikänen belde* [Әбүгалисина, б. 11] 'Йөзеннән патша икәнен аңлады...'; *Güzäl čyrajly abystajlar belän yyjš-yyjšrät itärgä mäxäbbäte bardyr* [Тутыйнамә, б. 10] 'Чибәр йөзле хатыннар белән чуалырга ярата иде'.

Текстларда персонажларның матурлыгын белдерү өчен *йөз* сүзенең *гөл* лексемасы катнашында килү очраклары да бар: *Bädiğyl Camalnyŋ jöze göl kebi ačyldy...* [Әлҗилдүл-хәмисү, б. 90] 'Бәдигыл Җамалның йөзе гөл кебек ачылды'; *göl jözle...* [Тутыйнамә, б. 4] 'Гөл йөзле...'.

Еш кына тискәре образларны сурәтләгәндә автор аның тышкы кыяфәтенә дә зур игътибар бирә: *Xajwanlar qaryj torğan bik qabäxät, borny cimerek, küze suqyr, ağyzy čalyš, ajağy aqsaq, ber quly qysqa, gurbuny čyqğan, janyna ber keše kilä almaj ağyz sasysyna...* [Әлф ләйлә, б. 106] 'Хайваннар караучы – бик кабахәт, борыны җимерек, күзе сукыр, авызы чалыш, аягы аксак, бер кулы кыска, бөкресе чыккан, янына бер кеше килә алмас авыз сасысына...'

*Küz* 'күз' соматизмы текстларда еш кына туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланыла: *Küzendäge jäšen wä jözendäge tuzanyn sört* [Кырык вәзир, б. 101] 'Күзендәге яшен һәм йөзендәге тузанын сөрт...'; *Küzläre qyzaryan ide* [Әбүгалисина, б. 61] 'Күзләре кызарган иде...'; *Küzläremez hälak bula jazdy...* [Әлф ләйлә, б. 63] 'Күзсез кала яздык...'.

Еш кына, тикшерелә торган әсәрләр текстларында күз, күрү органы буларак кына түгел, бәлки кешенең эчке дөньясы көзгесе буларак та кулланыла: *Küzlärendän, jözendän načar adäm uldyyyn beleb* [Әлҗилдүл-хәмисү, б. 23] 'Күзләреннән, йөзеннән аның начар кеше икәнен белде'; *küz qarašlaryndan belde, bunlar arsynda yyjšyq-mäxabbät bulyanny...* [Әлҗилдүр-рәбигу, б. 82] 'Күз карашларыннан болар арасында мәхәббәт булганын белде...'.

Әлеге лексема хәзерге татар әдәби телендә кулланылган фразеологизмнар составында да очрый: *Axyr xöcrätneŋ ečenä töten tulyb, bik xafä qyjla bašlady. Küz ačar xäl juq* [Әбүгалисина, б. 258] 'Соңыннан,

бүлмәнең эченә төтен тулгач, бик нык курка башлады. Күз ачар хәл юк...’; *Jöz atlylar wä ber görux saqčylar qaršy kileb, küz küreme qadär kiŋ ber mäjdannan kičeb ber oluğ diwan cirenä kiterdelär* [Әбүгалисина, б. 317] ‘Аларны йөз атлы һәм бер төркем сакчылар каршы алдылар да, күз күреме кадәр киң бер мәйданны үтеп, бер зур канцелярия бинасы янына алып килделәр’; *Ike batyr küzlären čekeräjteb ber bersenä qasd ittelär* [Кәлилә вә Димнә, б. 7] ‘Ике батыр күзләрен чекерәйтеп бер-берсенә текәлделәр’; *Küzlären joldyz kebi jaltyratyb, myjyqlaryn qabartadyr* [Кәлилә вә Димнә, б. 15] ‘Күзләрен йолдыз кебек ялтыратып, мыекларын кабартадыр...’; *Küzenä joqy kermäde* [Кырык вәзир, б. 50] ‘Күзенә йокы кермәде’.

Еш кына бу лексема ‘күз тию’ төшенчәсен белдерүдә дә катнаша: *Bu uğlanğa küz timäsen...* [Әлҗилдүс-сәлисү, б. 42] ‘Бу малайга күз тимәсен...’; *Däwlätlärenä küz tide* [Кәлилә вә Димнә, б. 9] ‘Дәүләтләренә куз тиде...’ һ. б.

Өйрәнелгән текстларда күз лексемасын хәзерге әдәби телдә актив булмаган фразеологизмнар составында да очратырга мөмкин: *Bän sine köteb küzlärem julda qaldy* [Әлф ләйлә, б. 46] ‘Мин сине көтә-көтә, күзләрем юлда калды...’; *Säwdägär küzendän ğaib buldy* [Тутыйнамә, б. 155] ‘Сәүдәгәр күзеннән гаиб булды (юкка чыкты)...’.

Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, кыйсса текстларында *küz* ‘күз’ лексемасы, кагыйдә буларак, лексик эквивалентларсыз гына кулланыла. Ләкин аның семантик һәм функциональ диапазоны шактый киң икәнлеге аңлашыла.

Әсәрләрдә *awyz* // *ağyz* ‘авыз’ сүзе гадәттә, туры мәгънәне белдерә: *Bän diŋgez suyn ečäm läkin sezneŋ ağyz ilä* [Әлҗилдүр-рәбигу, б. 182] ‘Мин диңгез суын эчәрмен, ләкин сезнең авыз белән...’; *Ağyzyna jawlyq tyğyb, kütäreb diŋgezgä kitereb* [Әлҗилдүр-рәбигу, б. 206] ‘Авызына яулык тыгып, күтәреп диңгезгә китерделәр...’; *Qulyŋ ilä ağyzyna suk* [Әлҗилдүр-рәбигу, б. 199] ‘Кулың белән авызына сук’; *Ber berenä qaršy awyzlaryn ačyb toryrlar* [Кырык вәзир, б. 33] ‘Бер-беренә авызларын ачып карап торырлар’; *Awyzyŋny ciŋ belän tot* [Кырык вәзир, б. 101] ‘Авызыңны җиң белән капла...’; *Tuğry söjlärgä ağyz ačyb äjtde* [Тутыйнамә, б. 136] ‘Тугры сөйләр өчен, авызын ачып, сөйләргә кереште’ һ. б.

Кыйсса жанрына караган текстларда *tel* ‘тел’ лексемасының да туры һәм күчерелмә мәгънәләре күзәтелә: *Kešeneŋ tele ečeneŋ tylmačydyr* [Тутыйнамә, б. 71] ‘Кешенең теле – эчке дөньясының тәрҗемәчесе...’; *Barmayyn telenä tijereb sanar irkän...* [Әлф ләйлә, б. 37] ‘Бармагын теленә тидереп саный икән...’.

Күчерелмә мәгънәдә *tel* лексемасы коммуникатив функцияне белдерә: *šäjäd, ayač telgä kiler* [Кәлилә вә Димнә, б. 72] ‘Мөмкин, агач телгә килер...’; *Bylbyl kebek fäsyjx telen ačyb äjtde* [Әбүгалисина, б. 11] ‘Былбыл кебек матур телдә әйтте...’; *Güzäl jeget kileb jomšaq tel berlän ğälladqa äjtde...* [Әлф ләйлә, б. 96] ‘Матур егет килеп, йомшак тел белән җәлладка әйтте’.

Анализлана торган текстларда ‘кул’ төшенчәсен җиткерү өчен *äl* һәм *qul* сүзләре кулланыла, бу ике лексема да туры һәм күчерелмә мәгънәләрне аңлата: *äleŋä ber fonar tot* [Әлф ләйлә, б. 129] ‘Кулыңа фонарь тот’; *Sixer ilän uγlymny bozaw surätenä, ğarijämne käğä surätenä qujmyšda, kötüčemezneŋ älenä tabšyrγb* [Әлф ләйлә, б. 12] ‘Сихер ярдәмендә улымны бозау сурәтенә, җариямне кәҗә сурәтенә кертеп, көтүчебезнең кулына тапшырып...’; *Šahzadä ul kijemne xuğa qulyna birde* [Кырык вәзир, б. 52] ‘Шаһзадә ул киемне хуҗа кулына бирде’; *ul mäxbubäm kölemseräb qulyna ber közge totyb* [Әлҗилдүс-сәни, б. 48] ‘Минем сөеклем, көлемсерәп, кулына бер көзге тотып...’; *Därwišneŋ itägen qulyŋdan jibärmä* [Әбүгалисина, б. 23] ‘Дәрвишнең итәген кулыңнан җибәрмә’.

Күчерелмә мәгънәдәге *qul* ‘кул’ лексемасы ярдәмендә бер кешенең икенче кешегә карата ихтирам хисләрен белдерү очраклары да күзәтелә: *Aqsaq, suqyr franq, išekdän kereb, Märjamnyŋ qulyn übde* [Әлҗилдүс-сәдисү, б. 198] ‘Аксак, сукыр европалы, ишектән кереп, Мәрьямнең кулын үпте’; *Qulyn übeb xälen sorady* [Тутыйнамә, б. 83] ‘Кулын үбеп, хәлен сорады’.

‘Йөрәк’ төшенчәсе текстларда *jöräk* һәм *qaleb* сүзләре белән бирелә. Алар күбесенчә, күчерелмә мәгънә аңлаталар: *Jöräge syqrab zar-zar jyylady* [Кырык вәзир, б. 51] ‘Йөрәге сыкрап, зар елады’; *Bän buny küreb, jörägem pärä pärä bulyb* [Әлф ләйлә, б. 136] ‘Мин моны күргәч, йөрәгем телмә-телмә булды...’; *Saba jile, xäbäreŋ, barmy minem jöräk ğanymdan ber närsä kiterdeŋme?* [Тутыйнамә, б. 7] ‘Таң җиле, яңалыкларың бармы, минем йөрәк җанымнан берәр хәбәр китердеңме?’; *Qalb ämer itmäsä, tel süzli almajdyr...* [Әлҗилдүс-сәни, б. 47] ‘Йөрәк боермаса, тел сөйли алмый...’; *Bänem qalebemä šäfqat kileb, waqyjγany bäjan äjlädem* [Әлф ләйлә, б. 62] ‘Минем йөрәгемә шәфкать килеп, вакыйганы сөйләдем’.

*Mujyn* ‘муен’, *barmaq* ‘бармак’, *buγaz* ‘бугаз’, *ajaq* ‘аяк’, *tez* ‘тез’, *arqa* ‘арка’, *söjäk* ‘сөяк’, *jodryq* ‘йодрык’; *qujyn* ‘куен’ кебек соматизмнар анализланган текстларда бары тик номинатив мәгънәдә кулланылган.

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, шул чор әдәби телендә өйрәнелә торган сүзләр төркеменең семантик дифференциациясе тулысынча оешып җитмәгән. Бу процесс акрынлап дәвам итеп, әдәби тел үсеш дәверенең соңгырак чорларында гына тәмамланган. Текстлардан *кеше* сүзенең бүгенге көнгәчә үзенең семантик универсальлеген саклап калганлыгын, ә *инсан, зат, шәхес* кебек алынма лексиканың күбрәк китап стилендә кулланыла башлавын беләбез. Шулай ук, кыйссаларда актив кулланылып, номинатив, нейтраль мәгънәгә ия булган *адәм, бәндә* кебек сүзләр хәзерге татар әдәби телендә мәгънәсен үзгәртеп, коннатанатив, ягъни түбәнсетү төсмерендә кулланыла башлаган.

Кыйсса жанрындагы әсәрләрдә соматик лексика туры һәм күчерелмә (метафорик) мәгънәләрдә очрый. Генетик аспекттан караганда,

текстларда төрки-татар лексикасы өстенлек итә. Алар кеше портретларының аерылгысыз өлеше булып тора. Әлеге лексиканы өйрәнү әсәр авторлары халык-сөйләм теле элементларын үз әсәрләре составына кертүгә зур игътибар биргәннәр, шул рәвешчә, хәзерге татар әдәби теленә нигез салуда үзләреннән саллы өлеш керткәннәр, дип фикерләргә нигез бирә.

**Әдәбият**


*Горды Мирослава.* Соматическая фразеология современных русского и польского языков. Щецин, 2010. 364 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 568 б. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т. I: А–В. Казан: ТӘhСИ, 2015. 712 б.

ابوعلي سينا قصه سي ديمكله مشهور تخيلات ننك ترجمه سي.عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجمات و تصنيفاتنداندر. قزان اونيورسيتيتي ننك طبع خانه سنده باصمه اولنمشدر ١٨٩٤ نچي يلده. ١١٢ ب = Абугалисина кыйссасы димәклә мәшһүр тәхйиләтнең тәрҗемәсе = Рассказы Абу Гали Сины. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1894. 112 с.

الف ليلة و ليلة،بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي،١٨٩٧ سنهده ٢١٢ ب.= Әлф ләйлә вә ләйлә= Тысяча и одна ночь. Т. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1897. 212 с.

الجلد الثاني ترجمة الف ليلة و ليلة ايكنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي ١٨٩٧ سنه ده. اوشبو مننك ده بر كيچه كتابى قزان اونيورسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل قزان اويازى توبان قرصى آولى حاجى شمس الدين حسين اوغليننك ورثه لري خراجاتي ايلان اول مرتبه ١٨٩٨ يلده ١٦٠ ب. = Әл-җилдүс-сәни тәрҗәмәти әлф ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1898. 120 с.

الجلد الثالث ترجمة الف ليلة و ليلة. اوچنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيورسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣١٨ ب. = Әлҗилдүс-сәлисү тәрҗәмәти әлф ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 3. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1898. 286 с.

الجلد الرابع ترجمة الف ليلة و ليلة. درتنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيورسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣١٨ ب. = Әлҗилдүр-рәбигу тәрҗәмәти әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 4. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 318 с.

الجلد الخامس ترجمة الف ليلة و ليلة. بشنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيورسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ١٩٢ ب. = Әлҗилдүл-хәмисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 5. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 192 с.

الجلد السادس ترجمة الف ليلة و ليلة. الطنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيورسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣٨٢ب = Әлҗилдүс-сәдисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 6. Казань, Изд. Казан. ун-та, 1899. 382 с.

طوطي نامه. عبدالعلام فيض خان اوغلي نك ترجماتندن. مطبعة كريميه، قزانده ١٩١٦. ١٧٥ ب. = Тутый нәмә =Тутыname. Казань: Матбага Каримия, 1916. 175 с.

كليله و دمنه كتابي. بو كتاب باصمه اولنمشدر قزان اونيويريستيني ننك طبع خانه سنده١٨٨٩ نچى يلده. ٨٧ ب. = Кәлилә вә Димнә китабы = Книга Калилы и Димны. Казань: Изд. Казан. ун-та, 1889. 87 с.
قرق وزير قصه سي، عثمانلى تلندن ترجمه قيلنوب قزانده اوچونچى مرتبه باصلدى. عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجماتندر. قزانده انيورسيتيت طبع خانهسنده باصما اولنمشدر ١٨٨٣ سنه ده. ١٦٠ ب. = Кырык вәзир кыйссасы = Рассказы сорока визирей. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1883. 160 с.

***Гыйлемшин Флер Фоат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гыйлемшина Айсылу Габделҗәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт медицина университетының рус һәм татар телләре кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

***Р.Т. Сәфәров***

# БАСТЫРЫЛМАГАН «РУСЧА-ТАТАРЧА ХӘРБИ СҮЗЛЕК»

Статья посвящена неопубликованному «Русско-татарскому военному словарю» Ш. Рамазанова, С. Файзуллина и Х. Каримова, составленному в 1944 г. и хранящемуся в Центре письменного наследия Института языка литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Он не был издан по неизвестным причинам. В процессе изучения установлено, какое место занимает данный труд среди других словарей татарского языка, отражающих военную лексику. Анализ рукописи показывает, что словарь был составлен на высоком научном уровне, как лексикографический источник не потерял актуальности и по сей день.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикография, военный словарь, рукописный словарь.

The article is devoted to the unpublished «Russian-Tatar military Dictionary» by Sh. Ramazanov, S. Fayzullin and H. Karimov, compiled in 1944 and stored in the Center of Written Heritage of the Institute of Language Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. During the study it was established what place the manuscript occupies among other dictionaries of the Tatar language reflecting military vocabulary. The analysis of the manuscript shows that the dictionary was compiled at a high scientific level, as a lexicographic source has not lost its relevance to this day and has not been published for unknown reasons.

**Keywords:** Tatar language, lexicography, military dictionary, handwritten dictionary.

Төрле архивларда бастырылмаган сүзлекләрнең кульязма вариантлары аз түгел. Фарсы кульязмаларының С. Гыйләҗетдинов тарафыннан төзелгән тасвирламасында (3 китапта) сүзлекләргә аерым бүлек багышланган. Беренче китапта – биш, икенчесендә – биш, өченчесендә ике сүзлек кульязмасы тасвирланган. Араларында ике нөсхәдә «Фәрһәнге Җиһангири» («فرهنگ جهانگیری», 1608 ел) кебек 473 һәм 409 битлек аңлатмалы сүзлек [Гилязутдинов, 2002, с. 115; 2006, с. 111], өч нөсхәдә «Лүгате Нигъмәтуллаһ» («لغة نعمة الله»,1540 ел) кебек 227, 152 һәм 177 битлек фарсыча-төрекчә [Гилязутдинов, 2002, с. 116; 2006, с. 112], шулай ук гарәпчә-фарсыча, фарсыча-гарәпчә тәрҗемәле сүзлекләр бар.

Русча-татарча кульязма сүзлекләргә М. Ногман монографиясендә җентекле анализ бирелгән [Ногман, 1969, б. 26–42]. Лексикография бүлеге аспиранты Г.Х. Җамалиева төрле чорда төзелгән гарәпчә-татарча сүзлекләрне өйрәнә башлаган иде. Алар арасында кульязма сүзлекләрнең дә шактый булуы ачыкланды. Кульязма сүзлекләрнең

кайберләренә «Татар лексикологиясе»ндә дә аерым урын бирелгән [Татар лексикологиясе, 2018, б. 47–64].

Урта гасырлардан алып XIX гасыр ахырына кадәрге сүзлекләр баштан ук кулъязма формада куллану өчен төзелгән яки күчерелгән булса, XX гасыр башында, аеруча Совет чорының башлангыч елларында басма сүзлекләр аларны бөтенләй кысрыклап чыгара. Шул ук вакытта теләсә кайсы басма сүзлекнең иң элек кулъязмасы әзерләнә. Басмага әзерләнеп тә төрле сәбәптән нәшер ителми калган мондый сүзлекләрнең кулъязмалары да төрле архивларда саклана.

Күләме ягыннан иң зур һәм фәнни әһәмиятен бүген дә югалтмаган әлеге чыганаклар арасында Н. Исәнбәт тарафыннан төзелгән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» беренче урында тора дисәк тә ялгыш булмас. Сүзлеккә материал 1950 елларда тупланып беткән була, әмма сүзлек басылмый калган [Хабутдинова, 2024, 301–302]. Шулай ук Галимҗан Ахунҗановның «Татар теленең зур фразеологик сүзлеге» өчен картотека базасы булдыруы билгеле, тик бу материал сүзлек булып басылып чыкмады. Үз вакытында М.И. Скворцов 6 меңнән артык сүзне үз эченә алган «Татарча-чувашча-русча» сүзлек төзегән булган [Дегтярёв, 2024, с. 24–25]. Актуальлеген һаман да югалтмаган әлеге сүзлек кулъязма хәлендә саклана.

Гомумән алганда, кулъязма сүзлекләрнең әлегә барысы да тел белгечләренә билгеле түгел. Һичшиксез, аларны эзләп табу, махсус өйрәнү, бүгенге көн өчен әһәмиятен югалтмаганнарын бастырып чыгару таләп ителә.

Шушы арада бер хезмәттә дә телгә алынмаган шундый бер кулъязма ачыкланды. (Кулъязма турында Институтның халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре И.Г. Закирова хәбәр итте. Аңа чын күңелдән рәхмәт белдерәбез.) Ул Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана һәм «Русча-татарча хәрби сүзлек» дип атала.

Гомумән алганда, хәрби терминологияне тулы бер системага салып тәкъдим иткән лексикографик чыганаклар күп түгел. Шундыйлардан беренче хезмәт буларак 1926 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы»н атарга мөмкин. Сүзлекнең авторлары күрсәтелмәгән. «Аңлаткыч» дип аталган кереш өлешендә аның максатлары түбәндәгечә ачыкланган: «Бу “Русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы” ике төрле теләкне күз алдында тотып төзелде: бердән, төрле күчерүчеләр бер үк сүзне төрлечә күчереп бутамасыннар өчен, рус теленнән татарчага устав, сугыш китаплары һәм кулланмалар күчерүчеләргә бер төрле сугыш исемнәре урнаштыру; тылмачның икенче теләге дә рус командирлар составына татар кызылармеецларын сугыш эшенә өйрәткәндә, бигрәк тә мылтык, пулемёт кисәкләре һәм уставлар белән таныштыруда булышлык итү һәм шуның белән бергә русча начар белүче татар кызылармеецларына русча сугыш исемнәрен төшенүне уңайлату» [Краткий русско-татарский…, 1926, с. 6]. Сүзлектән файдалану мөмкинлекләрен

арттыру өчен, һәр тәрҗемә ителәсе һәм тәрҗемә ителгән сүз гарәп графикасында да, кириллица да бирелгән. Мәсәлән:

Ствол كۇبشه (ٲستۋول) Кöбшä

Р. Ә. Мөгыйновның 2000 елда чыккан «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге» – татар телендә хәрби терминологияне тәртипкә салу эшендә иң җитди хезмәт [Русско-татарский военный…, 2000]. Ул кораллы көчләрнең барлык төрләрен колачлаган 8 меңгә якын терминны үз эченә ала. Сүзлек бер телдән икенче телгә терминнарның тәрҗемәсен биргән басма гына түгел. Автор сүзлек белән бергә ике телдә хәрби темага кагылышлы мәкаль һәм әйтемнәрне дә туплап тәкъдим иткән. Борынгы заманнардан алып хәзерге көнгә кадәр төрле халыклардагы корал, сугыш киемнәре һәм башка хәрби кирәк-яракларның иллюстрацияләре бирелгән шактый күләмле кушымтасы да игътибарга лаек. Сүзлектә күп кенә катлаулы һәм аңлаешсыз терминнар рус теленнән татар теленә тәрҗемә ителеп кенә калмыйча, кыскача аңлатмалар белән дә тәэмин ителгән. Бу яктан ул аңлатмалы белешмәлеккә якын. Мәсәлән, Б хәрефенә 102 терминның 60 ына татар телендә кыскача билгеләмә бирелә. Шул ук вакытта сүзлек тулылыкка дәгъва итә алмый: кайбер мәкаләләрдә, әдәби формадан тыш, сөйләм-диалектта (вертолёт – вертолёт, боралак) бирелсә, күп кенә киң кулланылган тарихи сүзләр басмада урын тапмаган (меч, кистень һ. б.) [Сафаров, 2015, с. 28].

Безнең тарафтан төзелгән «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге»ндә татар теле беренче планга чыгарылды [Сәфәров, 2017]. Шуның белән бу белешмәлекнең әһәмияте зур. Автор анда Урта гасырлар әдәбиятында, мәкаль-әйтемнәрдә, тарихи романнарда чагылыш тапкан хәрби сүзләрне туплап бирүне максат итеп куйган, шул сәбәпле, рус теле аша кереп, хәзерге татар телендә нигездә үзгәрешсез кулланылган хәрби терминнар бик чикле күләмдә теркәлгән. Сүзлектәге берәмлекләрнең тематикасына килгәндә, анда сугыш кораллары һәм корал төрләренең атамалары, аларның аерым өлешләрен, детальләрен, саклау савытларын белдергән сүзләр; саклану киемнәре һәм аларның аерым өлешләрен тәгъбирләгән берәмлекләр; төрле хәрби берләшмәләр, сугышчыларның исемнәре; гаскәр башлыкларының атамалары; сугыш мәйданының аерым эпизодларын, хәрби символларны белдергән берәмлекләр; әсирләрне тасвирлауга бәйле лексика һәм хәрби өлкәгә караган башка шундый сүзләр алынган. «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге»ндә күптәнге чорларда формалашып, һәр дәвердә яңа берәмлекләргә байый-байый, хәзерге татар телендә хәрби тематикага бәйле лексик системаны тәшкил иткән бай материал, аеруча искергән һәм искереп бара торган берәмлекләр барланган һәм анализлап тәртипкә салынган [Сабитова, 2019, б. 171].

2023 елда Халыкара төрки академия (Казакъстан Республикасы, Астана шәһәре) инициативасы белән күптелле терминологик сүзлекләрнең кульязмалары әзерләнде. Шулар арасында хәрби

терминология сүзлеге дә бар. Сүзлек күптелле белешмәлек рәвешендә төзелгән, аның нигезен инглизчәдән азәрбайҗан, башкорт, казакъ, каракалпак, кыргыз, татар, төрек, төрекмән һәм үзбәк телләренә тәрҗемә ителгән 5 меңнән артык термин тәшкил итә. Шулай ук барлык терминнар рус телендә дә бирелгән. Әлеге белешмәлекне кәгазьдә бастыру планлаштырыла.

Алда әйтеп узганча, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә» язма мирас үзәгендә Ш. Рамазанов, С. Фәйзуллин һәм Х. Кәримов тарафыннан төзелгән «Русча-татарча хәрби сүзлек» кульъязмасы саклана. Кульъязма А4 форматындагы кәгазьгә машинкада басылган, ике папкадан гыйбарәт. 200 битлек беренче папкага А хәрефеннән башлап О хәрефенә (*отбив* сүзенә) кадәр сүзләр [52 нче ф., 1 нче тасв., 233 нче сакл. бер.], 243 битлек икенче папкага О хәрефеннән башлап Я хәрефенә кадәр сүзләр, шулай ук ике кушымта: «Сокращения – Кыскартмалар» һәм «Команды – Командалар» кергән [52 нче ф., 1 нче тасв., 234 нче сакл. бер.]. Ике папканың да тышында эш 1944 елның 17 августында тәмамланган дип язылган.

Кульъязманың титул битендә бастыру нәшрияты буларак «Татгосиздат» күрсәтелгән. Димәк, сүзлекне дәүләт нәшриятында бастыру планлаштырылган булган. Титул биттән соң кулдан зәңгәр кара белән язылган ике генә битлек «Сүз башы» килә. Анда авторлар сүзлеккә 10 меңләп сүз-термин кергәнен, аның күләме чикле һәм кыска булганын билгеләп үтәләр. Шунда ук сүзлекнең төзелешенә карата кыскача белешмә бирелгән, кайсы авторның нинди хәрефләргә башланган сүзләр кергән өлешне төзүе күрсәтелгән.

Алга таба кульъязмада профессор Х. Мөштәринең «Хәрби сүзлек» турында рецензия»се беркетелгән: башта ике ягына да зәңгәр кара белән өч дәфтәр битенә язылган варианты, аннары шул ук текстның машинкада басылган күчермәсе. Кыска гына керештән соң Х. Мөштәри кульъязмадагы кимчелекләргә тукталa. Ахырда сүзлек «аз гына төзәтмәләр кертү белән басарга яраклы», дигән нәтиҗә ясый [Русско-татарский военный…, 1944, с. 6].

Кульъязма тексты яхшы укыла. Һәр биттә диярлек авторларның (бәлки, шулай ук бәяләүченендер) зәңгәр кара белән төзәтмәләре һәм өстәмәләре бар.

Сүзлекнең эчке структурасына килгәндә, ул бүген дә актуальлеген югалтмаган терминологик сүзлекләр калыбында төзелгән. Баш сүзләр (вокабулалар) баш хәрефләрдән алфавит тәртибендә урнаштырылган. Төп терминга караган аналитик формалар, терминологик сүзтезмәләр, төр терминнары шул вокабула астында оялап бирелгән, төп терминнар тире белән күрсәтелгән:

СТОЛКНОВЕНИЕ – бәрелешү, бәрелеш.
– АЭРОПЛАНОВ – аэропланнар бәрелешү.
– ПОЕЗДОВ – поездлар бәрелешү.
– С ПРОТИВНИКОМ – дошман белән бәрелешү.

Күп очракта юл хәрефләре белән бирелгән татар эквивалентларыннан соң кыек җәяләр эчендә кыскача гына аңлатмалар да урнаштырылган:

ШЛЕМ – шлем /баш киеме/.

ШЛЮС – шлюс /атлы гаскәрләрдә – ияр өстендә нык утыруга ирешү өчен иярне тезләр һәм бот итләре белән кысу/.

ЭСКАДРИЛЬЯ – эскадрилья /1/ хәрби корабльләр берләшмәсе; 2/ хәрби операциядә берничә звенодан яки отрядтан торган бүлекчә/.

Сүзлектә аерым сүз төркемнәренең бирелеше хәзерге сүзлекләрдән берникадәр аерыла. Мисал өчен, нисби сыйфатлар 2018 елгы русча-татарча сүзлектә түбәндәгечә бирелә:

**авиаторский** *прил.* очучы …ы, авиатор …ы
**штабной** *прил.* штаб …ы; **штабная рота** штаб ротасы
**этапный** *прил.* этап ...ы

Кулъязмада исә шул ук сүзләр башкача тәкъдим ителгән:

АВИАТОРСКИЙ – авиатор /га бәйләнешле/.

ШТАБНОЙ – штаб /ка бәйләнешле/.

ЭТАПНЫЙ – этап /ка бәйләнешле/.

Татар телендә төгәл эквиваленты булмаган һәм, кагыйдә буларак, изафә конструкциясе белән кулланыла торган рус сыйфатлары XX гасырның беренче яртысында төзелгән күпчелек сүзлектә нәкъ шушындый калыпта бирелеп килгән.

Анализлана торган кулъязма әзерләнгән чорда бөтен сүзлекләрдә дә фигыльләр эзлекле рәвештә *-у/-ү* кушымчасы белән, ягъни исем фигыль формасында бирелә. (Совет чорында төзелгән бер генә сүзлектә дә без фигыльләрнең *-мак/-мәк* кушымчасы белән бирелгәнен очратмадык):

АРЕСТОВАТЬ – кулга алу, сак астына алу.

БАРАБАНИТЬ – барабан кагу, барабан сугу.

ФОРСИРОВАТЬ – кичү, сугышып үтеп чыгу.

Сүзлек 30 нчы еллар ахырында, аеруча сугыш елларында төзелгән дип фаразлыйбыз. Ул вакытларда рус теленең терминология өлкәсенә йогынтысы аеруча көчле була. Бу хәрби сүзлектән дә яхшы күренә. Күпсанлы русча һәм рус теленә Европа телләреннән кергән терминнар шул килеш татар теле ягында да тәкъдим ителә:

БЛИНДАЖ – блиндаж.

ВИНТОВКА – винтовка.

ГЕНЕРАЛИТЕТ – генералитет.

Шул ук вакытта күп кенә терминнарга татарча синонимнар да бирелә бара:

БАТАЛИЯ – баталия, сугыш, орыш.
ГРАДУС – градус, дәрәҗә.
ДЕЛЕГАЦИЯ – делегация, вәкилләр.

Татар теле ягында калька яки ярымкалька юлы белән ясалган терминнар аз түгел:

АВИАШКОЛА – авиамәктәп.
АВТОСАНИ – авточана.
АЭРОМАЯК – һава маягы.
ВОДОХРАНИЛИЩЕ – су саклагыч.

Бу ысул белән татар телендә яңа терминнар ясауны без уңай бәялибез. Хәзерге татар телендә бигрәк тә узган гасыр башында барлыкка килгән мондый калькаларның шактые әдәби телнең актив кулланыштагы лексикасын тәшкил итә.

Гомумән алганда, хәрби сүзлектә татар теленә яңа кереп барган берәмлекләр саны шактый күп. Вокабулярийның чама белән 80% ын моңа кадәр басылып чыккан сүзлекләргә теркәлмәгән терминнар тәшкил итә дип саныйбыз. Бу беренче чиратта ул замандагы хәрби эшнең яңа баскычка менүе, сугыш ысулларының камилләшүе, коралларның үзгәрүенә дә бәйле. Икенче яктан, сүзлекләрнең арта баруы, сыйфатлары күтәрелә төшү аларны тулырак, төзегрәк итүне таләп итә. Рус теленең көчле йогынтысына аерым игътибар итәргә кирәк. Монда фәнни терминологиянең бөтен өлкәсендә дә рус телле терминология нигез итеп алынганын күз уңында тоту зарур. Шуның белән бергә сүзлек төзүчеләр еш кына, берничә варианттан телдә инде кулланылган яки гарәп-фарсы алынмасын сайламыйча, рус телендәге терминны татар теленә кертүне өстенрәк күрә. Карала торган сүзлектә, мәсәлән, *аптека, больница, власть, группа* дигән сүзләр рус теле ягында да, татар теле ягында да бертөрле бирелә.

Сүзлектә берникадәр традицион татар хәрби лексикасына да урын бирелгән. Мәсәлән:

БАЛЛИСТА – баллиста; мәнҗәникъ.
БЕРДЫШ – айбалта.

Кулъязманың «Командалар» дип аталган кушымтасы аеруча кызык. Анда бүгенге көн күзлегеннән искергән командалар да теркәлгән:

ЗАПРЯГАЙ! – Җигәргә!
ЧУЛКИ СНЯТЬ! – Оекларны салырга!

Мондый командалар тарихи әсәрләрне тәрҗемә иткәндә кулланыла ала. Шул ук вакытта авторларның команда-боерыкларның татарчаларын тәкъдим иткәндә боерык фигыльгә түгел, инфинитивка

аеруча игътибар бирүләре татар теле позициясеннән чыгып түгел, рус теленә ияреп эш итүләрен күрсәтә. Мәсәлән, ЧУЛКИ СНЯТЬ! дигәнне *Оекларны сал!*, хәтта *Оекны сал!* дип, СОМКНИСЬ! дигәнне *Кысылыгыз!* түгел, *Кысыл!* дип, ВСТАТЬ! дигәнне *Торыгыз!* түгел, *Тор!* яки *Бас!* дип кыскартырга һәм боерык фигыль формасында бирергә булыр иде. Шул ук вакытта СТАНОВИСЬ! – Сафка бас! /тезел!/; РАЗВЕРНИСЬ! – Җәел! кебек кайбер очракларда боерык фигыль формасы кулланылган.

Күпчелек командаларга татар эквивалентлары тәкъдим ителгән (ВОЛЬНО! – Ирекле торыгыз!), рус теленнән үзгәртелмичә калган очраклар да бар: ОТБОЙ! – Отбой!; СМИРНО! – Смирно!

Ш. Рамазанов, С. Фәйзуллин һәм Х. Кәримов тарафыннан төзелгән «Русча-татарча хәрби сүзлек» билгесез сәбәпләр аркасында басылмый калган. Ул үз вакыты өчен югары дәрәҗәдә төзелгән белешмәлек булган. Кайбер терминнарның тәрҗемәсен ачыклау өчен аны бүген дә кулланырга мөмкин. Сүзлектәге хәрби терминология хәзерге татар телендәге хәрби терминологиягә тәңгәл килә дип бәяләп була. Хәрби лексиканы өйрәнгән вакытта нәтиҗәләр тагын да ышандырырлык булсын өчен, бу сүзлек материалы һичшиксез файдаланылырга тиеш. Шул вакытта гына әлеге тармак терминнарның үсеш эволюциясен һәм динамикасын ачыграк күзалларга мөмкин булачак. Тулаем алганда, сүзлек – узган гасыр башында, аеруча Совет хакимиятенең беренче елларында татар теленең нинди юлдан үсеп китүен, нинди тенденцияләр өстенлек итүен күзәтү өчен ачык мисалларның берсе. Татар лексикографиясе тарихын тулырак һәм объективрак тасвирлау өчен, телнең хәрби лексикасын билгеле бер чорда теркәгән чыганакларның берсе буларак, ул бәяләп бетергесез зур роль уйный.

**Әдәбият**

*Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. Казань, Фикер, 2002. 254 с.

*Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. Вып. 2. Казань, 2006. 192 с.

*Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. Вып. 3. Казань, 2007. 288 с.

*Дегтярёв Г.А.* М.И. Скворцов как лексикограф // Актуальные проблемы лексикографии, терминологии и теории перевода: к 90-летию со дня рождения М.И. Скворцова (1933–1916): материалы Всерос. науч.-практ. конф. «Актуальные проблемы лексикографии, терминологии и теории перевода» (Чебоксары, 25 мая 2023 г.) / сост. и науч. ред. Г.А. Дегтярёв, Э.Е. Лебедев. Чебоксары: ЧГИГН, 2024. 300 с.

Краткий русско-татарский словарь военных терминов (толмач). М., Искра революции, 1926. 180 с.

*Ногман Мостафа.* XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 1969. 112 б.

Русско-татарский военный словарь / Ш. Рамазанов, С Файзуллин, Х. Каримов // Центр письменного наследия ИЯЛИ им. Г. Ибраһимова АН РТ. Фонд

Татарский научно-исследовательский институт языка, литературы и истории (Тат. НИЯЛИ), ф. 52, оп. 1, ед. хр. 233, 234.

Русско-татарский словарь военных терминов / авт.-сост. Р.А. Мугинов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 151 с.

*Сабитова И.И.* «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» турында (төзүче Р.Т. Сәфәров) // Фәнни Татарстан. 2019. № 1. Б. 171–173.

*Сафаров Р.Т.* Военная лексика татарского языка. Казань, 2015. 196 с.

*Сәфәров Р.Т.* Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге. Казан: ТӘhСИ, 2017. 112 б.

Татар лексикологиясе: өч томда. Т. III. 2 кис. Казан: ТӘhСИ, 2018. 464 б.

*Хабутдинова М.М.* Почему не был опубликован первый толковый словарь татарского языка Наки Исанбета? // Теория языка и межкультурная коммуникация. 2024. Выпуск 2(53). С. 291–312.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 82.091

*Д.М. Абдуллина*

## АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ...
## (Татар әдәбияты классигы Дәрдемәнднең тууына 165 ел тулу уңаеннан)

В статье представлен обзор жизни и деятельности классика татарской литературы, издателя, крупного промышленника, мецената, общественного деятеля Дэрдменда (Закира Рамиева). Определено его место в татарской культурной жизни начала XX века, проанализированы основные мотивы и особенности его творчества.

Статья посвящена 165-летию со дня рождения Дардменда.

**Ключевые слова:** Дэрдменд, поэзия, татарская литература, татарские издатели начала XX века.

The article presents an overview of the life and activities of the classic Tatar literature, publisher, major industrialist, philanthropist, public figure Dardemend (Zakir Ramiev). His place in the Tatar cultural life of the early XX century is determined,the main motives and features of his work are analyzed.

The article is dedicated to the 165th anniversary of Dardemend's birth.

**Keywords:** Dardmend, poetry, тatar literature, тatar publishers of the early XX century.

Халкыбызның үткәне, бүгенгесе турында фикер йөрткәндә, аның күп гасырлар дәвамында Россия һәм гомумкешелек тарихында зур әһәмияткә ия булган вакыйгаларда хәлиткеч роль уйнавы күңелләрдә горурлык хисе дә уята, уйландыра да. Милләтебезнең асылын, дәрәҗәсен, зыялылыгын, иманын, үз кыйбласын саклап, киләчәккә атлавында рухына «мөкаддәс кан, изге сөт» белән милләтпәрвәрлек салынган фидакяр затлар зур ышаныч, терәк булган һәм алга таба да ул шулай булачак. Һәр заман үз югарылыгында олуг шәхесләрне тудыра. Кайчандыр Колшәрифләре, Сөембикәләре булса, аларны Курсави, Бубилар, Насыйри, Тукай, Дәрдемәнд, җәлилчеләр алыштырган. Татар халкы үзенең данын күтәргән, рухын баеткан, мәдәни үсешенә юнәлеш биргән абруйлы затларыбызның һәрберсен зур хөрмәт белән хәтерендә саклый.

Шундый олы шәхесләрнең берсе – классик шагыйрь, нашир, җәмәгать эшлеклесе, эре сәнәгатьче, химаяче Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев – Дәрдемәнд.

XX гасыр башы татар тормышына һәрьяклап йогынты ясаган, белеме, дөньяга карашы, матди мөмкинлекләре ягыннан да, әдәби таланты белән дә аерылып торган зыялы зат ул. Бу шәхескә язмыш мөмкинлекләрне дә, иҗат куәсен дә кызганмый, әмма алардан файдалану вакытын гына чикли.

Закир Рәмиев 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Атасы Мөхәммәтсадыйк Габделкәрим улы бик булдыклы кеше була, сәүдә эшләре белән ике йөзешәр чакрым араларны әйләнә. Шул сәфәрләренең берсендә, ярминкәгә барганнан соң, ул Эстәрлетамактан өч йөз чакрым чамасы ераклыктагы Юлык авылында бөтенләй төпләнеп калырга уйлый. Закирга өч яшьләр булганда, алар гаиләләре белән шунда килеп урнашалар. Кечерәк сабын заводы сатып алалар һәм тире-күн эшкәртү эшен дә җайлап җибәрәләр. 1869 елда Мөхәммәтсадыйк Юлыктан сиксән чакрымнар ераклыкта урнашкан Ишбирде авылыннан беренче алтын приискасын сатып алуга ирешә. Эшләре киңәеп киткәч, 1871 елдан Закирны да милек хуҗасы буларак терки, ягъни берничә прииска улының милке булып санала. 1892 елда вафаты алдыннан Мөхәммәтсадыйк ага улларына ике дистәдән артык алтын приискасын мираска калдыра. Ике бертуган Шакир (1857–1912) белән Закир бу эшне лаеклы дәвам итүчеләрдән булалар. Тарихи-рәсми чыганаклардан күренгәнчә, 1902–1904 елларда, эш туктатылганнарын (аларның саны 42) һәм кем беләндер уртак милектә булганнарын да (мондыйлары 12) кертеп исәпләгәндә, Рәмиевләр приискаларының саны 91 гә җитә. Октябрь инкыйлабыннан соң Закир Рәмиев тулысынча җиһазландырылган кырыктан артык алтын шахтасын Совет хөкүмәтенә тапшыра.

Шагыйрьнең әнисе Хәнифә – шул ук Эстәрлетамак өязе Яуш авылы морзасы (нәселләре элек-электән рус мәктәбе тәрбиясе дә алган) Алмакай (Әлмөхәммәт) Дашков кызы.

Закирга тәүге тапкыр сабак биреп, русча һәм татарча укый-язарга өйрәтүче кеше әнисе була. Соңрак ул Орск өязе Тәмәч (Темәс атамасы да кулланыла) авылы учителеннән хосусый дәресләр ала, Юлык башлангыч мәктәбен тәмамлый һәм ике кыш, абыйсы Шакир белән, Орск шәһәрендә, аннары Муллакай мәдрәсәсендә укый. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, алар Орскида яши. Закир 1880 елда, белемен тирәнәйтү теләге белән, Төркиягә китә, ике елга якын шунда яшәп, 1881 елда кабат Орскига әйләнеп кайта.

Төркиядә аерым уку йортына кереп укымый, Истанбул шәһәрендә урнашып, үзлегеннән төрек телен, әдәбиятын өйрәнә, ирекле рәвештә аерым укытучылардан хосусый дәресләр ала, төрек мәдәнияте, шагыйрьләре һәм язучылары белән таныша, типография эше белән кызыксына.

Фатих Кәрими Закирның төрекчә, гарәпчә, фарсыча, русча камил үк белгәнен, соңыннан да бу телләрдә язылган әдәбият һәм вакытлы матбугат белән танышып баруын, Шәрык һәм Гареб дөньясының күренекле әдипләре, фәлсәфәчеләренең хезмәтләрен укыганлыгын яза [Кәрими, 1929, б. 9–10].

Истанбулдан кайткач, ул Орскида төпләнә, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә, җәй айларын алтын приискаларында уздыра. 1882 елда Орскиның зур сәүдәгәрләреннән саналган Мостафа Муса улы Борна-

евның Мәхүбҗамал исемле кызына өйләнә. Ике-өч елдан яшь гаилә Оренбургка килеп төпләнә һәм утыз биш ел шушы шәһәрдә яши. Аларның өч кызы, биш улы булып, шуларның берсе – Фоад исемлесе яшьли дөнья куя. Закир Рәмиевнең бу йортында заманының күренекле шәхесләре Р. Фәхреддинов, Ш. Камал, Г. Кәримов, Ф. Кәрими, Г. Камал, Н. Думави, Г. Ибраһимов, бертуган Максудилар (Садри Максуди Закир белән бертуган Шакирның кызы Камиләгә өйләнә), Х. Акчурин, Й. Акчурин, З. Вәлиди, Б. Баттал мәҗлестәш булган. Бу җыелуларда үз чорының иҗтимагый-сәяси вакыйгалары да, әдәбият һәм мәдәнияткә кагылышлы мәсьәләләр дә әңгәмә үзәгендә булган дип фаразлый алабыз.

Бертуган Рәмиевләрнең иң мул табыш биргән приискалары булып хәзерге Чиләбе өлкәсе Нагайбәк районы Балкан авылы тирәсендәгеләре санала. Балкан авылына нигез салучылар да – алар. Биредә Рәмиевләр алтын чыгару эшенә күңел биреп, зурлап керешәләр. Үзән инешен буып, өч ясалма күл булдыралар, чит илдән, электр тогы алу өчен, локомобильләр, махсус җиһазлар кайтартып, артезиан коелары казыталар, Балкан авылындагы кое авыл халкына озак еллар хезмәт итә.

Унике яшеннән милекче саналган Закир приискалар хуҗасы, эшмәкәр булып кына яшәми, татар милли тормышында күренекле фигураларның берсенә әверелә. Оренбургта яшәгән елларда, халык вәкиле буларак, берничә тапкыр шәһәр Думасына сайлана. Оренбург һәм Орскида оешкан берничә хәйрия җәмгыятендә әгъза булудан тыш, «Хөсәения» мәдрәсәсе оешкан елдан ук аның да Тышкы иганәчеләр һәм идарәчеләр әгъзасы була, үз исәбенә чит илдә берничә шәкерт укыта, татар мәктәп һәм мәдрәсәләрен дәреслекләр белән тәэмин итәргә булыша. «Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте» рәисе итеп билгеләнә. «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыру корылтайларында катнаша, анда милләтләрнең тигез хокуклылыгын, мәдәни үзбилгеләнү мөмкинлеген яклаган Кадетлар партиясенә язылa. Беренче дәүләт думасында да ул депутат буларак үз диндәшләренең таләпләрен якларга тиеш була, әмма Дума патша фәрманы белән таратыла.

1917 елның Февраль вакыйгаларыннан соң күтәрелеш кичергән милли хәрәкәткә дә Дәрдемәнд бик теләп кушыла. Июнь аенда Казанда узган Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда Вакытлы Милли идарәнең Малия нәзарәтенә (Финанс күзәтчелегенә) әгъза итеп сайлана.

1919 ел башында Казанда үткәрелгән татар язучылары эшен камилләштерүгә багышланган бөтенроссия күләмендәге конференция эшендә катнаша.

Рәмиевләрнең гомум милләт файдасына эшләгән иң изге эшләренең тагын берсе – наширлек хезмәте. Бертуган Шакир һәм Закир үз телебездә вакытлы матбугат органы булдыру өчен озак вакытлар тырышлык куялар. Закир Төркиядә яшәгәндә үк бу өлкә белән ныклап кызыксына, Петербургта булып, хөкүмәттән бу эш өчен рөхсәт

алырга йөргән вакытта да алар типография эшенең үзенчәлекләрен өйрәнәләр. Оренбургта тупләнеп, китап басу эшенә керешергә теләк белдергән Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримовка (Ф. Кәриминең этисе) ярдәм кулы сузучы да, Бакчасарайда И. Гаспралы нигезләгән «Тәрҗеман» газетасының иганәчәсе дә Рәмиевләр була.

1982 елда татар матбугатын булдыру турында зур сөйләшү оештыруга өметләнеп, И. Гаспралы Казанга килә. Монда аны, зур бер бинаны үз акчаларына арендага алып, бертуган Рәмиевләр каршылый. Әмма казанлылар белән эшлекле очрашуга килүче булмый, алар бу кичне үзара сөйләшеп үткәрәләр [Хәмидуллин, 2009, б. 67].

Үзләренең матбугат органын ачуга алар, әлбәттә, соңрак, 1905 ел революциясе китергән мөмкинлекләр аша гына ирешәләр. Алар бастырган «Вакыт» милли-либераль газетасы 1906 елның 21 февраленнән башлап 1918 елның 26 гыйнварына кадәр (барлыгы 2309 сан) чыга. 1907 елдан алар «Шура» журналын чыгару эшенә алыналар. Айга ике мәртәбә, һәр саны 36 битле зур форматта, рәсемнәр белән дә бизәлгән бу журнал 1908 елның гыйнварыннан 1918 елның башына кадәр нәшер ителә (барлыгы 240 сан). Наширләре Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтзакир Рәмиевләр дип күрсәтелсә дә, 1906 елның октябреннән «Вакыт» газетасында мөхәррир урынбасары булган Ризаэддин Фәхреддин, журнал басыла башлауга, мөхәррирлек эшенә билгеләнә. Әлеге газета һәм журнал 1909 елга кадәр Рәмиевләр тырышлыгы белән булдырылган «Кәримев, Хөсәенев вә шөркиясе» матбагасында басыла. Әмма бу матбугат органының сыйфатсыз чимал белән табышлырак эшләргә омтылуы, наширлек эшеннән табыш алуны һич тә максат итмәгән, милләтне рухи азыкландыруны гына күздә тоткан Рәмиевләрне һич тә канәгатьләндерми. 1909 елда алар үзләре «Вакыт» матбагасы ачып җибәрәләр һәм аның югары зәвык белән эшләвен тәэмин итү өчен көчләрен дә, байлыкларын да кызганмыйлар. Шул чорда «Шура» журналында эшләгән З. Бәшири үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «Закир Рәмиев газета белән журналның техника ягыннан матур булып чыгуына шулкадәр нык әһәмият бирә иде, хәтта машинадан өч тапкыр үткән хәрефләрне яңадан керттерми, алар белән әйбер бастырмый иде» [Бәшири, 2002, б. 140]. Әмма ул бу эш өчен җаваплы кешеләргә тулысынча ышана, беркайчан да аларны борчып, басылган яки басылачак нәрсәләрне тикшереп йөрми, үзенең шигырьләрен дә «Ярарлык дип тапсагыз, журналга кертерсез» [Бәшири, 2002, б. 144], дип кенә бирә торган була.

Егерме биш ел таныш булып, озак еллар нәшриятта эшләгән Ф. Кәрими дә Рәмиевләрнең мөхәррирләргә тулы хокук бирүләрен дәлилләп: «“Вакыт”та хатыннарга хокук бирү тиешлек, мәдрәсәләр ислахы, татар театрын күтәреп язу шикелле нәрсәләр басылып чыкканда, муллалар вә мөтәгассыйб байлар тарафыннан наширләренә күп игътизарлар, һөҗүмнәр булса да, алар мондый турыларда гәзитәгә тәэсир итәргә тырышмыйлар, һичбер сүз әйтмиләр иде» [Кәрими, 1929, б. 10], дип яза.

Бу матбугат органнарында шул чорның танылган каләм ияләре Б. Шәрәф, Г. Баттал, Җ. Вәлиди, К. Бәкер, Ш. Камал эшли. Г. Ибраһимов, Г. Тукай, М. Гафури, Н. Думави, С. Сөнчәләй, Я. Биги, З. Вәлиди, Һ. Атласи, Г. Гафуров-Чыгтай һ. б. әдипләребез, үзләренең иҗат җимешләрен халыкка җиткерәләр. Гомумән, газета-журналда язышкан авторларның географик яктан да, сыйнфый яктан да гаять киң булуы мәгълүм. Анда галим, табиб, философ, имам, шәкерт, мөгаллим-мөгаллимә, балалар да катнашкан. Хатлар, мәкаләләр Казан, Мәскәү, Уфа, Санкт-Петербург, Ташкент, Себер, Ерак Көнчыгыш, Каһирә, Истанбул, Бәйрут, Париж, Мәдинәдән килгән. Шуның белән бу газета-журналлар татар матбугаты һәм әдәбияты үсешенә үзләреннән зур өлеш кертсәләр, икенче яктан, төрки-татар дөньясын мәдәният белән сугаручы мул сулы елга вазифасын үтиләр. «Вакыт», «Шура»ны татар һәм башкортлар гына түгел, башка төрки халыклар да бик яратып укый.

«Шура» битләрендә төрек, казакъ, азәрбайҗан, үзбәк, уйгур һ. б. төрки халык вәкилләренең 150 дән артык исемдә мәкалә һәм язмалары басылып чыккан [Мәрданов, 2002, б. 160].

Рәмиевләрнең «Вакыт» нәшриятында Р. Фәхреддин, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Ш. Мөхәммәдьяров, Г. Баттал, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъдиләрнең әдәби әсәрләре һәм фәнни хезмәтләре басыла. Үз басмаханәсе булган Ф. Кәриминең кайбер хезмәтләре дә монда дөнья күрә.

«Шура» журналының еллык төпләмәләре хәзерге вакытта Казан, Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа, Ташкет, Алматы һәм Нью-Йорк шәһәрләре һәм Төркия китапханәләрендә, Хельсинки университетында саклана.

1912 елда, абыйсы Шакир Рәмиевнең вафатыннан соң, бөтен милеккә хуҗа булып калган Закир Рәмиев, 1917 елгы Октябрь революциясе тудырган кануннар буенча, барлык мөлкәтен яңа дәүләт карамагына тапшыра. Аның шәхси нәшрияты да 1917 елның көзеннән «Яңа вакыт» дип исемләнә, ә 1918 елның февраль урталарында Дәрдемәнд аны да совет хөкүмәте вәкилләренә бирә.

XX гасыр башында татар иҗтимагый тормышының үзәгендә торган, «Россиянең алтын корольләре» исемен йөрткән, тулы, түгәрәк гаилә бәхетендә яшәгән Закир Рәмиев үзенә һич тә туры килмәстәй күренгән «зарлы», «кайгылы» мәгънәсенә ия тәхәллүс алган бөек шагыйрь Дәрдемәнд буларак та танылa. Каршылыкның асылы нидә, әллә ул каршылык түгел, ә үзе бер бөтенлекме? Иҗаты аның тормышны бик нечкә һәм тирән хисләр аша кичерүче, акыл белән, фәлсәфи югарылыкта бәяләүче шагыйрь икәнлеген дәлилли. Бу шагыйрь шәхесе һәм иҗатының бөтенлеген дә раслый.

Дәрдемәнд – үз чорында иҗат иткән әдипләрдән әсәрләренең идея-тематик эчтәлеге, теле белән дә аерылып тора. Ул бөтен асылы белән милләтпәрвәр шәхес булса да, иҗатында инкыйраздан сакланырга, Европа мәдәниятенә йөз белән борылырга өндәгән мәгърифәтчел-дидактизмга юнәлеш тотмый. Шулай да Дәрдемәнд үз заманының

иҗтимагый-сәяси вакыйгаларыннан, халык рухыннан читләшми. Бердән, бу шагыйрьнең үз чорындагы вакыйгаларга гомумяшәеш кануннары, җиһан югарылыгыннан торып бәя бирергә омтылуыннан булса, икенчедән, иҗтимагый-социаль хәле, белеме, мәдәниятлелек һәм мәгълүматлылык дәрәҗәсеннән дә килә. «Аның шигырьләре хистән бигрәк фикер тирәнлеге эченә чумып, озак төшенүнең җимеше булдылар. Ул әүвәл хис итмәде, төшенде: төшенгәнен хискә әйләндерде» [Сәгъди, 2002, б. 149]. Бу рәвешле эш йөртү аның шигъриятен фәлсәфә, тарих тәҗрибәсе белән баета, әмма моңа карап һич тә сәнгати югарылыгына, нәзакатьлелегенә хилафлык китерми.

1902–1903 елларда «Тәрҗеман» газетасында басылган берничә шигыре бик үк отышлы булмаса да, 1906 елда «Казан мөхбире»ендә басылган «Каләмгә хитаб» әсәре белән ул җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Шуннан башлап аның шигырьләре «Казан мөхбире», «Вакыт» һәм «Шура» битләрендә еш күренә. Башта шигырьләрен «Р», «Д» имзасы белән бастыра, алга таба ул үзен «Дәрдемәнд» дип яза. Әмма укучыларны да, тәнкыйтьчеләрне дә аның шигырьләренең үзенчәлеге, тематик киңлеге, фәлсәфи тирәнлеге, сәнгати камиллеге үзенә тарта.

1908–1910 елларда «Шура» журналының һәр санында диярлек Дәрдемәнд шигырьләре басыла. «Кораб», «Без», «Хәят», «Бүзләрем мана алмадым» кебек фәлсәфи шигырьләре янында «И мөхәррир», «Хикәяи гыйшык», «Игътизар», «Бәллү» «Школьникка» кебекләре шагыйрь иҗатының идея-тематик яктан киңлеген, шигъри талантын дәлилләп тора.

Гасыр башында ил күләмендә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, татар матбугаты өчен туган иркенлекләрдән файдаланып калуны күздә тотып, шагыйрьләребез каләм образын символлаштырып, аны халыкны үз янына туплап, кайгы-шатлыгын уртаклашып, яңалыкка, көрәшкә әйдәп торучы рәвешендә гәүдәләндерсәләр, Дәрдемәнд каләменә үз заманының вакыйгаларын киң тарихи яссылыкта ачу бурычын йөкли. Аяк астыбыз кан, күз яше, кыерсытылганнар зары, билгесез корбаннар белән тулганлыгын, дәүләтебезне саклап шәһит киткән бабаларыбыз кабере, аталар рухы алдында бурычыбыз түләнмәгәнлеген искәртә ул.

*Каләм! Калбеңдә ни сер бар гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит!*
……………………………………………
*Бабалар кабере янында күңел зар,*
*Аталар рухының армандасы бар…*
*Кара туфрак тулы мазлум нидасы,*
*Алар кемдер? Алар кемнәр фидасы?* («Каләмгә хитаб», 1906) –

дип, Дәрдемәнд ил күгендә куерган вакыйгаларны гомум вакыт агышына бәйләп, фәлсәфи югарылыктан, салкын акыл белән бәяләп әдәбият мәйданына аяк басты һәм ил эчендә искән җилләргә һәрвакыт

игътибарлы булып, аңа үз бәясен бирә килде. Милли горурлыкны, гаделлекне яклау юлында «каләм – тел зөлфикаре»нең көченә зур ышаныч баглап эш итте. Шагыйрьлек вазифасын халык хәтерен яңартуда, нәфислек, мәхәббәт җырчысы булуда күрде.

Дәрдемәнд шигъриятендәге күңел төшенкелеген һич тә берьяклы гына, буржуазия сыйныфының инкыйлабны кабул итмәве яки «җиһан туен иткәндә, урыны үлекләр аймагында» булачагын төшенүдән генә дип аңларга ярамый. Дөрес, мәсьәләнең бу ягы да аерым игътибар сорый.

Ул үз чорының вакыйгаларыннан тәэсирләнеп яши, язарына азыкны да шуннан ала. Кайвакыт һәркемгә мәгълүм олы фәлсәфә артына аерым вакыйга, лирик геройның күңел сызлануы, ә кайберләрендә шәхси фаҗигасы өретелгәнлеге сизелә. «Без» шигырендә гасырлар, еллар дәвамында яшәп, инде эзсез юк булган мәшһүр ил-дәүләтләр, бөек затлар язмышын фәлсәфи югарылыктан карап табигыйлек, гадәтилек буларак бәян итә. Шигырьдәге «Дәрийг, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!!!» дигән юллар укучыны абстрактлыктан арындыра, һәркемне үз тормышы, кылган һәм кылачак гамәлләре, яшәү мәгънәсе турында уйланырга мәҗбүр итә.

Шагыйрь үзе дә үткән гомер, кичкән яшьлек турында уйлана, кеше гомеренең вакытлы гына булуын да һәрвакыт күңелендә тота. Вакыт-вакыт дөнья фанилыгы, гомер кыскалыгы, яшәеш кануннарының бик тә кырыс булуы аркасында, тормыш рәхәте бик чикләнгән булудан зарлана.

Әмма дөнья фанилыгы Дәрдемәнд өчен һич тә тулаем пессимистик хисләргә сәбәп түгел, ул аның табигыйлеген, кичектергесезлеген аңлый, шуңа да фаҗигалылык күрми. Киресенчә, гомер бик кыска, яшәү – бәхет, дигән нәтиҗә сизелеп тора.

Кеше гомерендәге үзгәрешләр, килеп-киткән байлык, дәрәҗәләр уфтануга сәбәп түгел, бары мәгънәле, матур итеп яши белергә кирәк. Менә шулар аша Дәрдемәнд яшәеш принципларын, тормыш кануннарын билгели: ата-анага мәрхәмәт кыл, изгелек үзе балаларыңнан кайтыр («Нәсыйхәт»), югарыга таш атма, сине кирәксенмәгәннәр арасына үзеңне мәҗбүриләмә («Беренче апрельдә зыярәт портретын җибәргән дустыма»), тормыш каккан дулкында йомычка булма, дөньяны үз кулыңда тотарга тырыш (Нәсыйхәт»), алга карап эш йөрт («Багып алдыңны күр...»), беркемне дә рәнҗетмә, ятимнәр күңелен кырма, бил алышсаң, үз тиңең белән алыш («Зәгыйфь кырмыскамын мин...», «Кыйтга»), яхшыга яхшы, начарга начар бул («Түгел лаек...»), тормышың бик үк җиңелдән булмаса да, үз артыңнан башкалар күңелен яктыртырлык эш калдыр:

*Караңгы төн исә якын, ераклар,*
*Хазин калбемне (кайгылы күңелемне) вакла – як чыраклар;*
*Гарипләр (зарлылар) шәмчыраг күргәндә юлда,*
*Дисеннәр, бер заман бар булган ул да...* («Кыйтга»)

Гаделлек, киң күңеллелек, үзеңнән соң изге эшләр калдыру, башкалар күңелен күрү, табигать кануннарын, үзеңнән өлкәннәр тәҗрибәсен кабул итү кебек матур сыйфатларны ул үзенең чәчмә әсәрләрендә дә үзәккә куя. «Кояшның нурлары», «Богдай», «Бер хәзинә», «Нури белән Зәйнәп» кебек кечкенә хикәяләре яшь буынга матур тәрбия бирү максатын күздә тотып язылган.

Дәрдемәнд үзен татар халкының бер вәкиле итеп саный һәм моның белән горурлана. Туган-үскән җир аңа ата-ана йортыннан да кадерлерәк *(Ата-анам йорты өчен Булса мең җаным фида; Туган үскән җирем өчен соң тамчы каным фида),* милләте белән аны сөт һәм кан кардәшлеге берләштерә. Дәрдемәнд иҗатында туган җир, газиз милләт һәм тел – иң изге нәрсәләрдән. Нашир, химаяче, депутат буларак гел милләт мәнфәгатьләрен кайгырткан шәхес, шигъриятендә дә милләт һәм тел мәсьәләләрен үзәккә куя. «И мөхәррир» шигырендә ул телне сөт туганы, дус, иптәшем дип атый, телнең грамматикасын, эчке төзелешен чит телнекенә якынайту, шул калыпка салуны телнең рухын харап итүгә тиңләштерә. Телнең асылын саклау юлында сүзләренең генә көче җитмәсә, күз яшьләре белән якларга да әзерлеген бик гади, үтә образлы итеп әйтеп бирә:

*Максадың гәр хәер исә куй, тимә тел тәркибенә!* (телнең синтаксисы, җөмлә төзелешенә)
*Сөт имешкән һәмдәмемдер* (сөт туганым), *кан әнисемдер телем,*
*Җан биреп күнмәм хәрим, васылдан тәгъбиренә* (нигезеннән читләштерелүенә).
*Мөддәгыйләр рәддена* (дәгъвачыларның сүзен капларга) *гәр җитмәсә сүзем дәлил,*
*Түккәнем күз яшьләрем җитсен алар тәэдибенә* (аларны әдәпкә чакырырга).

Шагыйрь, XX гасыр башында Россияне тетрәткән иҗтимагый үзгәрешләргә битараф кала алмый. Дәрдемәнд инкыйлабны, һәрнәрсәгә салкын акыл белән, тарих тәҗрибәсенә таянып бәя бирүче буларак хупламый. Шулай да, кеше, дөнья һәм вакыт мөнәсәбәтләренә фәлсәфи югарылыктан караганлыктан, ул тарихның җимерү этабына кергәнлеген һәм моның кичектергесез икәнлеген, бу агымга каршы йөзүнең файдасызлыгын аңлап эш итә.

Дәрдемәнд – буржуазия вәкиле. Инкыйлаб дулкыннары бу сыйныфны да, йөзгә якын алтын приискаларының хуҗасы, миллионер-алтынчы Дәрдемәндне дә аямаячак, шагыйрь күңеле белән моны сизә, бу хакта кайта-кайта уйлана, дөрес нәтиҗәләр ясый. Иҗатының бер өлешендә зур эшләр башкарырга теләге, мөмкинлекләре булып та, читкә тибәрелгән, бәяләнмәгән затның күңел сызланулары урын ала. Туган-үскән илләрдән искән җилләр дә («Гарип моң»), «ерак диңгездә кышлар кичергән агымсу» да («Агымсу») аның өчен гарип (сәер, аңлаешсыз) моңнар китерә.

Ил һәм шагыйрь язмышындагы фаҗигалылык, тарихи хакыйкать аның берничә шигырендә аеруча калку гәүдәләнә. Аларның беренчесе – «Кораб». Әсәр турында тулаем фикер инде күптән формалашкан: инкыйлаб җилләре кубарган дулкыннар эчендәге татар иле корабының билгесезлеккә төренгән котылгысыз язмышын гади һәм иң төгәл чагыштыру аша әйтеп биргән шагыйрь:

*Чыкты җилләр,*
*Купты тулкын –*
*Ил корабын җил сөрә!..*
*Кайсы юллар,*
*Нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?!.*

Шигырь мәгънәсен шәрехләүдә күп вакыт шушы дүртьюллыкка таянабыз. Ләкин Дәрдемәнд «Юл бара ят ил карап» дип, фаҗиганың сәбәбен алдарак күрсәтә. Ул үзгәреш зарурияten аңлый, тарихның котылгысыз бер һәлакәткә якынлашуын тоемлый, шул сәбәптән өзелеп-өзелеп сызлана. Күңелендәгесен ачыктан-ачык ярып салуда да мәгънә күрми, беләә: буржуазия сыйныфы вәкиле буларак аны аңламаячаклар, үзе өчен зар елаучы, инкыйлабны кире кагучы буларак тәнкыйть утына тотачаклар. Шуңа Дәрдемәнд күңелендәгесен турыдан-туры түгел, күп урында символлар аша сурәтләүгә, эчке мәгънә йөген арттыруга күчә. Шагыйрьнең җан фаҗигасын гәүдәләндергән «Бүзләрем мана алмадым» шигыре образ-символлар, эчке мәгънә, сүзләр сайланышы, шигъри төзелеше һәм аһәңлелеге ягыннан да камиллек үрнәге саналырлык.

Татар халкында кешенең кимсетелү дәрәҗәсен, бәһасезлеген күрсәтү өчен фразеологизм булып калыплашкан «исәпкә-санга алмау», «искә-санга тыкмау», «санга сукмау», «санламау», «исәптә бар, санда юк» тезмәләре кулланыла. Милләт өчен җаны өзелеп тә, аның бәяләнмәвен шагыйрь дә «бар саналса да, сан алмау» дип бәяли. Илдә яшәп, халык тарафыннан танылмавы (эшләренең тиешле бәя алмавы), милләт өчен янып яшәп тә, яндыга саналмавын, ул язмышның сул кулыннан «бер сынык нан (икмәк)» да ала алмауга тиңли.

Мөселман уң кулын дин кардәшенә суза, чит дин вәкиленә икмәкне сул кулы белән бирә. Шагыйрь менә шул чит итеп кенә бирелә торган өлештән дә мәхрүм.

Ул ил эчендәге һәр сүзгә колак салып, үзен аңлауларын, җан тынычлыгы алырлык хәбәр көтә, әмма күңеле ләззәтләнерлеге генә юк:

*Исте җилләр ил эченнән,*
*Иртә-кич салдым колак.*
*Җил-җиләсләрнең моңыннан*
*Зәүкы әлхан алмадым.*

Бу бәхетсезлегенең сәбәпләрен дә төшенә, затлы шәхесләр бәяләнмәгән илдә яшәгәнен аңлый ул:

*Әйттеләр, кем, бер бәхетсез*
*Илгә гашыйксың, фәкыйрь,...*
*Ник таныйм – таналмадым.*
*Ник таныйм?.. Таналмадым.*

Дәрдемәнд инкыйлаб тудырачак аянычлы нәтиҗәләрне тулысынча күз алдына китерә алмый. Аның күңелендә илнең ихлас бәясенә ирешү теләге яши. Хаҗга баручылар кәфеннәрен Зәмзәм чишмәсендә манган кебек, ул да, бу дөнья белән бәхилләшкәндә генә булса да, милләтеннән аңлау табуга – кәфенен милләт коесында мануга өметләнә.

*Биэре милләт, маэи зәмзәм,*
*Күзләдем еллар буе, …*

Әмма ни аяныч, кәфен бүзләре манылмаган килеш кала:

*Җитте дәфенем вакыты* (күмелер вакытым),
*Кәфенем бүзләрен маналмадым.*
*Вәйла* (үкенеч)!..
*Дәрийг* (аяныч)!
*Бүзләрем маналмадым!!*

«Гөрләгән сулар башында» шигырендә ул «Кораб» һәм «Бүзләрем мана алмадым» шигырьләрендәге күңел сызлануларына фәлсәфи югарылыктан торып нәтиҗә ясый. Дөнья буйлап таралган милләтебезне, нинди ватанда яшәвенә карамастан, сөт һәм кан берлеге үзара якынайтып, берләштереп саклаячагына ышаныч белдерә. Ил, халык язмышындагы фаҗиганы, үзенең шуларга каршы тора алмас дәрәҗәдә көчсез икәнлеген аңлап, күңел төшенкелегенә бирелгән вакытларда да, рухын күтәрерлек таяныч эзли:

*Ни газизрәк – бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкаддәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!..*

Халкыбызның якты киләчәгенә өметен югалтмаган хәлдә ул туган җире, тормышының бәхетле мизгелләре белән бәхилләшә:

*Тәгәрәп, уйнап*
*Буй үскән*
*Туган илем, исән бул!*
*Чәч кузгатып,*
*Җай искән*
*Таңгы җилем, исән бул!*
*Йөгереп-йөгреп*
*Туктаган...*
*Яулык болгап*
*Сыктаган*
*Нәзкәй билем, исән бул!*

1921 елның 9 октяберендә үзе дә дөнья белән хушлаша. Закир Рәмиев – Дәрдемәнд Орск шәһәре янәшәсендәге Ильяс авылы зиратына җирләнә. Вакытлар үтү белән каберстан хәрби завод биләмәсенә әверелә, анда-монда күчеп йөри торгач, Дәрдемәнд кабере өстеннән кузгатылган кабер ташы да юкка чыга.

XX гасыр башы милли яңарышын тудыручыларның берсе булган бөек шәхес, шагыйрь, нашир, химаяче Дәрдемәнднең тууына быел 165 ел. Бакыйлыкка күчкәненә дә бер гасырдан артык, кабере югалса да, аның иҗатын да, милләте өчен кылган изге гамәлләрен дә халкыбыз күңел түрендә йөртә, рухына сеңдереп саклый.

**Әдәбият**

*Бәшири З.* Рәмиевләр турында истәлекләр // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни биографик җыентык. Казан: Рухият. 2002. 367 б.

*Кәрими Ф.* Дәрдемәнд // Дәрдемәнд әсәрләре. Казан: Яңалиф, 1929. 108 б.

*Мәрданов Р.* «Шура» журналы һәм Рәмиевләр // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни биографик җыентык. Казан: Рухият. 2002. 367 б.

*Сәгъди Г.* Дәрдемәнд // Бертуган Рәмиевләр: Фәнни биографик җыентык. Казан: Рухият. 2002. 367 б.

*Хәмидуллин Л.* «Татар уянсын дисәң…» // Кичке шәфәкъ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 254 б.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 930.1

*Э.К. Сәлахова*

# Г. ИСХАКЫЙ ҺӘМ АНЫҢ ЗАМАНДАШЛАРЫ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Конец XIX – начала XX века в истории татарского народа характеризуется временем осмысления своего прошлого, размышления об исторических и культурных вопросах, определения основных задач развития. Параллельно с проблемами стратегии развития идентичности ставится вопрос о её сохранности. Татарский публицист и писатель Г. Исхаки в своем труде «Ике йөз елдан соң инкыйраз» («Исчезновение через 200 лет») подчёркивает о существовании проблемы не только развития национальной идентичности, но и о назревании вопроса ее сохранения. Он через литературный образ предупреждает о возможных последствиях при несоблюдении некоторых правил сохранения самобытности.

Впервые «Исчезновение через 200 лет» автором исследования рассматривается не как литературное произведение, а как аналитический труд публициста на насущную проблему современности. В данной статье анализируются размышления Г. Исхаки о признаках исчезновения, а также его план на сохранение и развитие нации. Автор статьи сравнивает и показывает мнения его современников на данную проблему, также подчеркивается их солидарность или не восприятия некоторых суждений Г. Исхаки.

**Ключевые слова:** нация, национальная идентичность, сохранение национальной идентичности, Г. Исхаки, Г. Губайдуллин, Дж. Валиди, история татарского народа.

The end of the XIX – beginning of the XX century in the history of the Tatar people is characterized by a time of reflection on their past, reflection on historical and cultural issues and determination of the main tasks of development. In parallel with the problems of the identity development strategy the question of its preservation is being raised. Tatar publicist and writer G. Iskhaki in his work “Disappearance after 200 years” emphasizes the existence of a problem not only of the development of national identity but also of the maturing issue of its preservation. Through a literary image he warns of possible consequences if certain rules of preserving identity are not observed.

For the first time “Disappearance after 200 years” is considered by the author of the study not as a literary work but as an analytical work of a publicist on an urgent problem of our time. This article analyzes G. Iskhaki’s reflections on the signs of extinction as well as his plan for the preservation and development of the nation. The author of the article compares and shows the opinions of his contemporaries on this problem and also emphasizes their solidarity or lack of perception of some of G. Iskhaki’s judgments.

**Keywords:** nation, national identity, preservation of national identity, G. Iskhaki, G. Gubaidullin, J. Walidi, the history of the Tatar people.

Халык формалашу һәм аның үсеше берничә этапта бара. Инсаннар[1] җыены гына булудан бигрәк, халыкның милләт булып формалашуы – аның үсешен билгели, ә үсеш югарылыгы ул – аның миллият дәрәҗәсенә күтәрелүе. Милләтнең инсаниятә үз урынын табу, аның үсеше, камилләшүенә халык үзе шартлар тудырырга, алга бару, үзен саклау өчен гамәл кылырга тиеш. Милләт ничек кенә үсмәсен, хәяты нинди шартларда булмасын, тарихның төрле этапларында аны милләт буларак саклау проблемасы килеп туачак. Бу мәсьәлә ике яссылыкта каралырга тиешле: беренчедән, милләтнең үз эчендәге бөтенлеген саклау, икенчедән, аның иҗтимагый-сәяси пространстводагы урыны, үз урынын табуы, шушы шартларда яши алуы.

XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар халкы милләт буларак формалашып килгән, милләт төшенчәсен ачыклаган чорда милләт булу өчен нинди билгеләр кирәклеге хакында фикерләр әйтелә, бәхәсләр бара. Әмма озак та үтми икенче зур проблема – милләтне, халыкны саклап калу, аның үсеш юлларын билгеләү мәсьәләсе килеп баса. Моның хәтта бер үк вакытта көн проблемасы булуы да күренә. Шул ук вакытта үсеш перспективаларын билгеләгәндә, юкка чыгу куркынычыннан саклану юллары турында да фикерләшү бара.

Мәгълүм булганча, татар дөньясына ысулы җәдит хәрәкәте килеп кергәч, җәмгыятьтә үзгәрешләр, яңалыклар күренә башлый. Татар тарихында 1885–1905 еллар аралыгын, гадәттә, уңышларга ирешкән, җәмгыятьнең югары ноктага җиткән чоры дип бәяләргә гадәтләнелгән. Җ. Вәлиди, милләт тормышына бәя биргәндә, бу вакыт аралыгын бары милли аң тууга әзерлек дәвере буларак гомумаң туган чор дип кенә бәяли. Ысулы җәдит татар миллиятенең нигезе булган милли әдәбият, милли музыка, милли сәнгать, милли фикерне тудыра алмады, ул бары тик булган хаосны тәртипкә генә салды, дип яза [Вәлидев, 2010, б. 37–42]. Бер яктан караганда, бу – милләт әле формалашып кына килгән, алга баруга юнәлешләр генә сайлаган чор.

Ә Г. Исхакый XX йөз башында ук инде милләтнең бетү, юкка чыгу куркынычының реаль шартларын күрә. 1902–1904 елларда Г. Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен язган икән, бу үзе үк проблеманың җитди куелуын дәлилли. Милләт хәятының юлын төгәл этапларга аерып карау мөмкин түгеллеге ачыклана, ягъни барлыкка килү, формалашу, үсеш һәм юкка чыгу арасында ачык чикләр булмаска да мөмкин. Бу процесслар еш кына бер-берсе белән үрелеп бара. Г. Исхакый милләтнең алга барышы, аның үсеше, ирешкән уңышларыннан эйфориядә булмыйча, инде бетү, юкка чыгуга китерергә мөмкин булган моментларны да барлый башлый. Аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы – иҗатының башлангыч чорында язылуга карамастан, тирән фикерле, ничә гасырдан соң барлыкка киләчәк вазгыятькә күрәзәлек иткән әсәр [Исхакый, 2019, б. 48–165]. Ул проза әсәре формасында тәкъдим ителсә дә, язучы – галим, тарихчы,

[1] Инсаннар – кешеләр.

сәясәтче һәм милли хадим буларак чыгыш ясый. Бу әсәрне милләтнең үсеш стратегиясенең әзер проекты итеп кабул итәргә дә буладыр.

Г. Исхакый әлеге әсәрендә заманы өчен бик четерекле теманы күтәрә, бу вакытта инкыйраз проблемасын кую, аны тоемлау – үз өстеңә зур җаваплылык алу ул. Г. Гобәйдуллин билгеләвенчә, Г. Исхакый «Әгәр татарлар болай барсалар, милләтнең мөнкарыйз булуын[1]» күрсәтергә тырышкан [Газиз, 1911, б. 4]. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» – шул заманның яңалыгы, әмма Г. Гобәйдуллин бу хезмәтнең буш җирдә генә барлыкка килмәвен билгели, Г. Исхакыйга дөнья әдәбиятында инде бу проблеманың булуы, куелуы тәэсир иткән, ди, һәм аның шушы ук куркынычның татар җәмгыятенә дә янавын «хыялый роман» рәвешендә тәкъдим итүен яза. Г. Исхакыйның бу әсәрен тарихчы «иҗтимагый романыбыз» дип атый [Газиз, 1911, б. 3–4]. Әлеге әсәр татар дөньясында ничек кабул ителгән соң? Замандашлары аны ничек каршылаган? Бу әсәргә рецензия рәвешендә махсус язма багышлаган Г. Гобәйдуллин язуынча: «Берничек тә каршыламады. Укырга өйрәнгән, матурлыкны аңламаган татарлар галәме бик тыныч кына каршылады. Хәтта беренче басмасы һаман китапчыларда сатылып беткәне юк дип, бик кыска гына җавап бирергә мәҗбүр буламыз» [Газиз, 1911, б. 4]. Хәтта әсәргә тәнкыйть сүзе әйтерлек кешенең дә булмавына борчылып яза ул, бары тик Й. Акчураның гына «Тарих вә голүм» исемле язмасында бер җөмлә белән генә кагылып үтүен билгели [Газиз, 1911, б. 4]. Г. Исхакый романын язган вакытта әле милләт проблемалары, аларны фәнни яссылыкта карау булмый, Г. Исхакый күтәргән мөһим мәсьәләне аңлау, аны анализларлык катлау соңрак формалаша. Халык арасында барган бәхәсләрне, борчуларны, гомумиләштереп, бер калыпка кертү максатыннан 1913 елда «Аң» журналы битләрендә Г. Гобәйдуллин 15 сораудан торган анкета бастыра һәм үзе дә, шушы сорауларга җавап йөзеннән, зур мәкалә белән чыга [Сәлахова, 2024, б. 11–29]. Г. Гобәйдуллин 1913 елда «Милләтне ничек аңлыйсыз?» дигән мәкаләсендә «Хәзерге көнемез хәсрәтле, ләкин үткәндә вакыт, киләчәктә нур күрәм», – дип яза [Газиз, 1913, б. 394; Гарипова, Әхмәтова, б. 143].

Г. Гобәйдуллин бу хәлләргә оптимистларча карап, киләчәккә өмет белән килсә, Г. Исхакый бу мәсьәләдә шактый катгый булган. Әдип «“Ике йөз елдан соң инкыйраз”ны язудан мәкъсудым – милләтемезнең шул китешеннән үземнең разый түгеллегемне күрсәтеп, бу китешнең очы инкыйраз идекене белдерүдер» [Исхакый, 2019, б. 48], дип ассызыклый. «Кайбер кешеләр милләтебезнең шул китешен бик файдалыга санап, шул китештән бик зур өметләр дә көтәләр. Әмма мин һич андый өметләр көтәрлек “төпле” сөйләнә торган сүзләргә, эшләнә торган эшләргә вакытлы килгән “бизгәк” дип кенә карыйм» [Исхакый, 2019, б. 48], дип шатлыкка чумып, реаль халәтне күрергә онытмаска кирәклеген җитди тон белән язарга мәҗбүр була.

[1] Мөнкарыйз булуыдыр – юкка чыгуыдыр.

Г. Исхакый – бу әсәре аша үз чоры татар җәмгыятендәге проблемаларны башлап күрсәтүче. Алга таба бу проблемага фәнни якын килү, аны анализлау күренә. Г. Гобәйдуллин милләт һәм миллиятнең формалашуын, үсешен һәм аның тормышында булган проблемаларны яктырта [Сәлахова, 2022, б. 457–467]. «Милләт вә миллият» исеме астында бу проблеманы анализлаган гыйльми хезмәт «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме Җ. Вәлиди тарафыннан 1914 елда Оренбургта аерым китап булып басылып чыга [Вәлидев, 1914]. Без аны озак еллар барган полемикага бер йомгак рәвешендә эшләнгән теоретик хезмәт буларак беләбез. Ул милләт һәм миллиятне билгеләүче факторларны да барлый һәм шул ук вакытта аерым бер шартларны күрсәтеп, милләтнең язмышы ничек булачаган да билгели.

Җ. Вәлиди тел, дин, кан, ганганә[1] һәм ватан берлеген бер милләт буларак кешеләрне бәйләп торган факторлар, шулар арасында тел, әдәбият, дин һәм игътикадны[2] иң көчлеләре дип күрсәтә. Боларны ул милли әсаслар[3] дип атый, әмма алар миллиятнең барлыкка килүен, оешуын билгеләсәләр дә, аның үсешен гарантияләмиләр [Вәлидев, 2010, б. 45]. Милләтнең тормышы, үсеше (тәрәккыяте) өчен гыйза[4] кирәк. Алар – Җ. Вәлиди фикеренчә, гыйлем, мәдәният, әхлак һәм һөнәр. Шулар бергә гармониядә булганда милләтнең үсешенә куәт бирәләр, ягъни милләт үсешкә ирешә ала. Бу шартлар бары тик бер милләткә генә хас билгеләр (шартлар түгел), алар бар кешелек дөньясы – инсаният үсеше өчен шарт, болар милләт үсешенә куәт биреп, ярдәм итсәләр, шушы ук шартлар үтәлгәндә, миллиятне киңрәк даирәгә алып чыгалар, ягъни үз эченә бикләнеп үсү генә түгел, үзүзенә соклану түгел, ә милләтләр арасындагы диалогка китерәләр, ягъни миллият үсешен югары дәрәҗәгә куялар [Вәлидев, 2010, б. 37–87].

Г. Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да халык тормышындагы нәкъ менә шушы моментларның инде проблемалы булуын, милләт нигезе компонетларының зыян күрүен халык хәятындагы мисаллар белән, халыкка аңлаешлы итеп проза әсәрендә бирә алган [Исхакый, 2019, б. 48–165].

Г. Гобәйдуллин Г. Исхакый әсәрен анализлап, инкыйразның матди һәм мәгънәви сәбәпләрен атый. Беренчесе – икътисади сәбәп, аны сәүдәдә, һөнәрчелектә камилләшмәү һәм татарларда җир азлыкта күрә. Бу – татар тормышында хәлиткеч роль уйный торган фактор, чөнки җир азлык татар кешесен үзенә чит булган тирәлеккә китәргә мәҗбүр итә. Икътисади сәбәп турыдан-туры милләтнең әхлак проблемасын тудыра. «Вакыйган, бу әхлак, вөҗдансызлык башлануын мөхәррир инкыйразның баш сәбәпләреннән таный» [Газиз, 1918, б. 1–2].

[1] Ганганә – традиция.

[2] Игътикад – ышану, инану.

[3] Әсаслар – нигезләр.

[4] Гыйза – азык, туендыручы.

Милләт үсешенең төп шарты – гыйлем. Гыйлем – мәктәп-мәдрәсә, мөгаллимнәр, җәмгыятьнең авторитетлы кешеләре. Әмма бу чорда Г. Исхакый татар җәмгыятендә бу өлкәне иң проблемалысы дип саный. Милләт язмышында хәлиткеч роль уйнарга тиешле, милләтне саклаучы булырга тиешле «голәма[1]» катламының бу вазифаны һич тә үти алмавын тәнкыйтьли.

Үзләрен «голәма» итеп күрәләр икән, алар халыкны тәрәккыяткә алып барырга тиешләр, әмма, аның сүзләре белән әйткәндә, «голәма» сыйныфының иң алда «кылычын тотып», наданлыкны саклавы күренә, ул аларны хәтта инкыйразны тизләтүчеләрдән дип саный. «Голәмаларга булган зур ышанычыбыз, әмма аларның шул эшләрне эшләргә сәләтле түгеллеген белә торып, шулкадәр мөкаддәс эшләрне аларга тапшыруымыздандыр» [Исхакый, 2019, б. 49], милләт үсешен билгели торган мәктәп-мәдрәсәләрнең юклыгы, бу уку йортларының эшенә әһәмият бирмәвебезне манигы тәрәккыянең[2] бер сәбәбе итеп күрсәтә. Булганнарының сыйфат дәрәҗәсе милләт өчен хезмәт итәрлек хәлдә түгел, мәдрәсәләрне тәмамлаган шәкертләрнең зур күпчелеге милләтнең башчысы булу урынына, чынлыкта, бер эшкә ярамый торган кеше булып чыгалар, дип яза. Мәдрәсәләрдә укып чыккан муллаларның милләткә файдасы булырлыклары, аның фикеренчә, бары тик 5% кына тәшкил итә.

Беренчедән, белемсезлек, җәмгыятьнең консерватизмы халык үсеше өчен киртә булса, икенчедән, ул – «үземезне голәманың тәхет коллыгыннан коткарып, һәр хәрәкәтемездә хөр булмактыр», аның гасыр башында әйтелгән әлеге сыйнфый ризасызлыгы алга таба сәяси эшчәнлегенең үзенчәлеген дә билгели. «Милләтемездәге эшкә ярарлык кешеләрнең һәм хезмәт итә торганнарның бик фәкыйрь сыйныфтан чыгып, үзләренең тамакларын туйдырыр өчен, милләткә хезмәт итәр урынында иң түбән кешеләрнең коллыгында изелүләредер» [Исхакый, 2019, б. 50]. Г. Исхакый нәкъ менә шушы факторны үсешкә иң зур киртә итеп исәпли, ягъни матди файда беренче планга чыга икән, андый юлбашчы милләт өчен түгел, ә үзенә гомер буе җитмәгән, хыялланган мал турында уйлаучы гына була, андый кеше рухи югарылыкка күтәрелә алмый.

Татарның шул чордагы тагын бер бәласе – бертуктаусыз дини ваклыклар турында бәхәсләшү, үзләрен «голәма» дип атаганнарның башкалар фикерен ишетергә теләмәве. Җ. Вәлиди дә, Г. Губәйдуллин да халыкның милләт булып формалашуында диннең роле хәлиткеч булуын дәлиллиләр [Вәлидев, 1914; Газиз, 1918], әмма шунысы хак, дини проблемалар турында бәхәсләшәбез икән, бәхәс гыйльми дәрәҗәдә булырга тиеш, шул вакытта гына ул гомуммилләт файдасын күздә тота. Г. Исхакый мулла гаиләсендә туган, шул даирә белән аралашып яшәгән кеше буларак, ихтирамлы мөнәсәбәт белән бергә, мил-

[1] Голәма – галим.

[2] Манигы тәрәккыя – үсешкә киртә.

ләт тормышына зыян салырлык гамәлләре өчен бу даирә кешеләренә шактый кискен җавап та бирә [Исхакый, 2019, б. 50].

Г. Исхакый шактый тәнкыйди фикер йөртеп, эшләгән эшләрнең дә күбесе төпсез, нигезсез дип саный. Бер эш бүген булса, икенче елга юк, ягъни системалылык булмауны ул милләтнең зур проблемасы итеп күрә. Моннан кала, җиңел һәм бик тиз нәтиҗә көтү. Милләтне үстерү, аны саклау юлы шул чор шартларында җиңел һәм тиз була алмауны аңлау кирәклеген искәртә. «Агачтан җимеш алыр өчен аны орлыктан сачеп, һәркөнне никадәр хезмәт сарыф кылып, ничә еллар тырышканнан соң гына максудка ирешәләр» [Исхакый, 2019, б. 50]. Милләтнең зур хаталануын ул зур чыгымнар тотып, күз буяр өчен эшләнгән буш эшләрдә күрә, аларны «курчак туе» дип атый. Эш эшлисең икән, бер гасырдан соң да, берничә гасырдан соң да аның өчен оят булмасын. Максатсыз эшләнгән эшләрнең эшләмәгәнгә караганда да зыяны зуррак булу ихтималы бар: «эшләгән эшләремезнең ни өчен, ник икәнлеген белмәенчә кылуыбыз – болгарларның искедә калган табигатедер. Әгәр дә бу табигать бездә булмаса иде, белмим, без хәзер нинди милләт булыр идек икән?» [Исхакый, 2019, б. 50], дип яза. Әмма язучының әсәренә анализ биргән Г. Гобәйдуллин аның бу кискен тәнкыйди сүзләрен өнәп бетерми һәм болай ди: «Элек сөйләп, язып, җәмгыятьне өйрәтергә кирәк, элек аларда “бизгәк” калтыраулары ясарга, кыздырырга кирәк, менә шул кызулар гына акырын, сабиранә эш күрсәтергә юл ачачаклар» [Газиз, 1918, б. 12].

Г. Исхакый җәмгыятькә инкыйраз билгеләре буларак белемсезлек һәм әхлаксызлык күренешләрен кертүне милләтнең киләчәген шик астына куя торган факторлар дип саный. Халыкның медицина буенча элементар белемне дә кабул итәргә теләмәвен билгеләп, «“Алла сакласа, берни булмас әле” белән инкыйраз орлыгын чәчәләр», дип яза. Медицинага җитди карамау демографик проблема тудыра. Милләтнең инкыйразына демография зур сәбәп була ала. Алга таба бу факторлар башка авторларның хезмәтләрендә дә инкыйразга китерүче сәбәп буларак күрсәтелә [Исхакый, 2019, б. 90].

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» – милләтнең бетүе турында язылган пессимистик әсәр түгел, Г. Исхакый үсеш стратегиясен булдырганда нинди моментларга игътибар итәргә, нинди хаталар ясамаска кирәклеген бәян итә. Ул нинди юнәлештә эшләргә кирәклеге хакында инструкция дә була ала. Иң мөһиме – бу роман конкрет чор проблемаларын яктырткан шул заман әсәре генә түгел, ә милләт тормышының һәр дәверендә халыкны тонуста тотардай кисәтү дә.

Әсәрнең төп максаты – милләт үзен ничек саклап кала ала? дигән сорауга җавап табу. Беренчедән, Г. Исхакый фикеренчә, мәктәп, белем – милләтне саклаучы факторлар. Икенчедән, ул хатын-кыз белеме һәм тәрбиясен милләтнең нигезе дип атый: «Һәр милләтнең яртысы хатыннар, һәр милләтнең рухын саклаучылар – хатыннар, һәр милләт теленең аерым әйтелешләрен, сөйләшен саклаучылар – хатыннар, киләчәктә ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия

кылучылар хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер мәсьәлә булгач, минемчә, аларны тәрбия кылырга кирәкме, йә юкмы мәсьәләсе һәркемгә җавап бирерлек бер нәрсәдер» [Исхакый, 2019, б. 74]. Өченчедән, татар рухында музыка һәрвакыт булса да, аны мәдәният дәрәҗәсенә үстермәү милләтнең киләчәгенә зыян салуын күрә һәм «әдәбият һәм музыка милләтнең атасы белән анасы икәнлеге һәркемгә мәгълүм, язучы, образлы итеп, әдәбият белән музыкага бергә тору, никахлы булу тиешле» [Исхакый, 2019, б. 84], дип яза. Бары тик алар бергә вакытта гына милләт өчен нәтиҗә матур булачак.

Г. Исхакыйның замандашы Җ. Вәлиди шушы фикерләрне ассызыклап, милләтне саклап калуда стратегия буларак ике ноктага карап эш итәргә чакыра. Беренчедән, миллиятне сакларга. Бу очракта «кәләпүш белән комганны саклау турында» сүз бармый дип, бу проблеманың бик җитди һәм тирән икәнлеген искәртә. Аның фикеренчә, миллият дигәндә төп нигезләрне – әсасларны – тел, әдәбият, дин һәм игътикадны сакларга. Моның өчен милли мәктәп, милли әдәбият, милли сәнгать булырга тиешлегенә басым ясый [Вәлидев, 2010, б. 54].

«Ике йөз елдан соң инкыйраз»да Г. Исхакый милләтнең тагын бер манигы тәрәккыйсы (үсешкә киртә) итеп, татар балаларының рус мәктәпләрендә укырга атлыгып тормауларын атый. Бу турыда шул чорда иҗат иткән күп авторлар яза. Моны, проблемага киңрәк карап, милләтнең башка мәдәниятне өйрәнергә, диалогка ачык булырлык дәрәҗәгә җитүе дип аңларга кирәк. Бу чорда татар җәмгыяте өчен күрше мәдәният – руснныкы. Әдипнең әлеге фикере аша, милләтнең бөтенлеген эчтән саклауны гына түгел, ә башка мәдәниятләр белән бәйләнештә, алар белән бер дәрәҗәдә яраклашып яши алу югарылыгына күтәрелү проблемасын аңлыйбыз. Шул ук Җ. Вәлиди дә милләт үсеше өчен татарга Русия мәмләкәтенең чын бер гражданины булу кирәк, дип саный. Ул милләтнең нинди шартларга эләгүен исәпкә алып, «без берьюлы ике камыт киярга тиешбез», дип яза. Г. Исхакый да, башка зыялы затларыбыз да бу проблемага реаль шартлардан чыгып карап, стратегия булдыруның милләт өчен отышлырак икәнлеген ассызыклыйлар. Җ. Вәлиди татар өчен «Татарлык һәм Русия гражданлыгы» бердәмлеген билгели: «Бу ике сүзне бергә китереп, бер кавычка эченә кертеп язу бик ансат, әмма хәятта бунларны бергә оештырып саклау, бер муазәнәттә (тигезлектә) алып бару, бусы ул кадәр ансат түгел. Интибаһ[1] вә тәҗәддед[2] хәрәкәте башланганнан бирле, безнең башымыз шуның илә ватыла, безгә ничек бу ике камытны киярга кирәк, ничек шуның илә бу биек тауга, буылып егылмыйча, менеп җитәргә кирәк» [Вәлидев, 2010, б. 74], ди.

XX йөз башында милләтне саклауда инде сәяси яссылык күренә башлый. Беренче чорда Г. Исхакый милләтнең үз эчендәге бөтен-

[1] Интибаһ – уяну.
[2] Тәҗәддед – яңару.

леген саклау проблемасын кайгыртса, алга таба инде Русия дәүләте шартларында милләтнең сәяси урыны, аның хокуклары өчен көрәшкә күтәрелә [Чыңгыз]. Г. Исхакый инкыйлаби фикер йөртүче буларак милләтнең сәяси, икътисади һәм мәдәни үсешен Европа тәэсирендә Россиядә барган инкыйлаби күтәрелешләрдән, мәдәни эволюциядән кабул итеп алырга теләүчеләр рәтендә [Исхакый, 2011, б. 11]. Шул чорның сәяси рәһбәрләреннән С. Максуди милли яңарыш, милли үсеш иң беренче урында гына торырга тиеш, алар тормышка ашырылганнан соң гына, барлык милләтләр (шул исәптән, хаким милләт булган руслар да) ирешергә тырышкан социаль тигезлеккә ирешү өчен көрәш юлына борылырга була, дигән фикердә тора. С. Максуди «Хәрәкәт миллиямезне онытып, бу мәсләккә кереп китсәк, без бетәбез, безгә куәт милли эшләремездә, хәрәкәт миллиямезгә хезмәт өчен ляземдер» [Гаффарова, 2001, б. 90], ди. С. Максуди «Милли бәйсезлеген, милли дәүләтчелеген югалткан милләт буларак, ахыр чиктә, бетүгә юл тоткан татар милләте бары тик бөтенлеген саклаганда гына гына мөстәкыйль яши алачак» [Гаффарова, 2001, б. 90], дип белдерә.

Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре чыкканнан соң, «болай да борчулы халәтебезгә бу сорау шөбһә өсти», дип яза Г. Гобәйдуллин [Газиз, 1911, б. 23]. Аның фикеренчә, милләт барлыкка килү, аның яшәеше күп факторларга бәйле, ул катлаулы организм, ул бетә дип борчылу дөрес фикерләү түгел. Милләт юкка чыкмый, әмма ул үз асылыннан китеп, башка милләт составына кереп китү куркынычы астында булырга мөмкин. Моңа каршы тору өчен «милли мөхәррирләр, милли театрлар, музыка – гомумән, милли сәнгать нәфисия тудыралар, мөмкин кадәрле милли хисне куәтләп, инкыйразга каршы тору куәтен арттыралар» [Газиз, 1918, б. 30], ягъни милләтнең инкыйразын булдырмау, асылын югалтмау өчен аны югарыда аталган көчләр сакларга тиеш. «Әгәр бер милләт көрәштә җиңелсә – ул югала. Әгәр ул хәятка, заманга муафәкать кәсеп итмичә, искечә калса – ул бетә. Менә шул яктан аерым милләтләр бетәләр, мөнкариз була алалар» [Газиз, 1918, б. 30], әмма моңа карап, инсаниятә милләтләр бетмәвен яза Г. Гобәйдуллин. Инсаниятнең зур тормышында аерым милләтләрнең яшәеше, саклануы – ул аның көрәше, тырышлыгы, заманга карап эш итә белүе. Милләт үсеше, киләчәге өчен Г. Исхакый билгеләгән төп факторлар бүген дә истә тотылырга тиеш.

## Әдәбият

*Вәлидев Җамалетдин*. Милләт вә миллият // Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

*Вәлидев Җамалетдин*. Милләт вә миллият. Оренбург: Вакыт, 1914. 50 б.

*Газиз Г.* «Ике йөз елдан соң инкыйраз» Гаяз Исхаков әсәре // Газиз Г. Олуг кешеләр вә аларның әсәрләре. 1 китап. Казан: В.Е. Казаков типографиясе, 1911. Б. 1–24.

*Газиз Г.* Милләтне ничек аңлыйсыз? // Аң. 1913. № 22. Б. 394.

*Гарипова Л.Ш., Әхмәтова А.И.* Г. Газиз. Милләтне ничек тәгъриф кылырга // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 140–148.

*Гаффарова Ф.* Садри Максуди (1906–1924 еллар): монография. Казан: ДАС, 2001. 262 б.

Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт.: С. Рәхимов, З. Мөхәммәтшин, А. Заһидуллин. Казан: Җыен, 2011. 964 б.

*Газиз Г.* Милләтнең бәгъзе әсаслары. Казан: Аң, 1918. 30 б.

*Исхаков М.Г.* Ике йөз елдан соң инкыйраз: проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 478 б.

*Сәлахова Э.К.* Г. Гобәйдуллин хезмәтләрендә «халык», «милләт» төшенчәләре // Историческая этнология. 2022. № 3. С. 457–467.

*Сәлахова Э.К.* Хатын-кыз күзлегеннән милләт проблемалары (XX йөз башы) // Историческая этнология. 2024. № 9. № 1. Б. 11–29.

*Чыңгыз*. Безнең мәсләкемез һәм миллият // Таң йолдызы. 1906. 29 май.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының яңа тарих бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Бәдретдинов***

# ЯЗУЧЫ АФЗАЛ ТАҺИРОВНЫҢ «СОЛДАТЛАР» РОМАНЫ: ПРОБЛЕМАТИКАСЫ, ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНДАГЫ УРЫНЫ

Статья посвящена исследованию романа «Солдаты» («Солдатлар») Афзала Тагирова – известного татарского прозаика, драматурга, государственного и общественного деятеля первой трети XX века. Его сравнительно недолгая жизнь и творчество были связаны с одним из самых драматичных периодов в истории нашей страны. Искренне поверив в идеалы марксизма-ленинизма, он беззаветно преданно служил им, принял активное участие в установлении и укреплении советской власти, фанатично трудился на ниве народного просвещения и культуры, но, в конечном счете, стал жертвой сталинского режима. Афзал Тагиров занимает достойное место в ряду великих сынов татарского народа, творческое наследие которых после длительного забвения было возвращено народу. В статье рассматриваются духовные ценности татарского народа, направления национального возрождения, наличие неоспоримых фактов, верно обозначающих пути развития. Анализ его произведений показал, что в основе исторических произведений, действительно, лежат реальные события и факты, что тему Первой мировой войны в татарской литературе одним из первых поднял А. Тагиров. Роман «Солдаты» («Солдатлар») – это показ картин кровавых событий и неисчислимых страданий рабоче-крестьянского люда. Он, как и большинство произведений А. Тагирова, носит подчеркнуто автобиографический характер.

**Ключевые слова:** татарская литература, Афзал Тагиров, проблематика, исторические ценности, автобиографические данные, армия, солдаты.

The article is devoted to the study of the novel "Soldiers" by Afzal Tagirov, a famous Tatar novelist, playwright, statesman and public figure of the first third of the 20th century. His relatively short life and work were associated with one of the most dramatic periods in the history of our country. Sincerely believing in the ideals of Marxism-Leninism he selflessly faithfully served them, took an active part in the establishment and strengthening of Soviet power, fanatically worked in the field of public education and culture but ultimately became a victim of the Stalin's regime. Afzal Tagirov takes a worthy place among the great sons of the Tatar people whose creative heritage was returned to the people after a long period of oblivion. The article examines the spiritual values of the Tatar people, the directions of national revival, the presence of indisputable facts that correctly indicate the ways of development. An analysis of his works showed that historical works are really based on real events and facts, that the theme of the First World War in Tatar literature was one of the first raised by A. Tagirov. The novel "Soldiers" is a display of paintings of bloody events and the incalculable suffering of the workers and peasants. It like most of A. Tagirov's works is emphatically autobiographical in nature.

**Keywords:** Tatar literature, Afzal Tagirov, problematics, historical values, autobiographical data, army, soldiers.

Афзал Таһиров – шактый еллар дәвамында хикәя, повесть, пьеса жанрларында актив эшләп, әдәби мәйданда үз урынын тапкан әдип. Прозада тәҗрибә туплап, каләмен чарлаган язучының киң колачлы эпик әсәрләргә мөрәҗәгать итүе аның иҗатын чын мәгънәсендә яңа биеклеккә күтәрә. Әдип калдырган иҗади мирасның иң әһәмиятле һәм кыйммәткә ия өлешен тәшкил иткән бу әсәрләр аның язучылык куәтенең яңа сулыш алуына, халык ихтирамын казанып, югары үрләр яулавына юл сала. Узган гасырның 20 нче еллары азагыннан башлап, язучы патша армиясендә хезмәт иткән һәм империалистик сугыш уты эченә куылган халык язмышын яктырткан «Солдатлар» романын, ә 30 нчы еллар урталарында «Кызылгвардиячеләр» һәм «Кызылармиячеләр» дилогиясен иҗат итә.

«Солдатлар» романының беренче китабын әдип 1931 елда Казанда, «Яңалиф» нәшриятында бастыра. Романның икенче китабы 1933 елда, беренчесе белән берләштерелеп, шулай ук Казанда, Татиздатта басылып чыга.

А. Таһировның бу романы шул елларда ук популярлык казанып өлгерә. 1932 елда – башкортчага, 1935, 1936 елларда рус теленә тәрҗемә ителә. Роман – әдипнең татар телендә нәшер ителеп калган зур күләмле соңгы әсәре. Аның 1935–1937 елларда язылып төгәлләнгән әсәре – ике кисәктән торган «Кызылгвардиячеләр» һәм «Кызылармиячеләр» романнары фәкать рус теленә тәрҗемә ителү сәбәпле генә сакланып кала. «Кызылгвардиячеләр» 1935 елда дөнья күрә, «Кызылармиячеләр» 1935 елда тәмамланып, русчага тәрҗемәсе 1937 елда Мәскәүдә нәшер ителә, оригиналы исә язучы үзе исән чакта басылмый кала.

1933 елда «Октябрь» журналында, китап чыгу уңаеннан, язучы Давыт Юлтыйның күләмле мәкаләсе басыла. Ул: «Афзал Таһиров иптәшнең “Солдатлар” исемле зур хикәясенең беренче бүлеге империализм сугышы алдындагы патша армиясендәге солдатлар тормышын үз эченә ала. Бу темага татар әдәбиятында художество әсәре юк иде әле. А. Таһиров бу әсәре аша хәзерге укучыларның күбесенә караңгы булган, матур әдәбиятта яктыртылмаган шул тормышны бирә. Афзал Таһиров иптәшнең “Солдатлар” әсәре безнең әдәбият белән бергә, бу әсәр – безнең бүгенге өчен, бүгенге хәрәкәт өчен сабак бирә торган әсәр», – дип яза [Юлтый, б. 62–68].

Чыннан да, А. Таһиров – Беренче бөтендөнья сугышы еллары әдәби хәрәкәтендә үзәк фигура. XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбиятының иҗат принципларын үзләштереп әдәбиятка аяк баскан бу әдип, күп кенә баскычларны үтеп, критик реалист булып формалаша. Яңа революцион күтәрелеш елларында А. Таһиров прозасында мотивлар көчлерәк яңгырый, контрастлар ачыграк күренә.

«А. Таһировның иң яхшы әсәре – “Солдатлар” романы. “Солдатлар” – 1914–1917 еллардагы империалистик сугыш турында зур художестволы хроника булып тора. Әсәрдә автор патша армиясендәге солдатларның революцион аңы үсешен күрсәтә. А. Таһиров “Солдат-

лар” романында империалистик сугышның талау сугышы булуын ача, сугыш “агарткан һәм чыныктырган” кешеләрне тасвирлый», – дип яза В. Гредель [Гредель, 1957, б. 63–65].

Чыннан да, бу чорда иҗаттагы эзләнүләр яшәештәге капма-каршылыкны чагылдыру, сугыш-тынычлык мотивларын тасвирлау белән бәйле иде. Г. Халит билгеләгәнчә: «Беренче империалистик сугыш еллары яшәү һәм үлем мотивларына бәйле психологизмның капма-каршы тенденцияләрен тагын да көчәйтеп җибәрде» [Халит, 1986, б. 278]. Чорның каршылыклы идеологиясе, фикерләр бәрелеше котылгысыз рәвештә иҗат өлкәсенә дә үтеп керә. Әлбәттә, Беренче бөтендөнья сугышының прозада яктыртылу рәвеше бер төсле генә булмыйча, теманы төрле аспектлардан чыгып, хәтта капма-каршы булган карашлардан торып тасвирлаулар да күзәтелә. Шулай да сугыш дәһшәтен реалистик эчтәлектә, төрле формада күрсәтергә тырышу идеясе алгы планга чыга.

А. Таһиров та беренче империалистик сугышка әзерлекне, аның барышын, андагы солдатларның хәлен тасвирларга алына. Бу сугышның эчтәлеген, властька менеп утырган большевикларның эш стилен еллар дәвамында күзәтеп бара, мәгълүмат туплап, хакыйкый чынбарлыкны әсәрендә ачып бирергә тырыша. «Солдатлар», «Кызылармиячеләр», «Кызылгвардиячеләр» романнары – А. Таһировның автобиографик характердагы повестьлары тәҗрибәсеннән үсеп чыккан иҗат байлыгы. Әйтик, «Солдатлар» – тормыш мисаллары һәм геройларның бирелеше ягыннан «Әтрәгәләмнәр»нең логик дәвамын тәшкил итсә, калган ике роман «Беренче көннәр» һәм «Ташкын дәрья тармакларында» повестьларының аерым очраклы хәлләрен һәм мотивларын үз эченә ала.

Автобиографик әсәр булуына шик калдырмый торган үрнәкләр «Солдатлар» романында аеруча калку төс ала. Роман А. Таһиров, ягъни вакыйгаларга күзәтү ясап, комментарийлар биреп баручы авторның үзе тарафыннан хикәяләнә. Әсәрнең кайбер урыннарында Афзал яки Таһиров исеме ачыктан-ачык күрсәтеп барыла.

Беренче заттан хикәяләнүендә дә, сурәтләнгән вакыйгаларның һәм төп герой Таһиров үткән юлның язучы биографиясенә тәңгәл килүендә дә, патша армиясендәге тәртипләргә, империалистик сугыш вәхшәтләренә һәм, гомумән, тормышка герой карашының авторныкы белән туры килүендә дә, хәтта аерым персонажлар сурәтләнгән вакыйгалардан соң язмышлары турында хәбәр итүдә дә күренеп тора. Әлбәттә, автор үзенең туган авылының исеме – Габдрахманны күрсәтми, чөнки романның тәүге сәхифәләрендә күп кенә авылдашларының исемнәре, образлары һәм аларның социаль чыгышлары бәян ителә.

Автобиографик әсәрләр авторның үз тормышындагы аерым вакыйгаларны чагылдыра. Мондый язмалар язучының үз кичерешләре, үз бәяләре һәм фикерләренә таянган булу белән биографиядән аерылып тора. Шуның белән автобиография, жанр буларак, мемуарга

якын.Ләкин мемуар автор шаһит булган кешеләр һәм вакыйгалар турында, автобиография исә, күпчелек очракта мин исеменнән сөйләнгәнгә күрә, төп герой да – автор үзе. Г. Тукайның «Исемдә калганнар», М. Гафуриның «Тәрҗемәи хәлем» кебек язмалары – шундыйлар. «М. Горькийның “Балачак”, “Малайлыкта”, “Минем университетларым”, М. Гафуриның “Шагыйрьнең алтын приискасында”, М. Кәримнең “Озын-озын балачак” исемле повестьлары» да – күркәм үрнәкләр [Әдәбият белеме сүзлеге, 1990, б. 60].

Г. Нигъмәти дә А. Таһировның бу әсәре хакында: «“Солдатлар” – “Әтрәгәләмнәр”, “Беренче көннәр”, “Ташкын дәрья тармакларында” әсәрләре шикелле үк автобиографик повесть, – ди. – Ул 1912 елдан алып Февраль революциясенәчә булган дәвер эчендә Русия армиясенең хәлен яза. Бу армиянең сыйнфый йөзен ачуы һәм аның Русия монархиясе “язмышын” уртаклап, ничек итеп таркалуга баруын күрсәтүне максат итеп куя. Шул дәвер эчендәге (1912–1917) вакыйгалар: сугыш алдындагы патша казармасы, аның таяк дисциплинасы, солдатның бөтен кешелек иреген югалтуга корылган әшәке режим: фронт, аның бөтен ач-ялангачлыгы, һәлакәте, шул күренешләргә каршы эшче крестьянның яхшы егетләренең большевик көрәшчеләр, җитәкчеләр политик тәрбиясендә ничек итеп революцион хәзерлек алулары – менә болар 284 бит буена сузылган әсәрдә җентекле күрсәтелергә тырышылалар» [Нигъмәти, 1933, б. 93–94].

Роман Афзалны стражник озатуында туган авылындагы старостага китереп тапшыру, аның гаскәри хезмәткә каралырга яше җиткәнлеген күрсәтү белән башланып китә. Әсәрдә вакыйгалар төп каһарман туган һәм яшәгән тирәлектә – Азнакай, Тайсуган, Чәшеле (Чыршылы), Бөгелмә, Минзәлә кебек бүгенге Татарстан Республикасына караган географик-административ пунктларда бара һәм соңыннан хәзерге Самара өлкәсе, Молдавия дәүләтләренә караган җирләрдә дәвам итә. Әсәрнең төп каһарманнары да – шул авыл һәм шәһәрләрдә туган татар егетләре. Язучы моны реаль фактлар белән раслап бара. А. Таһиров армия һәм андагы гаделсезлекләр, җитәкчелекнең дөрес булмаган карарлары, башбаштаклык, сугыш елларындагы аяныч вакыйгаларны, халыкның коточкыч авыр хәлен бөтен тулылыгы белән бәян итә. Романда мөһим тарихи вазгыятьләр белән конкрет шәхеснең тормыш фактлары аерылгысыз берлектә бирелә, шул тарихи вакыйгаларда шәхеснең язмышы сурәтләнә. Килеп туган үзгәрешләрнең кешене төрле борылышларга дучар итүе, алга таба шул мохит һәм алдынгы идеяләр йогынтысында формалашкан шәхеснең актив геройга, тарихны үзгәртүче көчкә әверелүе күрсәтелә. Таһиров әсәргә инде шактый җитлеккән карашлы кеше булып килеп керә. Фикер сөрешеннән без аның элек Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганлыгын, эшчеләр белән аралашып яшәгәнлеген беләбез. Биш-алты ел эчендә булып үткән иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, Михаил Кирш, укытучы Гайдан, Шаруда, Суров кебек большевиклар йогынтысы нәтиҗәсендә аның аңы үсә, дөньяга карашы

үзгәрә, әсәр дәвамында ул ныклы революционер, большевик булып җитешә. Аның үсеше фикер-карашларының һәм характерының ныгуы рәвешендә күрсәтелә. Төп геройның мөнәсәбәте аша А. Таһиров империалистик сугышның халыкка кайгы-хәсрәттән башка бернәрсә дә китермәгән мәрхәмәтсез кан коюю булуын ышандырырлык итеп ачып бирә. Геройның эксплуататор сыйныфларга, реакцион көчләргә карашы бөтен романның иҗтимагый-сәяси пафосына нигезләнә. Шушы ук караш һәм мөнәсәбәтләр язучының әсәрдәге башка персонажларга бәясен белдерә, аларны гәүдәләндерүнең мөһим бер чарасы булып тора.

Романдагы геройларның эш-хәрәкәтләре, портретлары, нигездә, Таһировның бәя бирүе аша характерлана. Аның сөйләве һәм нәтиҗәләр ясап баруы объектив бәя бирүдә икеләнүләр тудырмый, аларны характерлаучы детальләр нинди дә булса өстәмә идея-художество үзенчәлекләренә ия түгелләр. Кайбер персонажларны сурәтләгәндә исә мөнәсәбәтен портрет, гротеск, шарж алымнарына мөрәҗәгать итеп җиткерә бара. Әсәр «мин» исеменнән язылганга, персонажларны характерлаганда аларның эчке дөньяларына үтеп керелми. Хикәяләүдәге бу алым сөйләүче геройның үзенең бөтен эчке дөньясын, кичерешләрен ачарга мөмкинлек бирсә дә, аның уй-карашлары романда публицистик фикер йөртү рәвешендә генә бирелгәнгә, кеше хисләрен чагылдыру тәҗрибәсенең азлыгыннан да, А. Таһировның төп игътибарны күзгә күренеп торган вакыйгаларга туплап, артык хискә бирелмәве, иҗатка социологик күзлектән генә карап, публицистикага кереп китүеннән дә килә.

«Солдатлар» романында А. Таһиров чор авырлыгын бөтен чынбарлыгы һәм тулылыгы белән яктыртып кына калмый, ә бәлки яшәешнең асылын чагылдырып, аны әдәби җепләр белән бәйләп, хәрби теманы һәм аның эш процессын ачык мисаллар җирлегендә чагылдыра.

Автор һәм романның төп каһарманы А. Таһиров «Вакыт», «Йолдыз», «Аң» кебек татар матбугаты басмалары белән рухланып яши. Ләкин, иҗат эшчәнлеген большевиклар заманында зур идеаллар белән башлаган язучының партия мәнфәгатьләрен яклаган карашлары «Солдатлар» романында да чагылмый калмый. Әсәрдә урын алган каршылыклар да персонажның социаль хәленә бәйле рәвештә аңлатыла. Мәсәлән, татарның руханилары арасыннан чыккан егетләрне һәм үз талантлары белән беркадәр хәрби дәрәҗәләргә ирешкән татарларны «сыйнфый дошман» санап, аларны үтә дә тискәре сыйфатлар белән тасвирлый. Чәшем (хәзерге Татарстан Республикасы Лениногорск районы Чыршылы) авылындагы бөтен тирә-як халкы хөрмәт иткән ишан хәзрәтнең улы да бик түбән итеп тәкъдим ителә. Афзал Таһировның прапорщик Зәкәрия Бәхтияровка мөнәсәбәтен алсаң да, чынбарлыктан читләшүне күрергә мөмкин. Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камаллар даирәсендә йөргән күренекле журналист һәм педагог Вафа Бәхтияровның якын туганы – Зәкәрия Бәхтияров

образы романда бозып бирелә. «Бөтен көчен татар мәгарифе юлында йөреп, патша армиясенә алынгач, анда алган хезмәт хакын да туплап, ярлы балаларын укыту өчен васыять әйтеп үлгән татар зыялысын начарлар хисабына кертү белән килешү кыен», – дип белдерде галим М. Әхмәтҗанов [Әхмәтҗанов, 2002, б. 29].

Романда шулай ук Россиянең төрле социаль катлау вәкилләренең тулы образлары, сәяси һәм иҗтимагый карашлары бәян ителә. Әлбәттә, анда гел кара һәм ак төсләр генә булмаса да, ил тормышының эчке күренешләре, барышы, барыннан да бигрәк, армия эчендәге түбән чиннар белән офицерлар мөнәсәбәте шактый тулы һәм реаль сурәтләнә. Армиянең сугышка сәләтсезлеге һәм шул сәбәптән берничек тә акланмаган мәгънәсез корбаннарның биниһая зурлыгы күрсәтелә. Һөҗүмгә әзерләнгән армиядә бердәм командованиенең булдыксызлыгы, оешмаганлыгы ачыла. Полклар, батальоннар, роталар бер-берсен белешми дошманга каршы баралар, уңайсыз позицияләргә урнашалар, корал запаслары да чамалы һәм алар каршы якның координацияләнгән уты астында зур югалтуларга дучар булалар. Әсәрдә шулай ук сугышка әзерлексез офицерлар, аларның солдатларга мөнәсәбәте, түбән гамәлләре һәм гаделсезлекләр ачып салына. Солдатларның авырлыклар белән күзгә-күз очрашуы, сугыш кырындагы җәрәхәтле солдатларның ярдәмчесез калулары кебек күңелгә авыр күренешләр романда еш күзәтелә.

Әлбәттә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәттә аларның психологик һәм шәхси мөнәсәбәтләре төрле яктан күрсәтелә. Бу үзенчәлекләр алар арасындагы мөнәсәбәтләрне я килештерә, я драматик ситуациягә китерә.

Әсәрдәге пейзаж да төп темага хезмәт итә. «Апрель ае. Көн аяз. Кояш үзенең кайнар һәм якты нурлары белән салкын кыштан интеккән кешеләрне йомшак кына җылыта...», «Без лагерьга якынлашабыз. Кояш сугыш башлану белән үк туңып калган кирпич заводының озын торбалары артына төшеп бара иде...» [Таһиров, 1933, б. 125]. Шул рәвешле, пейзаж әсәрне кабул итүне җиңеләйтә, вакыйга кызыклыгын, аерым тасвирларны тагын да тулырак күрсәтү өчен дә кулланыла.

«Кызылгвардиячеләр» һәм «Кызылармиячеләр» дилогиясендә А. Таһировның нык, үсеп җиткән талантлы язучы икәнен күрәбез. Аның зирәк акылы, үтәли карашы, әдәби-нәфис иҗат киңлекләрендә оста хәрәкәт итүе талантының бәхәссез булуын раслый. Әсәрләрдә вакыт аралыгы гаять киеренке. Вакыйгалар тыгыз һәм шул ук вакытта системалы итеп тасвирлана. Урын берлеге ачык итеп бирелә. Сурәтләнгән картиналар бер үзәк герой – Билал Кадыйров тирәсенә берләшкән хәлдә, төп бер теманы хәл итүгә – яңа җәмгыять төзү юлындагы көрәш һәм халыкларның берләшү идеясен, бердәмлеген чагылдыруга хезмәт итә.

Хронологик яктан дилогия «Солдатлар» романындагы вакыйгаларны турыдан-туры дәвам итә. Билгеле булганча, А. Таһиров үзе

1918 елның көзендә Оренбургка килеп, Дутов бандаларына каршы көрәшкә катнашып китә. Әсәр империалистик сугыш гарасатын узып, революцион көрәштә чыныккан Билал Кадыйровның шушы калага килеп, Дутовка каршы сугышуы, кызылгвардиячеләр отряды белән җитәкчелек итүгә керешүе белән башлана.

Оренбург далаларында, Татарстан һәм Башкортстан авылларында һәм Урал тавы араларында Совет власте дошманнарына каршы көрәш картиналары дилогиянең зур өлешен алып тора. Шушы вакыйгаларда Билал, Гыйлаҗи, Арыслан, Салават һәм башка геройлар төрле яктан характерлана. Язучы сыйнфый көрәшне бер-берсенә капма-каршы булган ике лагерьның кораллы бәрелеше төсендә дә, карашлар төрлелеге сыйфатында да сурәтли. Шул ук вакытта автор көрәш сызыгының хәтта бертуган кешеләрне дә ике лагерьга аеруын күрсәтә: Гафар – кызылармияче, советлар өчен җан аямый сугыша, ә аның туганы Мәгъфүр – аклар ягында. Бу ике туган арасындагы мөнәсәбәттә, кан-кардәшлеккә караганда, сыйнфый тойгы өстенлек ала.

Дилогиядә интернациональ чикләр юк. Төрле халык вәкилләре берләшеп, азатлык өчен көрәшкә күтәреләләр. Шуны чагылдыруда автор зур идеяне – «Вак халыклар юк, ә вак төркемнәр генә бар» кебек афоризмга әверелгән гыйбарәне кертә. Әлеге юнәлештә кыю һәм саллы эш итеп, үз чорының каһарманнарын тарихи аспектта чагылдырып, аларның эш-гамәлләре аша халык хәтеренә якынайта.

А. Таһировның тарихны яхшы белүе һәм аңардан оста файдалануы әсәрне күркәм итә. Һәрбер тарихи шәхесне яки аның белән булган эш-хәлләрне ул яратып сурәтли. Әсәрдә яңа җәмгыять төзү өчен көрәш процессында яңа сәнгать мәсьәләләре дә күтәрелә. Башта сәяси тормышка битараф булган артист Нури Сакаевның большевиклар йогынтысында көрәшкә тартылуы, театрны халык массаларына хезмәт иттерергә омтылуы тирән лирик чигенешләр аша сәнгати югарылыкта чагылдырыла.

Сәнгатьне сыйнфый көрәш белән бутаучыларга да әсәрдә урын иркен бирелә. Шул җәһәттән, автор сәнгатьне югары күтәрә һәм аның сыйнфыйлыктан өстен торырга һәм бары халыкка гына хезмәт итәргә тиешлеген хуплый.

«Кызылгвардиячеләр» һәм «Кызылармиячеләр» романнарында социаль-сәяси вакыйгаларны чагылдыру белән беррәттән кеше шәхесенә дә игътибар арта төшә. Төп герой Билал, мәсәлән, төрле ракурста гәүдәләнеш тапкан: беренчедән, ул, көрәшче, халык массаларының җитәкчесе буларак, һәрвакыт алар белән, аларның аерылгысыз өлеше итеп күрсәтелә, икенчедән, язучы аның шәхси тормышын да бөтен тулылыгы белән ячтырта. Әсәрләрдә әхлак проблемаларына, аларның хәл ителешенә, шәхес һәм коллектив мөнәсәбәтләренә шактый урын бирелә. Бигрәк тә Билал белән Маһи мөнәсәбәтләре, үтә нечкә хисләр аша, гаилә проблемасын яктыртуда хәлиткеч роль уйный. Интим тойгыларны хикәяләү дилогиягә лирик җылылык өсти, чынбарлыкка якынайта, ышанычны арттыра. Геройларның кичерешләре,

үткән һәм киләчәк турында уйланулары, бер яктан, аларны образ буларак тирәнрәк ачса, икенче яктан, кыска гына чорда сурәтләнгән романнарның вакыт сыйдырышын киңәйтә, персонажларның үсү-формалашу юлларын тулырак күз алдына бастыра. Шул ук вакытта язучының герой тойгыларын хикәя итүдә үз-үзен «тыюын» да шәйләми мөмкин түгел.

Бу дилогия дә, А. Таһировның башка әсәрләре кебек үк, чынбарлыкның конкрет фактларына, документаль материалларга нигезләнеп язылган. Тарихта билгеле булган кайбер шәхесләр әсәрдә үз исемнәре белән кертелгән.

Мәсәлән, артист Нури Сакаев исеме үзгәртүләрсез кулланылган. Шулай ук күп кенә персонажларда исемнәре аваздаш булган конкрет шәхесләрне төсмерләргә мөмкин. Әмма персонажларны идея-эстетик кануннар таләп иткәнчә сайлау, урнаштыру, төркемләү һәм типиклаштыру, вакыйгаларны художестволы аспектта чагылдыру «Кызылгвардиячеләр» белән «Кызылармиячеләр»не «Солдатлар» романына хас мемуарлыктан арындыра.

Дилогиядә ил тормышындагы мөһим иҗтимагый-социаль вакыйгалар, кораллы сыйнфый бәрелеш картиналары киң офык агымында тәфсилле сурәтләнә, уңай геройларның эш-хәрәкәтләре, нигездә, объектив хикәя ителә. Анда берьюлы берничә сюжет сызыгы үстерелә, төп геройга бәйләнмәгән, әмма бер-берсе белән идея-художество ягыннан берләшкән картиналар чагылыш таба, бер үк күренешнең төрле бүлекләрендә төрле персонаж позициясе аша үткәрелеп сурәтләнгән очраклар да бар. Болар романнарга эпиклык төсмере бирә һәм дилогия тарихи-революцион романнарның күп кенә сыйфатларын үз эченә ала. Сәяси адымнарны, аерым шәхесләрне характерлауда автор еш кына тарихчы-публицист буларак чыгыш ясый, үткән вакыйгаларга 30 нчы еллардагы сәяси-иҗтимагый карашлар күзлегеннән чыгып, турыдан-туры бәя бирә.

Шулай итеп, әсәрләрдә сәясилек үтә нечкә төсмерләр аша чагылдырыла. Автор публицистик бәя бирү белән бергә, үзенең кире мөнәсәбәтен белдерә торган чагыштыру-метафораларны, ирония, гротеск һәм башка алымнарны еш куллана. Шул рәвешле дилогиягә сәяси памфлет, сатира алымы килеп керә.

Роман жанрын формалаштыруда һәм үстерүдә, аны яңа художество үзенчәлекләре белән баетуда А. Таһиров зур эш башкара. 30 нчы елларда ук аның романнары рус теленә тәрҗемә итеп бастырыла һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан уңай бәяләнә. Әсәрләренең идея-проблематикасы бүгенге көндә дә актуаль.

Гомумән, Афзал Таһировның «Солдатлар» романы – Беренче бөтендөнья сугышы темасына, солдат язмышына багышланган һәм татар телендә язылып басылып чыккан, чорның әхлакый кыйммәтен чагылдырган оригиналь әсәр [Бәдретдинов, 2010, б. 170]. Ул – солдат язмышын калку күрсәткән, совет чынбарлыгын яктырткан, шул чорның иҗтимагый-сәяси йөзен ачып биргән үзенчәлекле татар романы.

**Әдәбият**

Атака. 1930. № 1. Б. 17.

Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.

*Әхмәтҗанов М.* Татар язмышы чагылган әсәр // Мирас. 2002. № 3. Б. 29.

*Бәдретдинов Р.Ф.* Каһәрле еллар корбаны. Казан: Ихлас, 2010. 175 б.

*Гали Г.* Сайланма әсәрләр. Казан. Татар. кит. нәшр., 1958. 32 б.

*Гайнуллин М.* Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. С. 428.

*Гредель В.* А.Таһиров иҗаты // Әҙәби Башҡортостан. 1957. № 4. Б. 63–65.

*Нигъмәти Г.* Татар совет әдәбиятында реализм мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1933. № 11–12. Б. 93–94.

*Рәхим Гали.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 280 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 3 т.: XX гасыр башы. 287 б.

*Таһиров А.* Солдатлар. Беренче һәм икенче китап. Казан: Татиздат, 1933. 47 б.

*Таһиров А.* Солдатлар // Мирас. 2002. № 3. Б. 107.

*Тинчурин К.* Әсәрләр: өч томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 96 б.

*Юлтый Д.* Солдатлар (А. Таһиров хикәясе) // Октябрь. 1933. № 3–4. Б. 62–68.

***Бәдретдинов Рәҗәп Фәтхетдин улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы*

УДК 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ПРОЗАСЫ: ПОЭТИК АЧЫШЛАР

Статья посвящена поэтическим особенностям прозы Амирхана Еники. На материале обширного корпуса произведений установлено, что его произведения военного времени характеризуются такими чертами как возрождение национальных художественных традиций татарской прозы начала XX века, углубление личностного начала и психологизма, интеллектуальностью и философичностью. В рассказах военной поры А. Еники описывает не военные сражения, а отражение этих трагических событий в зеркале человеческой души. В отдельных рассказах такие приемы психологизма как «диалектика души», «поток сознания» становятся основными смыслообразующими центрами. Ключевыми поэтическими приемами в повестях 1960–1980 гг., способствовавших созданию новых контуров татарской литературы, стали распределение персонажей по полюсам добра и зла (духовного и материального); представление «правды двух людей». В его творчестве впервые в татарской советской литературе происходит расширение смыслового диапазона традиционных образов от единичного ко всеобщему, к архетипическим началам, и неразрывная взаимосвязь этнических и общечеловеческих ценностей. Интересом к подсознательным процессам, психоанализу характеризуются произведения конца 70-х годов, которые вписаны в контекст экзистенциальных произведений мировой литературы.

**Ключевые слова:** татарская проза, Амирхан Еники, психологизм, философичность, бинарность материального и духовного.

The article is devoted to the poetic features of Amirkhan Eniki's prose. Based on the material of an extensive corpus of works, it is established that his wartime works are characterized by such features as the revival of national artistic traditions of Tatar prose of the early twentieth century, the deepening of personal beginnings and psychologism, intellectuality and philosophy. In the stories of the wartime A. Eniki describes not military events but the reflection of these tragic events in the mirror of the human soul. In some stories such techniques of psychologism as "dialectics of the soul", "stream of consciousness" become the main semantic centers. The key poetic techniques in the stories of the 1960s and 1980s which contributed to the creation of new contours of Tatar literature were the distribution of characters along the poles of good and evil (spiritual and material); the representation of the "truth of two people". In his work for the first time in Tatar Soviet literature there is an expansion of the semantic range of traditional images from the singular to the universal, to archetypal principles and an inseparable interconnection of ethnic and universal values. Interest in subconscious processes and psychoanalysis characterize the works of the late 70s which are inscribed in the context of existential works of world literature.

**Keywords:** Tatar prose, Amirkhan Eniki, psychologism, philosophicality, the binary of the material and the spiritual.

Әмирхан Еники иҗатының кыйммәте, аның татар совет әдәбиятын үзгәрткән әсәрләр иҗат итүе хакында күп язылган. Чыннан да, бер яктан, ул әдәбиятка кешенең рухи олылыгын үзәккә куйган шәхес концепциясен алып керә. Икенче яктан, иҗатчыларны да уйландыра, милли әдәбиятның үз традицияләрен, бигрәк тә XX гасыр башы язучыларының психологизм һәм фәлсәфи гомумиләштерү мөмкинлекләреннән оста файдалануын искә төшерә.

Совет әдәбияты контекстында Ә. Еники иҗатын тикшергәндә, без беренче чиратта андагы психологизмны телгә алабыз. Әмма татар әдәбиятында психологизм XX гасыр башында ук кешенең эчке дөньясын ачуга хезмәт итә башлый. Ф. Әмирхан («Хәят»), Г. Исхакый («Теләнче кыз»), Г. Ибраһимов («Яшь йөрәкләр», 1912) әсәрләре тирән психологизм белән сугарылган. 1917 елдан соң мәйданга чыккан совет әдәбиятында да психологизм юк дип булмас. Соцреализмның иң мөһим әсәрләре – әйтик, Г. Бәшировның «Намус» романында да Нәфисә кичерешләре психологизм алымы ярдәмендә ачылалар. Шулай булгач, Ә. Еники иҗатының үз чоры язучыларының әсәрләреннән аермасы бармы, булса – нәрсәдә соң?

Бар, билгеле. Язучының сугыш чоры хикәяләрендә психологизм төп эчтәлекне хасил итә. Ягъни язучы сугыш яки тыл вакыйгаларын түгел, бәлки аларның кеше күңелендә чагылышын сурәтләү объекты ясый, аерым кеше өчен фаҗига булуын үзәккә ала. Татар совет прозасында исә, гомумән алганда, психологизм – геройлар характерын тергезүдә, аерым хәл-вакыйгаларны бәяләүдә катнаша. Шулай итеп, Ә. Еникинең «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Бер генә сәгатькә» (1944) кебек хикәяләре психологизмның «җан диалектикасы» кебек катлаулы төренә мөрәҗәгать итүе, шуның ярдәмендә геройларның үзгәреп торучы кичерешләрен барлык ваклыкларында тергезүе белән аерылып тора.

«Кем җырлады» (1956) хикәясендә, татар прозасында беренче булып, психологизмның аң агышы алымы файдаланыла, ул фәлсәфи гомумиләштерүгә китереп, әсәр эчтәлеген тудырган төп алымга әйләнә. Кызганычка каршы, текстны болай оештыру татар әдәбиятында бары тик XX гасыр ахырында гына киң кулланылышка керә.

Шуның белән янәшә хикәяләрдә фәлсәфилек, язучының сурәтләнгән хәл-вакыйганы яшәеш законы итеп күтәрүе күзгә ташлана. Бу сыйфат шулай ук XX гасыр башы татар прозасында бик уңышлы файдаланылган иде. Гасыр башындагы кебек үк, Еники еш кына моны символлар ярдәмендә башкара. Әйтик, «Бала» хикәясендә бала образы сугышка, үлемгә каршы куелган яшәү символы булып калка. «Тауларга карап» (1948) хикәясендә Локман карт уйларында мөрәҗәгать итә торган таулар – яшәеш кыйммәтләре, алар арасында язучы нәсел, дәвам, мәхәббәтне аерып чыгара, символлаштыру әсәрдәге төп фикергә турыдан-туры юл күрсәтә.

Бу әсәрнең жанрлык үзенчәлеге дә яңалык буларак бәяләнергә лаек: язучы тарафыннан «хикәя» дип билгеләнгән, әмма хикәяләү

шактый озын булып, табигать белән янәшәлекләр дә; ретроспектив һәм лирик-фәлсәфи чигенешләр дә, күзәтүләр дә урын алган әсәрләр «озын хикәя» белән «кечкенә повесть» арасында тора. Мондый әсәрләр язучының бөтен иҗаты дәвамында күзәтелә.

Тирән психологизм белән сугарылган, вакыт-вакыт күңел монологы, аң агышы алымы белән кушылып китә торган хикәяләү рәвеше татар прозасы өчен яңа һәм ят булып чыга: бу әсәрнең 1948 елда «Совет әдәбияты» журналында басылмау сәбәбе дә шунда булса кирәк. Чөнки истәлекләрендә язучы үзе дә әсәрнең кире кагылуын «хикәягездә сүз күп, хәрәкәт аз, аннары хискә бирелеп язылган» дип аңлатуларын телгә ала [Еники, б. 457]. Сурәтләү матурлыгы, сүзләрнең бер-берсенә ярашлы файдаланылуы Ә. Еники прозасында эчке бер моң, музыка хасил итә. Әдип вакыйгаларны сюжет-композиция ягыннан оештыруны психологизмны көчәйтүгә буйсындыра. Янәшәдә авторның фәлсәфи «тавыш»ы ишетелә. Шул рәвешле, әсәрләрдә синтетизм күренеше хасил була.

Әмма иң зур үзгәреш геройлар бирелешендә булып чыга. Башта Ә. Еникинең милли әдәбиятыбызга социалистик реализм алып килгән коры-рәсми, резонер геройлар ярдәмендә идея белдерүдән баш тартуын әйтергә кирәк. Бу мәсьәләдә әдип белән Г. Әпсәләмов арасында бәхәс тә булып уза [Еники, б. 368–369].

Күренекле әдәбиятчы В.И. Тюпа, рус авангард әдәбиятындагы яңалыкны Ч. Айтматовның беренче повестьларының «мин» дип башлануында, шуның белән соцреализмдагы «без»дән баш тартуында күрә: шуның белән язучы «шәхси ихтыяҗларның өстенлеген ассызыклады, дәүләти ихтыяҗларны беренче планга чыгарган идеяне җимерде» дип белдерә [Тюпа]. Бу сыйфатны без Ә. Еникинең сугыш чоры хикәяләрендә үк күзәтәбез. Хикәяләүнең субъективлашуы шәхси башлангычны алга чыгара.

Язучы 1950–1960 еллар чигендә үзенең геройларын капма-каршы ике чиккә аера башлый. Бу – соцреализмда да шулай. Аерма шунда: Ә. Еники бу вакытта кешедәге рухи һәм матди кыйммәтләрне капма-каршы куя.

Әлбәттә, поэтик үзенчәлекләр хакында сөйләгәндә, язучының татар әдәбиятына моңа кадәр тыелган яки кысрыкланган проблемалар алып килүен дә әйтергә кирәк. Кайбер партия җитәкчеләренең матди байлык колына әйләнүе («Саз чәчәге»), аерым кешеләрнең сугыш вакытында Ватан гаме белән түгел, шәхси ихтыяҗларын кайгыртып яшәве «Рәшә» (1962) шундыйлардан. «Вөҗдан» (1966–1968) повесте шәхес культы атмосферасын тергезгән беренче әсәрләрдән була. Аларда, кеше психологиясе һәм холкы хикәяләү үзәгендә калдырылган хәлдә, совет идеологиясенең нигезен тәшкил иткән ялгыш караш-фикерләргә иҗтимагый-сәяси тәнкыйть көчәя, җәмгыятьтәге күп кенә тискәре күренешләр закончалыклы хәл югарылыгына куела.

1960 еллар совет әдәбиятына нисбәтле В.И. Тюпа «ике кеше хакыйкате» дигән төшенчә кертә. Галим фикеренчә, соцреализм өчен

«ике кеше хакыйкате» – ялган, чөнки ул тоталитар «без» хакыйкатеннән аера [Тюпа]. Ә. Еники иҗатының буеннан буена ике кеше хакыйкате шәрехләнә. «Тауларга карап»та ул Локман карт һәм хикәяләүченеке булса, «Рәшә»дә ул Рәшидә һәм Зөфәрнең абыйсыныкы, «Әйтелмәгән васыять»тә Акъәби белән шагыйрьнеке, Акъәби белән Миңлебай картныкы. Әлеге алым 1960–1980 еллар татар прозасында иң активлардан санала.

Ә. Еникинең «Саз чәчәге», «Рәшә» повестьларында ук тагын бер авангард сыйфат калкулана: ул – төп геройларның архетипик структурага «утыртылуы» [Кофман, б. 295]. Әйтик, исәп кешесе – Зөфәр дә, хис кешесе – Рәшидә дә әдәби иҗатта бик борынгыдан килгән типик оппозицияләргә куелганнар. Әмма бу сыйфат язучы иҗатына буыннар арасындагы бәйләнеш темасының төп тема буларак килеп керүеннән соң тагын көчәя. «Туган туфрак» (1959), «Матурлык» (1964), «Әйтелмәгән васыять» (1965) һ. б. хикәяләрдә төп геройлар – теләсә кайсы заманда һәм урында очрый торган, борынгы грек яки төрки эпостан ук килгән персонажлар булып тоелалар. Әмма алар татар кешесе итеп, милли мохитта, милли менталитет йөртүчеләр кебек сурәтләнгәннәр, шуңа да язучыны татар фәлсәфәсен, психологиясен җиткерүче буларак кына бәяләп була.

«Җиз кыңгырау» (1966), «Курай» (1970) хикәяләре, «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) повесте татар әдәбиятында милли-тарихи материал, йола-гадәтләр, бәйрәмнәр, мәдәни ядкәрләр турында сөйләшүне башлап җибәрүчеләрдән була. «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестенда интертекстуальлек алымы киң кулланыла башлый дияргә мөмкин.

Тагын бер сыйфат аерып билгеләүне сорый: Ә. Еникидә фәлсәфә экзистенциаль башлангычлы, яшерен сагыш белән өретелгән, ләкин әсәрләр һәрчак өмет ноктасында төгәлләнә. Бигрәк тә язучының «Төнге тамчылар» (1964), «Шаяру» (1955), «Картлар» (1970), «Тынычлану» (1978) хикәяләре шуны күрсәтә. Аларда әдип шәхеснең рухи ялгызлыгын яшәеш кануны дәрәҗәсенә күтәрә, моның сәбәбен берәү дә урап уза алмый торган ялгышу белән бәйли. Әсәрләр дөнья әдәбиятында 1960 елларда беренче планга чыккан, ялгызлык фәлсәфәсен тудыручы экзистенциаль әсәрләр белән аваздаш. Ләкин һәркем тормышының үкенечле узуын, ахыр чиктә кешенең барыбер рухи яктан ялгыз җан булуын татар язучысы үзгә аңлату юлы таба, иҗтимагый хаталарга ишарә ясый.

Әйтик, «Төнге тамчылар» хикәясендә кешеләр совет системасындагы сәясәтнең асылына төшенәчәк үзгәртеп кору елларыннан күп элек, 1964 елда, Ә. Еники, татар әдәбиятында беренче булып, совет идеологиясенә ышанган буын фаҗигасын ача, аңа тулаем бәя бирә. Бу хикәяләр язучының кеше психологиясе, аң төпкелендә барган процесслар, психоанализ белән кызыксынуының артуы хакында да сөйли. Болар татар әдәбияты өчен яңалык, XX гасыр башында өзелеп калган агымга ялгану икәнлеген дә искәртергә мөмкин. Нәкъ менә

аң һәм аң төпкеле яссылыкларында тудырылган ялгызлык фәлсәфәсе әдипнең «Тынычлану» (1978) әсәрендә иң югары ноктасына җитә.

Шулай итеп, 1960 елларда татар прозасында башланып киткән һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан үзгәрешләрне Ә. Еники прозасы әйдәп бара. Алга таба башка язучылар иҗатында дәвам итәчәк авангард эзләнүләрнең башы да шушы иҗатта булуы бәхәссез [Заһидуллина, б. 210].

1960 еллар авангард әдәбияты бүгенге әдәбият белеме фәне тарафыннан авторитар автордан – дус-сердәш авторга күчү вакыты буларак карала. Ә. Еники иҗатында да ул шулай. Язучы – хәбәр җиткерүче, кисәтүче: ул рухи кыйммәтләр югалу, тел бетү һәм туган җир кадере киму, буыннар арасында бәйләнеш өзелү, вөҗдан төшенчәсенең эчтәлеге үзгәрү турында кисәтә.

**Әдәбият**

*Еники Ә.* Әсәрләр: 5 томда. 4 т.: Соңгы китап: истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 479 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Кофман А.Ф.* Художественный мир Чингиза Айтматова // Studia Litterarum. 2019. Т. 4. № 2. С. 292–311.

*Тюпа В.И.* Коммуникативная стратегия «вестничества» в прозе Чингиза Айтматова // https://cyberleninka.ru/article/n/kommunikativnaya-strategiya-vestnichestva-v-proze-chingiza-aytmatova (мөрәҗәгать итү көне: 23.11.2023).

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ф.Х. Миңнуллина***

# 1950 ЕЛЛАР ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЗАМАН ҺӘМ ГЕРОЙ (Н. Исәнбәт, Г. Насрый, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов иҗатлары мисалында)

В статье раскрываются особенности татарской драматургии 1950-х годов. Выявляются закономерности идейно-эстетического развития национальной сценической литературы исследуемого периода через концепцию эпоха и герой. Определяются изменения концепции героя, основная тематика и идейно-эстетические особенности татарской советской драматургии изучаемого периода. Главная идея пьес заключается в призыве к преобразованию жизни страны.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, Великая Отечественная война, трансформация, герой, жанр.

The article reveals the features of the Tatar drama of the 1950s. The patterns of the ideological and aesthetic development of the national stage literature of the studied period are revealed through the concept of epoch and hero. The changes in the concept of the hero, the main theme and ideological and aesthetic features of the Tatar Soviet drama of the studied period are determined. The main idea of the plays is to call for the transformation of the life of the country.

**Keywords:** Tatar drama, the Great Patriotic War, transformation, hero, genre.

1945–1950 еллар татар драматургиясе совет иленең сугыштан соңгы ирешкән уңышларын күтәренке публицистик рухта яктырту белән билгеләнә. Бу чор әдәбиятында тормыш каршылыкларын шомартып сурәтләү, «конфликтсызлык теориясе»нең зур зыян китерүе, төзелешләр һ. б. белән мавыгу, кеше шәхесен икенче планда калдыру, дәүләт һәм халык эшенә тулысынча бирелгәнлек алгы планга чыгу, илдә барган вакыйгаларны уңай яктан гына яктыртуның өстенлек итүе күзәтелә. XX гасырның 50 нче елларында әдәби иҗатка килгән язучылар, халык тормышының төрле якларына мөрәҗәгать итеп, чор проблемаларын әхлакый-этик планда тасвирлыйлар. Әмма алар да заманга хас кимчелекләрдән, традицион схемалардан, штамплардан ерак китмәделәр. Шулай да, Р. Ишморатның «Якын дус», «Яңа бистәдә», Н. Исәнбәтнең «Гүзәл», Г. Насрыйның «Кушнарат», «Кадерле минутлар» кебек пьесалары (1950–1952) сталинизм тудырган авыр шартларда заман герое образын эзләүдә яңа бер омтылыш булды.

Сугыштан соңгы елларда Г. Насрый комедия жанры өлкәсендә аеруча актив эшли. «Күңел дәфтәре» лирик комедиясе (1949), «Директор Тарханов» («Без капчыкта ятмый») комедиясе (1950), «Алтын көз» («Идел буенда») музыкаль комедиясе (1950), «Кушнарат» лирик комедиясе (1952), «Кушамат» кебек фаҗигалы комедияләр (1955), Ш. Хөсәеновның «Профессор кияве» комедиясе (1952) – шуның

мисалы. Әмма аның иҗатына да «конфликтсызлык» шаукымы кагыла. «Ул бер урындарак таптана, кабатлана, конфликт һәм характерлар эзләүгә җиңелчәрәк килә, сюжетны очраклы вакыйгаларга, аңлашылмаучылыкка, вак интригага кора. Авызы пешкән өреп кабар дигәндәй, күп кенә әсәрләре әлеге «теориядән» чыгып тәнкыйть ителгәч, ул ирексездән әнә шундый алымнарга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була» [Хатипов, 1958, б. 63]. Шулай да, психологик анализ тирәнәя бару, җитди мотивлаштыру тенденциясен Г. Насрыйның «Кушнарат» комедиясендә күрергә мөмкин [Ханзафаров, 1921, б. 352]. А. Салихова фикеренчә, Г. Насрыйның «Кушнарат»ын уңышлы әсәр дип атап булмый [Салихова, 2016, б. 27]. Пьесада хезмәт кешесен эш урынында сурәтләгән берьяклы концепция дә өстенлек итә. Биредә кешенең шәхси тормышы икенче планда кала һәм заман рухына хас булганча, социалистик хезмәт темасы күтәрелә. Шуларга бәйле рәвештә, геройларның әхлакый йөзе дә хезмәткә нисбәтле ачыла. Сәхнә әсәрендә хезмәт кешене тәрбияләү чарасы, бәхет чыганагы итеп карала. Биредә автор, Ә. Фәйзинең «Акчарлаклар» әсәрендәге кебек, колхозларны үстерү, уңыш арттыру өлкәсендәге актив эшчәнлекне күрсәтә. Мәсәлән, сугыш кырында батырлыклар кылып кайткан Харис тыныч тормышта алдынгылар сафында тора, «Ялкын» колхозында председатель вазифасын башкара:

«Ш а к и р җ а н. Акыл бит яшьтә түгел, башта. Безнең Харис башлы егет булып чыкты, мин әйтәм. Соң шулай димичә. Казанда укып, агроном исемен алды. Сугыштан кайткач, үзен председатель итеп сайладык. Өч ел эчендә ниләр генә эшләмәде ул!.. Лаборатория оештырды. Кырларыбызны сортлы орлык белән күмде. Агроном бит ул, агроном! Үткән ел тагын укырга китте» [Насрый, 1952, б. 17]. Бу уңайдан «Маяк», «Чаткы», «Ялкын» колхозларын берләштереп, яңа сортлы орлыклар белән зур уңыш алуга, электростанция ачуга ирешкән Харисның сүзләрен китерү дә урынлы булыр: «Ә халыкка хезмәт итү – коммунизм төзү өчен көрәшнең алдынгы сафында бару дигән сүз. Ләкин “Ялкын” кебек вак колхозлар белән зур максатка ирешүе авыр. Колхозларның бөтен эше хәзер фән һәм техника көченә корылган. Шундый зур көчне кечкенә басуларга сыйдырып буламы? Юк, булмый! Председательләр курсында укыган чакта мин Кубань егетләре белән сөйләштем, һәм миндә шундый фикер туды: Татарстан басуларын, Кубань далалары кебек, мул икмәк арсеналына әйләндереп булмыймыни?! Мөмкин бит, бик мөмкин. Моның өчен вак колхозларны кушарга, кечкенә басуларны зурайтырга кирәк. Алдынгы техниканы бөтен ходка җигәргә! Колхоз кырларын галимнәр лабораториясенә әйләндерергә!» [Насрый, 1952, б. 28]. Язылган драмада, әлбәттә каһарманының гүзәл образын күрсәтү максаты белән геройлар тулысынча ачылып бетми. Алар схематик характерда бирелә. Шулай да, пьеса заман героен эзләү, фән-техника казанышларын яктырту омтылышы ягыннан игътибарга лаек. Бу уңайдан, Абдулла Әхмәтнең «Егет сүзе» исемле комедиясен искә алу да отышлы булыр. Ф. Хати-

пов комедиянең кимчелекләрен күрсәтеп болай ди: «Урыны-урыны белән бу комедиядә эчкерсез шат көлү тавышлары ишетелеп киткәләсә дә, тулаем алганда, коллизияләрнең ясалмалыгы, телнең төгәлсезлеге күзгә ташлана; хәрәкәтләр ышанычсыз, характерлар акланып җитмәгән, проблема художество югарылыгына күтәрелеп ачылмаган» [Хатипов, 1958, б. 27]. Драматург әсәрнең төп конфликтын баш герой Мөбарәк тирәсенә җыя. Әтисе улын үз урынына колхоз председателе итеп калдырырга тырышуга карамастан, яшь егет нефтьче булып китәргә тели. Беренче күренештә атасы Сәмыйкның улын озатырга машина чакыртуы әсәрдәге драматик киеренкелекне, конфликтны юкка чыгара. Вакыйгалар барышында егет яңа эш урынында тиз генә күтәрелә башлый. Ләкин алга таба эшеннән китәргә теләк белдерүе, күпмедер вакытлар үткәннән соң, янәдән тоткан юлыннан тайпылмыйча нефть эшендә калырга ниятләве кебек вакыйгалар логик яктан акланмый, схематик килеп чыга, геройларның эш-гамәлләрендә эзлеклелек сакланмый, герой характерының бөтенлеге дә җимерелә. Мөбарәк образында драматург ил байлыгын ишәйтергә, производствоны алга җибәрергә омтылучыны күрсәтсә, Сәмыйк абзый аша үз колхозының патриотын күрсәтергә тели. Карт мастер Зарифны тискәре герой итеп сурәтли. Бораулау конторасы директоры Бакланов мастерны яшьләргә юл бирмәүдә, яңа техниканы файдаланмауда гаепләп, эшеннән ала. Ләкин «яшьләргә юл бирмәү» нәрсәдә чагыла? Бу автор игътибарыннан читтә кала. Биредә, ясалма каршылыклар характерларны буташтыралар, сюжет та табигый рәвештә үстерелми. Мәхәббәт сюжетын бирүдә дә автор уңышсызлыкларга очрый. Мәхәббәт тойгыларын, кичерешләрне тасвирлаудагы тел байлыгының ярлылыгы егет белән кыз арасындагы мөнәсәбәтне салкын итеп күрсәтә. Гомумән, татар әдәбияты тарихында билгеләнгәнчә: «1940–1950 еллар чиге драматургиясе сугыштан соңгы елларда ук кешене сурәтләүдә бертөрлелеккә юл куймадылар дияргә була. Әмма аларга ул вакытта совет әдәбиятында киң таралган конфликтсызлык теориясе шактый зыян итте. Бу теориядән күпмедер дәрәҗәдә Н. Исәнбәтнең «Рәйхан» (1949), Ю. Әминовның «Язылмаган законнар» (1957), Ш. Хөсәеновның «Чулпан» (1956), Ә. Фәйзинең «Рәүфә» (1958) кебек драмалары гына читтә кала. Бу әсәрләр тормышның шактый җитди мәсьәләләрен, геройларның каршылыклы уй-хисләрен һәм язмышларын тормышчан чагылдыралар. Бигрәк тә лирик комедия, музыкаль комедия, водевиль, сатирик комедия төрләре ачыклана төшә» [Ханзафаров, 2022, б. 354].

Гомумән, 1950 еллар татар драматургиясендә тормышчан күренешләргә мөрәҗәгать итү, геройларның югары әхлак сыйфатларын тасвирлау омтылышы күзәтелә (Р. Ишморат. «Якын дус»; Ю. Әминев «Язылмаган законнар» «Гөлчәчәк», Н. Исәнбәтнең «Зифа», «Рәйхан», Ш. Хөсәеновның «Профессор кияве» һ. б.).

Р. Ишморат Ю. Әминевның «Язылмаган законнар», «Гөлчәчәк» пьесаларын «драматургиябез хәзинәсендә күренекле урын алырлык

әсәрләр» дип билгели. Драматургның әсәрендә әхлакый проблема кешеләрнең бер-берсенә, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре, хезмәтнең кешегә тәэсире аша хәл ителә. Тракторчы егет Шәйхенур белән савымчы кыз Фәридә гаилә корып җибәрәләр. «Бәхетләре ташып тора, яраткан кешеләре янәшәдә, җанга якын эшләре бар, йорт дисәң, йортлары менә дигән, азык запасы уйламыйча 3 елга җитәрлек, киемсалым сандыкка сыймый». Вакыйгалар үстерелешендә Шәйхенур хатынының җәмәгать эшләренә күп вакыт сарыф итүенә канәгатьсезлек белдерә. Фәридә, сөйгәненең тупас мөгамәләсен авыр кичерсә дә, җәмәгать эшләреннән баш тартмый. Нәтиҗәдә, Шәйхенурның күңелен җилбәзәк Назлыбикә били. Яшь гаиләнең җимерелүендә автор, Шәйхенурны гына гаепләп, фермада эшләп, кичләрен утырышларда үткәрүче Фәридәне дә аклау юлына бармый.

«Ф а з ы л. Гаепнең Шәйхенурда гына булуы мөмкин түгел. Фәридәнең үзендә дә, бездә дә гаеп юк микән? ...Кызыбызны җиленә дә, давылына да сыгылмаслык нык итеп үстерә алмадыкмы әллә? Габдри кызы Сараны ал, юлдан язган адәм актыгын да кеше итте бит. Ә безнең кызыбыз авылның мактаулы егетен дә кулында тота алмады», ди кызның әтисе (104 б.) Назлибикәнең максаты исә «бай» кияү табу, шуның исәбенә көн күрү. Ул йөрәк авырулы каенанасын асраугa әйләндерә. Эчәкләрен алмыйча тавык шулпасы пешерү кебек ситуацияләр ярдәмендә драматург, татар фольклоры традицияләрен дәвам итеп, ялкау килен, комсыз хатынны халык хөкеменә тапшыра [Шәрипова, 2018, б. 59]. Шул рәвешле, драматург әхлакый-фәлсәфи проблематиканы яктырта, геройларның күңел халәтен ача. Заманында күпләргә үрнәк булган тракторчының хезмәт күрсәткечләре түбәнәя, гаиләдәге мөнәсәбәтләре кискенләшә, дуслары белән аралары бозыла. Назлыбикә тарафыннан «әрәмтамак» дигән исем тагылу, бу хәлләргә улының битарафлыгы Хөббиҗамалда ризасызлык тудыра: «...Намуссыз син. Башыңны читкә борып кына хөкемнән котыла алмассың… Синең мондый җинаятең өчен язылмаган законнар буенча хөкем итәрләр. Хөкем каты булыр. Сезгә беркемнән дә мәрхәмәт, шәфкать булмас», ди ана улына. Әни кешенең әрнү-үкенеч тулы сүзләре, баладан өмет өзү мотивы белән «Язылмаган законнар» Ш. Хөсәеновның «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») драмасы белән аваздаш. Ю. Әминев үзенең геройларын хаталы адым ясаудан сакларга тырыша. Фазыл кызы белән киявенең, саф, матур, бәхетле тормыш белән яшәүләрен теләп, якты дөньяга аваз салган оныгы Алмазны Шәйхенур кулына тапшыра. Шул рәвешчә, автор ялгышлары өчен язылмаган тормыш законнары буенча хөкем ителгән, авыр намус газаплары кичергән Шәйхенурның үз хаталарын тануын күрсәтә. Гомумән, «Язылмаган законнар» – мәхәббәт, хезмәт, яшәү мәгънәсе, бәхет төшенчәләрен аңлауга бәйле психологик драма. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар Ю. Әминевнең «Гөлчәчәк» драмасында да урын ала. Әсәрдә табиблар гаиләсендә тәрбиягә алып үстерелгән хирург Гөлчәчәк белән яшь урманчы Илшат арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр тас-

вирлана. Сөйгәне авырып китү сәбәпле, кыз, авыр юллар үтеп, егет янына килә, операция ясый, үлемнән коткара. Әлеге вакыйгалардан соң, Гөлчәчәк үзе авырып китә, аңа күрү сәләтен югалту куркынычы яный. Сәламәтләнеп аякка баскан Илшат исә Сөмбел исемле тол хатын белән танышып, сөйгәнен ташлап китә. Әлеге вакыйгаларга бәйле рәвештә, драматург яманлык һәм җәза мәсьәләсен күтәрә. Вакыйгалар үстерелешендә Илшат янәдән операция өстәленә ята. Илшатның гомерен саклап калырлык группалы кан бары Гөлчәчәк белән Сөмбелдә генә булып чыга. Сөмбел кан бирергә риза булмый, Гөлчәчәк исә, авыру булуына да карамастан, ризалаша, егетнең гомерен икенче тапкыр саклап кала. Әмма, шушы вакыйгалардан соң, Гөлчәчәк Илшатның мәхәббәтен кире кага. Ш. Хөсәенов әлеге әсәрне «медицина работникларына карикатура» дип атый [Хөсәенов, 1959].

1950 еллар татар драматургиясендә драматург Ш. Хөсәеновның «Профессор кияве» исемле комедиясе (1952) аерым урын алып тора. Әхлак һәм мәхәббәт мәсьәләләрен үзәккә алган бу әсәрдә шәһәр зыялылары, эшче яшьләр тормышы бәян ителеп, заманы өчен яңача ситуацияләр тасвирлана. «Бу елларда шәхес культы һәм репрессия елларында чынбарлыктан ераклашкан, идеологик таләпләр кысасында тәмам штамп, схема, плакат хәленә төшкән ясалма сәхнә әсәрләреннән арыну проблемасы җәмгыяви фикердә тәмам өлгереп җитә. Ул яңа идея-тематик эчтәлекне яңа формаларда бәян итү мәсьәләсен алга куя. Әлеге әсәр шуларны хәл итү юлында беренче җитди тәҗрибә буларак та әһәмияткә ия» [Ханзафаров, 2022, б. 203]. Галим фикеренчә, ул елларда комедия жанрына «үги» итеп карау, аңа юл бирмәү дә үзен сиздерә. Автор «комедия» дигән әсәре чынбарлык турында «иронияле» бәхәс-хикәят, диспут-пьеса булып чыга. Персонажларның күплеге, сюжетының киңлеге белән дә ул «кечкенә романны» хәтерләтә.

Белемле, «зыялы галим», профессор Хуҗин токарь егет Рөстәм һәм кызы Гөлсинәнең мәхәббәте белән килешә алмый: «Син, кызым, безнең бердәнбер балабыз... Синең әллә гамеңдә дә юктыр. Әмма безнең үзеңә тиң булырлык, туган итеп семьяга кабул итәрлек кеше очраса ярар иде, дип уйламый калган көнебез юк», – ди ул. Карьера хакында гына уйлаучы галимгә үзе тирәсендә эшләрлек кияү кирәклеген белдерә, шәхси «дәрәҗә»сен кайгырта. Әхмәт Хуҗин, хезмәтендә дә уңай нәтиҗәгә ирешә алмый. Аның белән эшләүче Алексей Степанович: «Безнең препарат дәвалау өчен яраксыз... Кролик үлде», – дигәч, ул: «Сез нәрсә, бу бит минем унбиш еллык хезмәтем юкка чыкты дигән сүз!» – дип, фәнни эшенең файдасыз тәмамлануын таный [Хөсәенов, 1979, б. 59].

Замандашларның әхлакый йөзен мәхәббәт һәм гаилә мөнәсәбәтләре аша тасвирлау Ш. Хөсәеновның «Чулпан» (1956) драмасында медицина өлкәсендә белем алучы Чулпан һәм Вилдан образлары аша тасвирлана. Вилданның тормышта максатлары зурдан. Вакыйгалар үстерелешендә егет Чулпанны җиңел акыллы, тормышта җитди максаты булмаган бер кыз буларак кабул итә башлый һәм ташлап китә.

Алга таба Вилданга мәхәббәте суынмаган Чулпан белән Илдар арасында җитди мөнәсәбәтләр тумас кебек тоела. Әмма егетнең ихлас хисләре Чулпанны әсир итә. Әсәрдә егетнең әнисе Шәмсебану һәм аның кызы Фәридә яңа гына гаилә корган Чулпан һәм Илдарны өйдән чыгып китәргә мәҗбүр итәләр. Яшьләр үзләренә яңа куыш коралар. Мәскәүдә диссертация яклаган Вилдан исә югары кан басымыннан дару уйлап таба. Фәнни эшен яклаганнан соң, аны ялгызлык хисе биләп ала башлый. Шул мизгелдә ул элеккеге мәхәббәте Чулпанны исенә төшерә, бу аның бар тынычлыгын ала. Беренче вакытларда Вилданга каршылык күрсәткән Чулпанда мәхәббәт хисләре янәдән кабына. Вилдан исә Фатыйма апаны үзе уйлап тапкан кыйммәтле дару белән дәваларга вәгъдә итеп, кызның тәмам башын әйләндерә. Ләкин соңыннан «әниең безнең бәхетебезгә киртә, күтәрә алмаслык йөк булачак» дип, аны хастаханәдән өйгә алып чыгудан да баш тарта. Шушы вакыйгалардан соң, кыз Вилданнан баш тарта һәм Илдар алдында гафу үтенә. Гомумән, Ш. Хөсәеновның сәхнә әсәрләренә геройларның фикри каршылыклары аша совет режимы тудырган әхлакый проблемаларны кискен итеп кую характерлы.

Н. Исәнбәтнең озак еллар Татар дәүләт академия театрында уйналган «Зифа» комедиясе сәнгатьчә эшләнеше, проблематикасы белән аерым урын алып тота. Ул мещаннарны, карьеристларны көлү объекты итеп ала, совет кешесенең әхлакый сыйфатларын яктырта, коммунистик әхлак нормаларын пропагандалаган җәмгыятьтә яңа шартларга яраклашырга омтылучы мещанлык күренешен фаш итә. Үз эшләрен хатыны Зифадан эшләтеп читтә йөри башлаган Айдар, фатир, йомшак ир, акча, җиңел тормыш аулап йөргән Эсмеральда, сихерләр белән көн итүче, Бикәмәткә кияүгә чыгарга хыялланган Кәләмзә, ирләрнең чит хатыннар белән чуалуын табигый хәлгә санаган Илдархан Балтаев, гайбәт ташучы Әйшә һ. б. – шундыйлардан. Вакыйгалар үстерелешендә Зифа белән Айдар, ялгыш юлга керүләрен аңлап, хаталарын төзәтәләр, шул рәвешле гаиләләрен саклап калалар. «Катлаулы мөнәсәбәтләр Н. Исәнбәтнең «Рәйхан» драмасында шәхси психологик конфликт, драматизм рәвешендә ачыла. Ил азатлыгы өчен көрәш юлын үткән кешеләр – Рәйхан, Морат, Гәрәйләр кабат югары әхлак кануннары яктылыгында сынала» [Ханзафаров, 2019, б. 69]. Драматург әхлакый кыйммәтләрнең сакланышына игътибарын юнәлтеп, аерым кешеләр характерындагы кимчелекләрдән көлә. Н. Исәнбәтнең психологик конфликтка корылган «Рәйхан» драмасында да төп геройларның әхлакый сыйфатлары мәхәббәткә мөнәсәбәттә ачыла. Ил азатлыгы өчен көрәштә данлы юл үткән Рәйхан, Морат, Гәрәйләр югары әхлак кануннары яктылыгында сынала. Биредә шәхси теләкләр җәмгыять алдындагы бурыч белән бәйле. Әйтергә кирәк, әсәрдә һәр герой күңел газабы кичерә. Рәйхан заманында Моратның хәрби хезмәттән соң укуын ташлавын, сөйгәненнән дә шуны таләп итүен кичерә алмаган. Моратның, еллар үткәч, Рәйхан артыннан кайтуы – яшьлек хатасын тануы. Рәйханның тормыш иптәше Гәрәй үзен

үлем тырнагыннан коткарган кешенең (Моратның) бәхетен урладым дип борчыла. Әмма совет тәрбиясе алган бу кешеләр дуслык, мәхәббәт хакына бер-берсенә авырлык китермәү җаен табалар: Морат китеп бара. Шунысы да игътибарга лаек: биредә производство темасына мөрәҗәгать итү, төп героиняны эш процессында гына күрсәтү аны берьяклырак ясый. Заман тормышын сурәтләүдән тыш, драматурглар үткәнгә дә игътибар бирә. Сугыштан соңгы байтак пьесаларның үзәк геройлары – фронтта чыныккан ир-егетләр. Ватан азатлыгын саклауда зур батырлыклар күрсәткән бу геройлар – хезмәттә дә тынгысыз көрәшчеләр, завод-фабрикаларны, авыл хуҗалыгын аякка бастыруда алгы сафта баручылар. Конфликтсызлык «теориясе» хакимлек иткәндә мондый актив геройның әдәбиятка керүе, сәхнәгә менүе, әлбәттә, эзлекле драматик хәрәкәт тудыра, пьесаларны шактый җанландыруга китерә [Ханзафаров, 2023, б. 68].

Билгеле булганча, 1953 елда Сталин үлә һәм партиянең XX съездында (1956) «шәхес культы» фаш ителә. 50 нче еллар уртасында М. Җәлил һәм репрессияләнгән татар әдипләренең (Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Х. Туфан, С. Рәфыйков һ. б.) иҗаты халыкка кайтарыла, тарихи шәхесләргә дә игътибар арта [Гарипова, Миңнуллина, б. 18–20]. Н. Исәнбәт Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең фашист тоткынлыгындагы батырлыгын татар әдәбиятында беренче булып чагылдырган «Муса Җәлил» трагедиясен (1956) иҗат итә. «Муса Җәлил» трагедиясендә шагыйрь белән илбасарлар арасында барган фаҗигалы бәрелеш Җәлилнең ватанчылык хисен, халкына, Туган иленә бирелгәнлеген, милли горурлык белән янып яшәвен күрсәтә. «Драматург иҗат максатын «шагыйрь һәм тиран көрәшен күрсәтү» дип билгеләсә дә, чынлыкта пьеса тагын да киңрәк колач ала. Ул заман проблемалары, халык язмышы, идеяләр көрәше турында әсәр булып үсә» [Ханзафаров, 2018, б. 68]. Шәхес язмышы ил, Ватан язмышына әверелә. «Муса Җәлил» трагедиясендә дә драматург сугыш афәтендә буыннар, милләтләр фаҗигасын чагылдырырлык геройлар таба. Н. Исәнбәт туган җирләреннән алман иленә күчеп киткән, туганлык җепләрен югалткан Зәбир Альбиков нәселенең өч буын вәкилләрен сурәтли: Зәбиргә, Лыков кебек, туган җиренең малы гына кирәк; улы Фәрит туган телен оныткан, халкының милли йолаларын белмәгән һәм белергә теләмәгән каты күңелле кеше булып үсә – Бөек Ватан сугышында ватандашларына каршы көрәш юлына баса. Гореф-гадәтләреннән, теленнән аерылган, туган халкының җырын ишетүгә сусап яшәгән Газизә карчык туган туфрагына кайтып үлү теләгенә дә ирешә алмый.

1950 еллар сәхнә әдәбиятына жанрлар төрлелеге хас. Бу елларда тарихи-биографик, тарихи-революцион драма, фольклористик жанрлар активлаша (Ә. Фәйзи «Пугачёв Казанда», Х. Вахит «Гомер сере», Р. Ишморат «Үлмәс җыр» һ. б.). Шулай ук комедия жанрына игътибар көчәя. (Г. Насрый «Кушамат», «Яшел эшләпә»; Г. Зәйнашева «Көйсез кияү» һ. б.). Төп темалар буларак сугыш, кыенлыкларны җиңү өчен

көрәш, эшчеләр һәм зыялылар тормышы, кеше бәхете һ. б. аерылып чыга, конфликтсызлык теориясе хөкем сөрә. Төзелешләр, хезмәт җиңүләре белән мавыгып, драматурглар еш кына кеше шәхесен икенче планда калдыралар. Фронтта туган илен саклаган геройның тыныч тормыштагы бюрократлык, эгоизм, карьерачылык һ. б. тискәре күренешләргә каршы көрәшкә чыгуы күзәтелә. Рус әдәбиятының һәм элеккеге СССРдагы милли әдәбиятларның 1940–1950 еллар аралыгын Н.Л. Лейдерман «совет әдәбияты тарихының хурлыклы чоры» дип билгели, һәм моның сәбәпләрен сүз сәнгатенең, рәсми идеологиягә ярарга тырышуы, коммунизм төзү турындагы фикерләрнең алга куелуы белән аңлата. Шулай да, сугыштан соңгы еллар әдәбияты халыктагы җиңү шатлыгын, аның батырлыгын гәүдәләндереп, батыр татар кешесе образы, туган ил хакындагы күзаллау 1950 еллар татар драматургиясе дөнья сурәтенең нигезен хасил итә.

### Әдәбият

*Гарипова Л., Миннуллина Ф.* Пьеса «Сююмбике» (Ханбика») М. Загитова и ее анализ на страницах периодической печати // Казанская наука. 2020. № 5. С. 18–20.

*Насрый Г.* Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 256 б.

*Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. Казань: ИЯЛИ, 2016. 360 с.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р. Ф. Рахмани]. Казан: Фолиант, 2017. 5 т. 826 б.

*Хатипов Ф.* «Егет сүзе» // Казан утлары. 1958. № 8.

*Ханзафаров Н. Г.* Татар драматургиясе: күзәтүләр, иҗат портретлары: фәнни һәм тәнкыйть мәкаләләре. Казан: ТӘһСИ, 2022. 264 б.

*Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 158 б.

*Хөсәенов Ш.* Профессор кияве // Хөсәенов Ш. Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. Б. 167.

*Шәрипова А.С.* Юныс Әминев драматургиясендә әхлакый-гуманистик концепция. Казан: ТӘһСИ, 2018. 144 б.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулловна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 392

*З.М. Брусько*

# КИНДЕР ЧӘЧСӘҢ, КҮЛМӘК КИЯРСЕҢ...
## Татар халкының киндер эшкәртү өмәләрен фольклор яссылыгында тикшерү

Статья посвящена описанию этапов возделывания и обработки конопли, представляющей собой незаменимое сырье для изготовления одежды, домашнего текстиля, а также растительного масла татарами в прошлом. Проделана большая работа по обобщению лексики, синтаксических единиц, отражающих выращивание, сбор урожая, обмолот, прядение, отбеливание, ткачество, окрашивание пряжи, сбивание масла, приготовление еды из семян и масла конопли. Мысль о значимости данной культуры в повседневной и обрядовой жизни татар подтверждается демонстрацией текстов многочисленных пословиц, примет, загадок, которые демонстрируют те или иные ее качества, а также особенности обработки. Детальное описание всех этапов обработки конопли в их хронологической последовательности, сопряженное богатым текстовым материалом, воссоздает целостную картину бытования данной трудовой практики у татар в прошлом.

**Ключевые слова:** татары, конопля, помочи, работа, молотьба, женщины, одежда, приданое, еда.

The article is devoted to the description of the stages of cultivation and processing of cannabis, which is an indispensable raw material for the manufacture of clothing, home textiles, as well as vegetable oil by Tatars in the past. A lot of work has been done to generalize vocabulary, syntactic units reflecting cultivation, harvesting, threshing, spinning, bleaching, weaving, yarn dyeing, churning oil, cooking from seeds and hemp oil. The idea of the importance of this culture in the daily and ceremonial life of the Tatars is confirmed by the demonstration of the texts of numerous proverbs, signs, riddles that demonstrate certain of its qualities, as well as processing features. A detailed description of all stages of cannabis processing in their chronological sequence, coupled with rich textual material recreates a holistic picture of the existence of this labor practice among the Tatars in the past.

**Keywords:** Tatars, hemp, labor help, job, threshing, women, cloth, dowry, food.

Күп көч һәм вакыт сорый торган эшләрне халкыбыз гомер-гомергә күмәкләшеп, өмә ясап башкарган. Бергәләшеп эшләүнең ялгыз эшләүдән күпкә күңеллерәк икәне, тиз арада үзең генә башкарып чыга алмаслык әллә никадәр эшнең эшләнүе турында татар халкы үзенең мәкаль-әйтемнәрендә бик төгәл әйтеп калдырган. Алар арасында «Күпнең эше күңелле», «Ялгыз кулдан тау чыкмас», «Бергәләп эшләгән эш ырамлы була», «Эш бергәләп эшләгәндә генә ырый» [Исәнбәт, 2010, т. 1, б. 234], ягъни үрчемле, алга китүчән була дигәннәре аеруча үтемле. Өмәләрнең һәркайсы авыр эш белән бәйләнгән булса да, аларга чакырылган кешеләр бик теләп катнашкан. Яшьләр

исә мондый ярдәмләшү чараларын аеруча үз иткән, берсеннән дә калмаска тырышкан. Өмәдә катнашу алар өчен, бер яктан, эшкә өйрәнү, тәҗрибә туплау, кул арасына керү булса, икенче яктан, очрашу, аралашу, эшләгән арада күңел ачып калу мөмкинлеге дә булган.

Өмәгә якын туганнар, күрше-күлән, авылның җиткән кызлары, киленнәре, егетләре-ирләре, яшүсмер кызлар һәм малайлар киләләр. Халкыбызның киндер эшкәртү өмәләрендә, кагыйдә буларак, хатын-кызлар катнаша. Алар арасында яшүсмер һәм буй җиткән кызлар да була, әлбәттә.

Киндернең туган ягы дип Үзәк Азия атала, ә безнең якларга ул инде Урта Азия аша килеп җиткән. Борынгы бабаларыбыз аны якынча IX гасырдан бирле үстереп, үзләренең көнкүрешендә куллана башлаганнар. Аны һәркем бәрәңге бакчасында да, үзләренә бүлеп бирелгән имана җирендә дә үстергән. Күмәк хуҗалыклар басу-кырларына да күпләп чәчкән аны. Киндер чәчелгән мондый җирләр авыл кешесе телендә «киндер җире» дип атап йөртелгән. Киндернең күпләп үстерелүе һәм моның авыл кешесе өчен гадәти күренеш булуы турында без халкыбыз телендә сакланып калган топонимик атамалар, җырлар аша яхшы беләбез. Беренче чиратта, киндер тукыма җитештерү өчен кирәк булган. Сүзен гаять оста, төгәл итеп әйтә белгән татар халкы бу турыда «Киндер чәчсәң, күлмәк киярсең» [Исәнбәт, 2010, т. 1, б. 571] дигән мәкаль теркәп калдырган. Ләкин, тукыма булып, кешене эсседән, салкыннан саклаудан тыш, киндер бик туклыклы һәм файдалы май бирүче үсемлек тә әле. Мае сыгылган орлыкны төрле ризыкларга кушып ашаганнар, түбәнрәк сыйфатлысын (түбен) малларга азык буларак файдаланганнар әби-бабаларыбыз. Димәк, киндер тулаем калдыксыз үсемлек булып чыга.

Тукыма җитештерү үзе үк күптөрле йолалардан тора һәм елның төрле фасылларына бүленә. Иң элек киндерне чәчкәннәр, бу эш, гадәттә, сабан ашлыгын чәчкәннән соң башкарылган. Табигать шартларына җиңел яраклашучан, нәзберек булмаган, артык хәстәр сорамаган киндер үз вакыты белән тишелеп, гөрләп үсәргә дә керешкән. Ә инде уңышының ничек буласын борынгыдан калган сынамыш буенча чамалаган авыл кешеләре: «Кузгалак көпшәсе юан булса, киндер уңар» [Исәнбәт, 2010, т. 1, б. 213], дигәннәр. Киндер бик үзенчәлекле үсемлек: аны ике тапкыр җыярга кирәк булган. Башта, чәчәк аткач та, ата үсемлекне, ул халык телендә «баса» дип аталган, арадан кереп, чүпләп, йолкып алганнар. Эшне бернинди җайланмаларсыз, бары тик кул белән генә башкарганнар. Чүпләү-җыйнау эше бала-чага һәм хатын-кызлар эше саналган. Киндер арасына кереп киткән бала-чагаларның чыр-



Буа районы, Каганович исем. колхоз колхозчысы Нәүбәһар Садыкова киндер йолкыганда. «Азат хатын» журналы (1940 ел, № 8)

чуы белән бергә, буй җиткән кызларның, киленнәрнең үзара көлешеп сөйләшкәннәре, ара-тирә җыр сузулары әллә кайларга ишетелеп торган. Көзгә кеше буеннан берничә мәртәбә биегрәк булып үскән ана киндернең орлыгы сугып алынган, аның сабакларын бераз йомшартыр өчен кеше, атлы арбалар күп йөри торган юлларга түшәп, я икеөч атнага ташлар белән бастырып, суга батырып куйганнар. Аларны салларга төяп күл уртасына кадәр кереп суга батыру, вакыты җиткәч, судан чыгарып киптерү, аннан арбаларга төяп авылга алып кайту кебек авыр эшләрдә ир-атлар да булышкан. Авылга кайткан киндерне бераз вакытка каралты түбәләренә, ындыр табакларына куеп торганнар да, тәмам киптереп бетерер өчен, җылы мунчаларга керткәннәр. Озаклап суда яткан, кояш кызуында, аяк астында теткәләнгән киндер бу вакытка инде бераз сүсләнә, җепселләргә аерыла, шул рәвешле алда башкарылачак әллә никадәр эшкә әзерлеген башлаган була.

Инде киндерне талкыр вакыт та килеп җитә. Җыеп алган киндерен эшкәртү өчен авыл кешесенең әле берсе, әле икенчесе өмәгә дәшә башлый. Авылның уңган-булган хатыннары, буй җиткән кызлары үз талкыларын, киле-кисапларын алып, өмә буласы өйгә җыела – сүсне талкышыннан аеру, йомшарту, аннан киндер төю эшенә керешәләр. Көлтәләп бәйләнгән киндерне яткан җиреннән алып чыкканда ук читәнгә бәреп-бәреп алалар, янәсе, коеласы чүбе коела торсын. Инде төп эшкә дә керешергә була. Ләкин башта хуҗабикә барысын да әле генә табадан төшкән кайнар коймагы, кабартмасы белән сыйлап чәй эчерә. Өмәчеләр биш-алты киледә өчәрләп-дүртәрләп басып, көлешә-көлешә, мәзәк сүзләр сөйләшеп, җырлый-җырлый киндернең талкышын («киндер сөяген») коя башлыйлар. Бөтен тирә-юньгә талкының «дөп-дөп» иткән тавышы тарала, апалар-кызлар шушы үзенчәлекле, эшкә дәрт өсти торган талкы көенә кинәнеп эшли бирәләр. Бу эшнең нәтиҗәсе булып талкышлары төшеп беткән киндер сабакларыннан буй-буй сүсләр барлыкка килә. Алар тәмам йомшарып, мамык хәленә киләләр. Ләкин җеп эрләрлек хәлгә килгәнче, бу сүсләрнең әле тагын әллә ничә төрле хезмәт процессы аркылы үтәсе – зур агач килеләргә салынып вакланып беткәнче төеләсе, тәрәшләргә эленеп тараласы бар. Киндерне талку, төю җиңел эшләрдән түгел, бертуктамый хәрәкәт итүдән куллар арый, кипкән киндер кабыгыннан күтәрелгән тузан тын юлларына утыра, күзләрне әчеттерә. Ләкин бергә эшләгәнгә эшнең авырлыгы әллә ни сизелми, аралашу, шаярышу, җыр артыннан җыр җырлау эшкә ямь өсти, күңелгә рәхәтлек бирә. Чират төелгән сүсне тарауга (тәрәшләүгә) җитә. Тәрәш тарагын сөям агачыннан (кабыгы төшерелгән юкә агачы) ясарга тырышалар, мондый тарак җиңел дә, юка да килеп чыга. Сүс тарау – үзенчәлекле, тәртибен белеп кенә эшләнә торган эш. Беренче кат таралган сүс капчык сугарга, мүк белән бутап бүрәнә арасына кыстырырга, икенче кат таралганы – киндер ыштан, тастымал, чаршау, сәке япмасы кебек тупасрак тукымалар тукырга, ә инде өченчесе, иң нечкә һәм чиста өлеше – затлы тукыма әзерләргә тотыла. Татар халкының данлыклы

кызыл башлы сөлгесе, бәйрәмнәрдә кияргә дигән күлмәкләре соңыннан шушындый тукымадан тегелә. Шушылай эшкәрткәннән соң өмә башында көлтәдән алынган киндернең авырлыгы биш тапкырга кими. Ә бит ишле гаиләнең өс-башын карарлык, кияүгә китәсе кызларның бирнә сандыгын тутырырлык тукыма әзерләү өчен күпме киндер җеп кирәк булган! Кыз бала бирнә сандыгының ничек тутырылуы турында сабый чагыннан ук белеп, моңа үз өлешен кертеп үскән. Аның бу турыда белә башлавы басуда өлкәннәр белән бергә киндер йолкыган вакытта нәни кулларына киндер сабагының шырпысы кереп авырттырган көннәргә барып тоташа. Шулай әзерләнгән киндерне кара көзгә кадәр алып куеп торалар да, вакыты җиткәч, яңадан өмәгә җыелып, эрләү эшенә керешәләр.

Эрләү өмәләре өйдә уздырыла. Көн кичкә авышып, өйдәге эшләр беркадәр каралгач, хатын-кызлар үзләренең каба-орчыкларын алып, инде эшкә ярардай кыз балаларын да ияртеп, кичке утырмага җыелалар. Кыз балалар читтән карап утырыр өчен генә килми монда, алар да сүс эрли, үзеңә яңа күлмәк була дия-дия кызыктырып, әниләре шулай эш рәтенә өйрәтә аларны. Яңа күлмәк кызыктыра инде, әлбәттә, булыр-булмас нечкә бармаклары белән сүс бөтерә кызлар. Эрләгән җепләре әллә ни тигез, әллә ни ыспай килеп чыкмаса да, тырышулары бушка китми аларның, өмә саен остарганнан-остара барып, торабара сүснең дә яхшырагын эрләүгә күчәләр. Татар халкының «Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен булыр» дигән әйтеме сөйләмгә нәкъ менә шушындый очракларда килеп кергәндер, мөгаен.

Киндер эрләү утырмаларына яшь кызлар үзләре генә дә җыелырга ярата. «Киндер өсте» дип аталган мондый вакыт һәр авылда күрше авыллардан кунак кызлары килү белән үзенчәлекле. Ике-өч атнага кунакка киткән кызларына ата-анасы бер киләплек (өч метр тирәсе) сүс үлчәп җибәрә, кыз сынатмаска тырыша, кайтып киткәнче киләбен тутырып бетерә. Эш артында вакытның төнгә авышканын сизми дә кала кызлар. Ләкин ата-аналары кызларының болай озак утырууларына каршы бер сүз дә әйтмиләр, киресенчә, кич утыру алдыннан аларга бераз гына йоклап алырга вакыт та бирәләр.

Кызлар булган җиргә егетләр дә килми калмый, билгеле. Олылар яшьләргә танышу, аралашу өчен мөмкинлекләр чикле булганын аңлап, аларның килүенә каршы төшмәскә тырыша. Мондый очрашуларның егет өйләндерү, кыз бирү кебек бик мөһим эшләрнең башлангычы булып торуын, яшьләргә бер-берсен күзләр, сынар өчен кирәк булуын аңлый алар. Егетләр дә, кызлар да үзләрен әдәпле, тыйнак, сөйкемле итеп тотарга тырышалар, чөнки берсенең үз-үзен тотышы икенчесенең игътибарыннан бер дә читтә калмый. Эш күңелле уеннар, гармунга кушылып җырлау, бию белән үрелеп бара. Монда уйнала торган үзенчәлекле уеннарның берсе «Киндер очы» дип атала. Ул – бәхет сынау уены. Бу уенны уйнар өчен кызлар хәстәрен алдан күрәләр. Элегрәк суккан киндерләреннән әйбер кисеп тегә башлаганда артып калган очын җыеп куялар. Шушы тукыма кисәген уң

кул беләгенә бәйләп урамга чыгалар. Беренче нинди кеше очрый – картмы, яшьме, баймы, ярлымы, шуның буенча үзләренең киләчәк язмышларын юрыйлар [Сүнчәләй, 1971, б. 184].

Уен уен белән, ләкин бу өмәнең дә төп максаты булып барыбер эш эшләү тора: киндерне эрләү, аны киләпләргә сару кебек эшләр бер утыруда бетмәсә, кабат җыелу турында сөйләшеп куялар. Ә инде эшләрнең болары тәгәлләнгәч, җепләрне агарсын өчен көл белән бутау, көлле суда кайнату, юу, мич башларында янә киптерү, яз башында салкынга алып чыгып катыру эшләре башкарыла. Болай иткәч, коңгырт-соры төстәге киндер җепләре күзгә күренеп агара, тагы да йомшара төшеп, ефәк шикелле нәзек, шома җепләргә әйләнә. Кияүгә китәсе кыз бирнәсенә дигән киндерен аеруча зур тырышлык белән агарта, көлнең дә иң чистасын, вак иләк аша иләнгәнен, зиректән әзерләнгәнен алырга тырыша. Менә шушы эшләрдән соң инде тукыма сугу эшенә күчәргә дә була.

Озын-озак кышкы кичләрдә киндер станнары артында күпме утырылган да, ничәмә-ничә дистә аршын тукыма сугылган! Кул эшләренә бик һәвәс татар хатын-кызлары бу эштә дә үзләренең бөтен осталыгын, сәләтен күрсәтә алган. Гаҗәеп бизәкләре, төрле-төрле төсләре белән күңелне әсир итәрлек нинди генә әйберләр үтмәгән алар кулыннан: кызыл башлы сөлге, ашъяулык, тастымал, чаршау, чыбылдык, пәрдә, җәймә, келәмнәр... «Бу әйберләр өй эчен ямьләү, өйгә «кот кертү» өчен кулланылган. Яшь киленнең киявенә һәм киявенең кардәш-ыруларына дип алып килгән туй бүләге – бирнәсе бөтенләе белән суккан киндердән әзерләнгән. Бием, биатасына, каенагалары, каенишләренә, каене, каенигәчләренә бирнә бүләге итеп күлмәклекләр, намазлыклар, аяк чолгаулары, капка ачучыга, мунча ягучыга, урын җәючегә сөлгеләр киленнең уңганлыгын, осталыгын күрсәтеп торган күркәм әйберләр булган. Киндердән сугылган кызыл башлы сөлгеләр ил күзендә бигрәк тә абруйлы саналган. Сабан туйлары алдыннан яшь киленнәрдән сөлге алу йоласы яшәгән. Сабан туйларында мәйданга ямь биреп, көрәшүче, узышучыларны җиңүгә дәртләндереп җилфердәгән бу сөлгеләр азактан мәйдан тоткан батырларга, бәйгеләрдә алга чыгучыларга ил бүләге итеп бирелгән» [Вәлиев, 1967, б. 127].

«Җитен-киндер ай яктысында агара, имеш», «Бер кояшта киндер киптергәннәр» [Исәнбәт, 2010, т. 2, б. 383]. Халкыбызның әлеге мәкальләре киндер белән инде тукылганнан соң башкарылган гамәлләргә нисбәтле әйтелә. Җеп хәлатендә инде бер кат көлдә чистартылган булса да, тукымага әверелгән киндерне кабат көлгә манып, кайнар мичтә пешекләп, юып-чистарталар да, язгы җепшек кар өстенә чыгарып җәяләр. Көннәрен, төннәрен шушында уздырып, ул үзенә карның аклыгын, кояшның җылысын, айның сафлыгын җыя, тагы да агара, ямьләнә төшә. Киндер агарту күренеше бик матур булып халкыбызның җырларына да килеп кергән. Авылының бер чибәр кызына күзе төшкән егет болай дип җырлый:

*Биек тауда, гөлбакчада*
*Кызлар киндер агарта.*
*Әйтче, сеңлем, конфет бирәм,*
*Апаң кемне ярата?*
[Рәхимова, 2018, б. 16]

Инде менә киндерне кар өстеннән җыеп алуга да байтак вакытлар үтеп китә, карлар эреп бетә, ташу кайта – киндер тукмаклар (киндер ору) чак та җитә. Бу гамәлнең нәкь менә шушы вакытта башкарылуы халкыбызның «Җәйгә чыккач, киндер тукмакла» дигән мәкалендә дә чагылыш тапкан.

*Әйли чабата, читек түгел аякта.*
*Бии белсәң чабата*
*Шап та шап шапылдата.*
*Әйли без әле,*
*Безгә бәйләнмә әле.*
*Бәйләнерсең, арырсың,*
*Мәсхәрәгә калырсың.*
*Әйли без әле,*
*Баскан саен өз әле.*
*Ярың күрми кичә түздең,*
*Бүгенгә дә түз әле.*
[Булатов, 1992, б. 145]

Язгы матур кичләрдә авылның кызлары, яшь киленнәре көндәлек эшләрен тәмамлап, киндер тукмакларга чыга. Эшләрен һәрвакыттагыча җырлый-җырлый, такмаклый-такмаклый башкаралар алар. «Киндерне сары гәрәбәдәй итеп юылган такталарга катлы-катлы итеп җәяләр дә, аның тирәсенә дүрт яки сигез кыз баса. Арадан берсе: “Башладык!” диюгә, кулларындагы бәләкләр белән киндерне тукмакларга керешәләр. Оста тукмаклаучылар булганда, тирә-юньгә искиткеч матур ритмлы бер көй тарала. Аргы очтан ишетелгән дәртле киндер тукмаклау көенә бирге очта теттереп алып биергә була. Киндер тукмаклаучылар авылның әллә ничә җирендә эшли – бер урындагылар аз гына тынып торган арада, аларга җавап кайтаргандай, икенче урындагылар тукмаклый башлый. Барыннан да уздырыйк дип, тегеләр туктар-туктамастан, өченче урындагылар матур иттереп тыпырдатып алып китәләр. Киндер тукмаклаучыларны карарга бала-чагалар, хатын-кызлар җыела. Егетләр дә килгәли бирегә, тик алар бу эшкә бик сирәк катнашалар, шушы тирәдә чуалалар гына. Алай да, кызлар күрү, кызлар белән бер-ике сүз әйтешү бәхетенә ирешә алалар. Тукмаклагач, бәләкләгәч, билгеле инде, киндер йомшара, ялтырый, күлмәк, алъяпкыч кебек нәрсәләр тегәргә яраклы була. Бу эш шуның өчен эшләнә дә. Әмма монда яшь-җилкенчәкне бергә җыелып күңел ачу, аз булса да күңел күтәрү, бер-береңне күреп сөйләшүләр дә бик кызыктыра» [Булатов, 1992, б. 145]. Бу күренешкә карата үзенең мөнәсәбәтен белдереп, халкыбыз «Кайда кызлар тукмагы, шунда егет сукмагы» дигән мәкален дә булдырасы иткән [Исәнбәт, 2010, т. 2, б. 383].

Кием һәм көнкүрештә кулланылган тукымаларны бизәү, аларга төрле төс бирү серләрен дә белгәннәр татар хатын-кызлары. Тукыма ману өчен табигать нигъмәтләре – җиләк-җимеш, үлән һәм агачларның кайрысы, яфраклары, чәчәкләре, тамырлары кулланылган. Аларның кайсын кайчан җыю, ничек киптерү, нинди шартларда саклау, кайсыларын нәрсә белән кушсаң нинди төс килеп чыгу – болар барысы да – анадан кызга тапшырылып килүче мирас, тормыш-көнкүреш итүгә караган мең дә бер киңәш арасында кирәклеләрдән саналучы бәһасез белем. Тукыма буяуда кулланылган иң борынгы буяулар имән, зирек һәм эт шомырты кайрысыннан ясалган. Алар ярдәмендә тукыманы коңгырт, куе зәңгәр, кызгылт-сары төсләргә манып булган. Алабута яфракларын кызыл төс алыр өчен файдаланганнар. Ә менә сары мәтрүшкәнең чәчәкләре һәм яфраклары шулай ук кызыл һәм сары төсләр биргән. Сары төсне әле болардан тыш, эт тигәнәгеннән, суган кабыгыннан да ясаганнар. Яшел төс кирәк булганда, кычытканның яфраклары, кыргый миләшнең тамыры, усак агачының күркәләре ярдәмгә килгән. Киемгә төс кертү эше үзенә күрә бер тылсымлы йолага әверелгән. Зур казандагы суда төн кунган кайрыны иртән утка куйганнар, кайнап чыкканнан соң, тагын бераз утта тоткач, төс кергән суны агызып алганнар. Казанга тагын су өстәлгән, тагын кайнаган – төсе чыгып беткәнче шулай дәвам иткән. Инде җыелган буяулы суны яңадан утка куеп, биштән бер өлешкә кимегәнче кайнатканнар һәм сөзелгән кайнатмага алдан ук селте суына манылган тукыма яки җепләрне салганнар. Шунда ук бер тимер кисәге дә салып җибәргәннәр. Селте буяуның уңмавы, ә тимер җепкә төсләрнең яхшырак сеңүе өчен кирәк булган. Кайчагында тукыманы буярга озатыр алдыннан аның кайбер өлешләрен төйнәп куя торган булганнар. Болай иткәч, тукымада үзенчәлекле чачаклы-чуклы бизәкләр барлыкка килгән. «Басма киндер» [Рәхимова, 2018, б. 37] дигәне менә шушындый булган. Талгын утта буяулы суда берничә сәгать кайнаган тукыма. Аннары салкын инеш суында чайкалган. Менә шушы үзе катлаулы, үзе искиткеч мавыктыргыч эш барышында күз явын алырлык гүзәллек – салават күперенең барлык төсләрендәге тукымалар барлыкка килгән.

Киндер белән гомер иткән халкыбыз гомере буе тугры булып калган аңа. Киндер белән өстен-башын каплаган, өен киендергән, ризыкланган, мал-туарын ашаткан. Җырларында аңа дан җырлаган, табышмак, мәкаль-әйтемнәрендә мәңгеләштереп калдырырга тырышкан. Киндер эшкәртүнең нечкәлекләрен белү өчен, мәкальләргә бер күз төшерү дә җитә. «Киндерне башлау белән бетерү кебек» дигән мәкаль, мәсәлән, киндернең чәчкәннән алып тукыма халәтенә килгәнче үткән юлын күз алдында тота, бу юлның бик озын икәненә ишарә ясый. «Талкышны күпме талкысаң да, талкыш булыр», «Килегә салып су төймиләр», «Актык тәрәшлесенә ябышкан» дигәннәре исә киндерне талку, тарау/тәрәшләү кебек күренешләрне искә төшерә. Ә инде апалар, кызларның утырмаларга җыелып киндер эрләүләре, бу эшне җырларына кушып, көлешеп-шаярышып, күңелле сүзләр сөйләшеп

эшләүләре «Эрләргә сүс булсын, сөйләргә сүз булсын» дигән мәкальгә кереп калган. Шул ук вакытта сүс эрләүнең ансат эш түгеллеге, моңа түземлек, зур осталык кирәклеге турында да хәбәр итә безгә халык мәкальләре. «Нечкә эрләгәнне көтүе озак» дип искәртә шундыйларның берсе. Телебездә бик еш кулланылган «киләп сару» гыйбарәсе киндер эрләү эшенең аерылгысыз өлешен – җепне чуалмасын өчен махсус эшләнгән агачка – киләпкә урап баруны күз алдында тота. Орчыкның бу эш барышында бертуктаусыз бөтерелгәләп, йөгергәләп торуы торабара арлы-бирле йөреп торучы кешегә карата әйтелә башлаган. Эрләү эшен халкыбыз табышмагына да яшергән. «Юкәгә утыр, өрәңгегә кара, бабаңның сакалын тара» дигән сүзләр белән юкәдән ясалган кабасын, өрәңгедән эшләнгән орчыгын һәм киндер сүсен сурәтләгән. Эрләнгән сүсне туку киндер эшкәртү эшләре арасында иң үзенчәлеклесе, иң могҗизалысыдыр, мөгаен. Кыш буена, язгы эшләр башланганчы, хатын-кыз тукыма суккан. Туку төрләренең ниндиен генә үзләштермәгән ул үз гомерендә: шакмаклап, буйга, чүпләмләп, алмалап суга белгән. Үзенең күңел җылысын, изге теләкләрен куллары аша тукылган сөлге-тастымалларына, ашъяулык-эскәтерләренә күчереп, башкаларга җылылыгын өләшкән. Туку җиңел эшләрдән булмаган, станда нык итеп утырырга, колачны җәеп тартып, ишеп суга белергә кирәк булган. Тукучының бу халәте табышмакта да тасвирлана: «Очып барган кош күрдем, утырып торган таш күрдем». Хезмәте авыр булса да, башкарган эшнең нәтиҗәсе сөендергән, һәркемнең күңеленә хуш килерлек булган. Юкка гына халык телендә «Киндер ыстаны киендерә, чүпләме күзне сөендерә» дигән мәкаль барлыкка килмәгәндер. Моның шулай икәнен «Кызлар тукыган киндерә яшь йөрәкне сөендерә» дигән мәкаль аша да күрә алабыз. Киндер киемнәрне матурлыгы өчен генә түгел, тәнгә рәхәт, җылы, чыдам булганы өчен дә үз иткәннәр. Үз кулларың белән тукылган киндернең соңыннан гәүдәңә килешеп торырлык кием буласын күздә тотып, «Кулың белән тукыганыңны инең белән туздырырсың» диясе иткәннәр. Халык ышануларының киемгә кагылышлылары арасында кешенең кырыгыннан соң киеменең сүрүе китә, хуҗасы белән бергә «сүтелә» дигәне дә бар [Миңнуллина, 2019, б. 17]. Бу исә халкыбызның киемен тузып беткәнче кию гадәте турында сөйли. Кемнең дә булса яңа кием кигәнен күргәч әйтелүче, «җылы тәнеңдә тузсын» дигән теләк тә күпмедер дәрәҗәдә шушы ышануны чагылдыра, димәк.

«Пәҗи килегә кермичә мае чыкмас» дигән мәкале дә бар халкыбызның. Бу исә әби-бабаларыбызның киндерне ризык буларак кулланганлыгы турында сөйли. Кайбер төбәкләрдә киндерне шушы сүз белән атап йөртәләр, аның үз чиратында «кара пәҗи» (иртә өлгерә торган киндер) һәм «сары пәҗи» (соңрак өлгерә торган киндер) дигән атамалары да билгеле [Хәйретдинова, 2017, б. 312].

Киндерне ризык иткәнче дә шактый көч куярга кирәк булган. Орлыгыннан май алу өчен аны иң элек мичкә куеп киптергәннәр, аннан агач килегә салып, кабыгы орлыгыннан аерылганчы, орлыгы он

булганчы озаклап төйгәннәр. Төйгән орлыкны, савытка салып, бик әйбәтләп, мае калмаслык итеп сыкканнар. Киндер маен да, мае сыгып алынган киндер орлыгын да үзенә күрә кулланганнар. Киндер орлыгы кушып пешерелгән ризыкларның тәме әле дә авызда тора, дип искә ала аларны кайчандыр ашап караган кешеләр. Бәрәңге тәкәсе, орлык дурчмагы, кара дучмак, кыстыбый, елгыр, орлык тәкәсе, орлык пәрәмәче, чувар тәкә, кырык кат, ат тоягы, киндераш пилмәне, киндер тәкәсе – болар киндер орлыгы кушып пешерелгән камыр ашларының әле кайберләре генә. Бәрәңге боламыгына да кушып ашаганнар киндер орлыгын, болай иткәч, боламык аеруча тәмле, майлы, туклыклы килеп чыккан. Киндер орлыгы (киндераш дигән атамасы да билгеле) ашау өчен үзе генә дә тәмле булган. Мичтә куырылган орлыкны йомарлам-йомарлам итеп тә (болай иткәне «орлык әнәчәсе» дип аталган), шикәр кушып та (монысы – «баллаган орлык»), шул килеш кенә дә ашаганнар.

Татар кешесе өчен киндер туендыручы да, киендерүче дә, җылытучы да булып торган – өсләрендә киндер сүстән тукылган кием, табыннарында киндер орлыгыннан әзерләнгән ризык булган аның. Күп көч һәм вакыт таләп иткән киндер эшкәртү хезмәте авыр булса да, үзенең күмәк төстә башкарылуы, эш барышында шаян сүз, уенкөлкенең тынып тормавы, яшь-җилкенчәкнең эш тәртибенә өйрәнүе, бер-берсе белән аралаша алуы, һәм иң мөһиме – өс-башны, йортҗирне карар өчен сыйфатлы тукыма, тамакны туйдыру өчен туклыклы май алып булачагына ышану бу эшкә ямь өстәгән, аны үзгә бер дәрт белән башкарып чыгарга ярдәм иткән.

**Әдәбият**

*Булатов В.* Гореф-гадәт, йолаларыбыз // Казан утлары. 1992. № 8. Б. 129–150.

*Вәлиев Ф.* Чуптарлы һәм асалы тукымалар // Казан утлары. 1967. № 8. Б. 127–130.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 623 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 749 б.

*Миңнуллина Й.* Бу йола хәзер дә сакланып, анадан кызга тапшырылып килә // Түгәрәк уен. 2019. № 1. Б. 16–17.

*Рәхимова Р.К.* Русча-татарча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2018. 208 б.

*Сүнчәләй С.* Уеннар // Казан утлары. 1971. № 11. Б. 180–186.

*Хәйретдинова Т.Х.* Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы. Казан: ТӘһСИ, 2017. 384 б.

***Брусько Зәлия Мансур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, «Татар ядкәрләре» үзәгенең халык иҗатына караган материаллар белән эшләүче белгече*

УДК 001.32

*Р.Г. Зәкиева*

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ ОЕШУГА 30 ЕЛ

Статья посвящается 30-летнему юбилею Института Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук Республики Татарстан. Особое внимание уделяется этапам становления, структуре института и научной деятельности коллектива.

**Ключевые слова:** Республика Татарстан, Институт Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук Республики Татарстан, многотомная Татарская энциклопедия, онлайн энциклопедия Tatarica.

The article is dedicated to the Institute of Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. Special attention is paid to the stages of formation, the structure of the Institute and scientific activities of the staff.

**Keywords:** Republic of Tatarstan, Institute of Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, multi-volume Tatar Encyclopedia, online encyclopedia Tatarica.

Быел Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оешуга 30 ел тулды. Бүгенге көндә Институт – Татарстанда һәм Россиядә энциклопедик басмалар әзерли торган әйдәп баручы фәнни-тикшеренү учреждениесе.

Институт тарихы Татарстан АССР Министрлар Советының «Татар Совет Энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү турында» 1989 елның 6 сентябрендәге 339 номерлы карары нигезендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында оештырылган (1990) Татар Совет энциклопедиясе бүлегеннән башлангыч ала. Әлеге документ ТАССР Министрлар Советы рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиев тарафыннан имзалана. Бүлек 14 хезмәткәрдән тора, мөдире итеп филология фәннәре докторы Фәрит Сабирҗан улы Хәкимҗанов билгеләнә. Бүлек тарафыннан «Татар Совет энциклопедиясе» фәнни концепциясенең беренче варианты эшләнә һәм аның нигезендә татар телендә Генераль лөгатьлек әзерләнә.

1991 елда Татарстан Фәннәр академиясе оешып, аның эчке фәнни-тикшеренү структуралары булдырылганнан соң, Татар Совет энциклопедиясе бүлеге Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе составына Татар энциклопедиясе бүлеге буларак тапшырыла. Бүлек мөдире итеп тарихчы Гомәр Салих улы Сабирҗанов билгеләнә.

1993 елның 8 апрелендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президиумы Татар энциклопедиясе бүлеген Татар энциклопедиясе институты итеп үзгәртеп кору турында карар кабул итә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күптомлы Татар энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү буенча өстәмә чаралар турында» 1994 елның 3 маендагы карары нигезендә Татар энциклопедиясе институты оештырыла (2014 елдан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты). Институт Татарстан Республикасының фәнни-тикшеренү учреждениеләре реестрына кертелә, юридик зат статусын ала. Карарда Татар энциклопедиясе институты республикада нәшер итүгә әзерләнгән энциклопедик характердагы басмаларны, терминологик сүзлекләрне һәм фәнни сүзлек-белешмәләрне фәнни-эксперт бәяләүне гамәлгә ашыручы төп учреждение буларак билгеләнә [Энциклопедия институты...].

1998 елга Инстиут фәнни-тикшеренү һәм нәшрият учреждениесе буларак формалашып бетә. Татарстан җитәкчелеге карары белән Институтка Пушкин урамындагы бина – сәүдәгәр Крестовниковларның реставрацияләнгән йорты бирелә.

1994–2010 елларда Институт белән филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Мансур Хәсән улы Хәсәнов җитәкчелек итә. Бер үк вакытта ул Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты вазифасын да башкара (1992–1996). М.Х. Хәсәнов – Татар энциклопедиясен булдыруга зур өлеш керткән шәхес. Мансур Хәсән улы татар җәмәгатьчелегенең Татар энциклопедиясе төзү турындагы фикерен күтәреп ала һәм аның тырышлыгы нәтиҗәсендә 1989 елның 6 сентябрендә ТАССР Министрлар Советының «Татар Совет Энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү турында» карары кабул ителә. Директор урынбасары булып озак еллар Г.С. Сабирҗанов эшли (1994–2011). Гомәр Салих улы Институтка үз эшләрен тирәнтен белгән талантлы кадрларны туплый. Нәтиҗәдә 107 хезмәткәрдән торган Институт коллективы оеша. Институтның структурасы үзгәрә, аның составында түбәндәге бүлекләр булдырыла:

– тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге (мөдире – тарих фәннәре докторы Р.В. Шәйдуллин),

– торак пунктлар тарихы бүлеге (мөдире – тарих фәннәре кандидаты А.И. Ногманов),

– икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге (мөдире – икътисад фәннәре докторы Ф.С. Зыятдинов),

– тел белеме һәм әдәбият бүлеге (мөдире – филология фәннәре кандидаты Р.Р. Мусабәкова),

– массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге (мөдире – тарих фәннәре кандидаты Л.М. Айнетдинова),

– фән, мәгариф һәм мәдәният бүлеге (мөдире – сәнгать фәннәре кандидаты Е.П. Ключевская)

– биология, география һәм геология бүлеге (мөдире – авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Ф.Г. Борһанов),

– табигыять һәм техник фәннәр бүлеге (мөдире – физика-математика фәннәре докторы Р.Г. Усманов),

– медицина, сәламәтлек саклау һәм спорт бүлеге (мөдире – биология фәннәре кандидаты В.Г. Матросова),

– фәнни-методик эш һәм контроль бүлеге (мөдире – сәясәт фәннәре докторы Р.М. Мөхәммәтшин),

– фәнни мәгълүмат хезмәте һәм библиография бүлеге (мөдире – Р.Ф. Шәрәпова),

– иллюстрацияләр һәм картография бүлеге (мөдире – Ә.Х. Хәлиуллина),

– фәнни нәшрият бүлеге (мөдире – техник фәннәр кандидаты Р.Р. Сәләхиев),

– энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге (мөдире – филология фәннәре кандидаты А.Г. Яруллина),

– редакторлар төркеме (мөдире – Г.М. Боровых).

Энциклопедиянең Баш гыйльми мөхәрририяте һәм 35 тармактан торган Фәнни мөхәрририяте оештырыла. Татар энциклопедиясен төзү эшенә танылган галимнәр, сәнгать белгечләре, архитекторлар, музыкантлар һ. б. җәлеп ителә: Мирфатыйх Зәкиев, Вахит Хаков, Хатыйп Миңнегулов, Миркасыйм Госманов, Индус Таһиров, Альфред Халиков, Яхъя Абдуллин, Кев Салихов, Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова, Рубин Абдуллин һ. б. Казан дәүләт университеты (хәзер Казан (Идел буе) федераль университеты), фәнни-тикшеренү институтлары һәм учреждениеләре, югары уку йортлары белән фәнни хезмәттәшлек урнаштырыла.

Институт алдында түбәндәге максатлар куела: Татарстан Республикасы һәм татар халкының социо-мәдәни һәм тарихи-фәнни мирасын өйрәнү буенча фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр үткәрү, энциклопедик һәм монографик характердагы фәнни-тикшеренү продукциясен эшләү һәм бастыру, мәгълүматны ачыклау, системалаштыру, саклау һәм аны мәдәният һәм мәгариф киңлегенә кертү.

1994–1997 елларда «Татар энциклопедиясе»нең рус һәм татар телләрендә беренче лөгатьлекләре дөнья күрә. Лөгатьлек материаллары «Татар энциклопедия сүзлеге»н һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе»н эшләү өчен нигез була. Рус телендә чыккан сүзлектә 17 меңгә якын мәкалә Татарстанның тарихын, дәүләт төзелешен, физик-географик һәм административ-территориаль бүленешен, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын, шәһәр һәм авыллары тарихын, республика халыкларының икътисади, фән-техника, мәгариф, сәнгать өлкәләрендә ирешкән казанышларын һ. б. яктырта. Мәкаләләрнең күп өлеше татар халкының күренекле шәхесләренә багышлана. Шулай ук Татарстан җирлегендә хезмәт иткән яисә, аннан читтә яшәсәләр дә, фәнни-иҗади, иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләре белән Татарстанга, татар халкы

тормышына, мәдәниятенә өлеш керткән башка милләт вәкилләре хакында да күп мәгълүмат тупланган. Сүзлектә Татарстан Республикасы авыллары һәм башка торак пунктлары турында мәгълүмат бирелә, аларның татарча исемнәре языла. 1999 елда Лондонда 30 мең данә тираж белән «Татар энциклопедия сүзлеге» («Татарский энциклопедический словарь») нәшер ителә. Шул ук елның 3 ноябрендә китапны тәкъдим итү була. Әлеге чарада Татарстан Республикасы президенты М.Ш. Шәймиев, Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары И.К. Хәйруллин, Казан мэры К.Ш. Исхаков, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты һәм Татар энциклопедиясенең баш мөхәррире М.Х. Хәсәнов катнаша. Минтимер Шәймиев чыгышында китапка уңай бәя бирә: *Татар энциклопедия сүзлегенең дөньяга чыгуы – күптән көтеп алынган вакыйга. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин традицияләрен дәвам итүче фәнни интеллигенциянең тормышка ашкан хыялы. Без Татарстанның гаять зур фәнни потенциалы турында сөйләү белән генә чикләнмәдек, ә эшебез белән нинди саллы хезмәт булдырырга сәләтле икәнебезне күрсәтә алдык* [Институт Татарской энциклопедии...]. Татар телендә сүзлек 2002 елда дөнья күрә. Аның табигыять, техника, гуманитар фәннәр, халык хуҗалыгы, мәдәният өлкәләренә караган өлешләре яңа мәгълүмат, өстәмәләр белән тулыландырыла. 2005 елда «Татар энциклопедия сүзлеге»н әзерләгән өчен Институтның бер төркем хезмәткәрләренә Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт бүләге бирелә.

«Татар энциклопедия сүзлеге»нә таянып, «Татар энциклопедиясе» күптомлыгы эшләнә. 2002 елда Татар энциклопедиясенең рус телендә беренче томы дөнья күрә. Соңгы алтынчы томы 2014 елда төгәлләнә. Татар телендә энциклопедиянең беренче томы – 2008 елда, соңгы алтынчы томы 2021 елда нәшер ителә. «Татар энциклопедиясе» күптомлыгы Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиевнең 1997 елның 10 февралендәге Указы һәм республика хөкүмәте раслаган программа нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты тарафыннан әзерләнә.

Татар энциклопедиясе – татар халкының һәм Татарстанның иң борынгы заманнардан безнең көннәргәчә тормышын дөрес һәм күпьяклы чагылдырган универсаль милли басма. Энциклопедиягә фәкать татар халкы һәм күпмилләтле Татарстан тарихы белән турыдан-туры бәйләнеше булган вакыйгалар һәм фактлар гына сайлап алына. Татар энциклопедиясенең беренче томы рус телендәге вариант нигезендә эшләнсә дә, эчтәлеге һәм күләме ягыннан аннан аерыла, бигрәк тә шәхесләргә, әдәбият, сәнгать, икътисад, сәнәгатькә, авыл хуҗалыгы, торак пунктларга, район, шәһәр муниципаль берәмлекләренә һ. б. караган мәкаләләр яңа мәгълүмат белән тулыландырыла.

Рус һәм татар телләрендәге «Татар энциклопедия сүзлеге»ннән һәм «Татар энциклопедиясе» күптомлыгыннан тыш, Институт тарафыннан төрле универсаль энциклопедик һәм фәнни-белешмә

басмалар чыгарыла, алар арасында «Татарстан: иллюстрацияле энциклопедия» («Татарстан: иллюстрированная энциклопедия», 2013), «Татарстан: кыскача иллюстрацияле энциклопедия» («Татарстан: краткая иллюстрированная энциклопедия», 2015), «Татарстан Республикасының юкка чыккан торак пунктлары: белешмәлек» («Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан: справочник», 2016), «Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләр» («Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации», 2016), «Казахстан татарлары: энциклопедик белешмәлек» («Татары Казахстана: энциклопедический справочник», 2016), «Татарстан Республикасының табигате һәм табигый байлыклары: иллюстрацияле энциклопедия» («Природа и природные ресурсы Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия», 2017), «Әдәби Чистай. Энциклопедия» («Чистополь литературный. Энциклопедия», 2017), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль символлары» («Государственные и муниципальные символы Республики Татарстан», 2017) «Татарстан Республикасының торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия», 1, 2 т. («Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия», т. 1, 2 , – 2018, 2021), «Татарстанга – 100 ел» иллюстрацияле энциклопедик очерклар» («Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические очерки», 2019), «Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз!» («Цвети, священная земля моя!», 2020), «Татарстанның сәяси эшлеклеләре: биографик язмалар» («Политические деятели Татарстана: биографические очерки», 2020), «Күренекле шәхесләр» мультимедиалы буклет-коммуникаторы («Выдающиеся личности» мультимедийный буклет-коммуникатор, 2022) [Күренекле шәһесләр...], Мәхмүт Гәрәев: хәрби, галим һәм җәмәгать эшлеклесе» (тууына 100 ел тулу уңаеннан): мәкаләләр җыентыгы» («Махмут Гареев: военный, ученый и общественный деятель» (к 100-летию со дня рождения: сборник статей, 2023) һ. б. күрсәтергә мөмкин. 2014 елда Татар энциклопедиясе институты «Татарстан: иллюстрацияле энциклопедия»се өчен «Иң яхшы энциклопедик басма» номинациясендә «Елның иң яхшы китаплары» конкурсы лауреаты була.

Хәзерге вакытта Институтта дүрт фәнни-тикшеренү һәм нәшрият үзәге, электрон-цифрлы ресурслар бүлеге эшли:

– энциклопедистика үзәге (мөдире – тарих фәннәре докторы Р.В. Шәйдуллин),

– регионнарны өйрәнү һәм социомәдәни тикшеренүләр үзәге (мөдире – тарих фәннәре кандидаты Л.М. Айнетдинова),

– татар диаспорасын өйрәнү үзәге (мөдире – тарих фәннәре кандидаты Б.Л. Хәмидуллин),

– Кама фәнни үзәге (мөдире – филология фәннәре докторы Н.М. Вәлиев).

Институт белән тарих фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Рамил Миргасим улы Вәлиев (2010–2015), тарих

фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев (2015–2024), сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эльмира Мөнир кызы Галимова (2024 елдан) җитәкчелек итә.

Бүгенге көндә Институтта «Ватан тарихы» юнәлеше буенча аспирантура эшли. Институт даими рәвештә үз фәнни җыентыкларын нәшер итә. Институт коллективы «Үзбәкстан татарлары энциклопедиясе», «Каюм Насыйри энциклопедиясе», «Татарстан галимнәре – фән докторлары» фәнни белешмәлеге һ. б. фәнни хезмәтләр әзерли. Институт тарафыннан татар дөньясында тирән эз калдырган һәм төрле өлкәләрдә дан казанган шәхесләр турында видеороликлар циклы әзерләнде. Әлеге проектның максаты – халкыбызның танылган уллары һәм кызларының тормыш юлын, иҗатын, казанышларын төрле яклап яктырту һәм халыкка җиткерү.

И.А. Гыйләҗев инициативасы белән Институтта Tatarica онлайн энциклопедиясе проекты эшләнә башланды. Tatarica онлайн энциклопедиясе – мультимедиалы универсаль интернет-ресурс. Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан тормышка ашырыла. Институт Татарстан һәм татарлар турында иң тулы фәнни мәгълүматны интернет челтәренә урнаштыру өстендә эшли. Проектның максаты – Татарстан Республикасы һәм татар халкы турында ышанып кулланырлык актуаль, бай мәгълүмат тупланмасы булдыру. Электрон энциклопедия «Татар энциклопедиясе» күптомлыгы мәкаләләренә нигезләнеп эшләнә. Мәкаләләр татар һәм рус телләрендә урнаштырыла. Китап версиясеннән аермалы буларак, онлайн энциклопедиядә мәкаләләргә күләм һәм сан ягыннан чикләр куелмый. Материаллар эзлекле рәвештә тулыландырыла һәм актуальләштерелә. Бу эш проект командасы тарафыннан башкарыла, кулланучыларның, википедиядәге кебек, турыдан-туры үзгәрешләр кертү мөмкинлеге юк. Мәкаләләр документлар, фото-, видео-, аудиоматериаллар, диаграммалар, таблицалар, схемалар, архив чыганаклары һәм башка медиаресурслар белән бергә бирелә [Фазлиахметова, 2018, с. 64]. Татар онлайн энциклопедиясе кулланучылар өчен беренчел чыганаклар белән эшләү, аларны анализлау, мөстәкыйль куллану мөмкинлеге тудыра. Шулай итеп, Татарстан һәм татар халкы турындагы ышанычлы мәгълүмат дөньяның төрле почмакларында яшәүче киң җәмәгатьчелеккә ике телдә ирештерелә.

Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты татар телен саклап калуга, тарихи үткәнебезне дөрес аңлатуга зур өлеш кертә. Институтның үз өлкәләрендә зур уңышларга ирешкән, тирән белемле фәнни хезмәткәрләре аерым игътибарга лаек.

Институтның милли энциклопедистика өлкәсендәге эшчәнлеге Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Нургали улы Миңнеханов тарафыннан даими яклау һәм игътибар таба.

Быел, 2024 елда, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты берничә юбилей датасы – татар һәм рус телләрендә Татар энциклопедиясен булдыру буенча беренче дәүләт программасы кабул ителүнең 35 еллыгын, Институт оешуның 30 еллыгын, рус телендә «Татар энциклопедия сүзлеге» чыгуның 25 еллыгын, һәм рус телендә 6 томлы «Татар энциклопедиясе»нең алтынчы томы чыгуның 10 еллыгын билгеләп уза.

### Әдәбият

Институт Татарской энциклопедии. URL: http://www.ite.antat.ru/scince/prezent.shtml (мөрәҗәгать итү көне: 31.10.2024).

Күренекле шәхесләр. URL: https://tatarica.org/application/files/8016/6082/1483/Shehkheslehrebez.pdf (мөрәҗәгать итү көне: 011.11.2024).

*Фазлиахметова Г.И.* Онлайн-энциклопедия как просветительский проект: особенности реализации // История России и Татарстана: итоги и перспективы энциклопедических исследований. Матер. ежегодной региональной науч.-практ. конф. (г. Казань, 8 июня 2018 г.). Казань, 2018. С. 63–68.

Энциклопедия институты. URL: https://tatarica.org/tat/razdely/tp-mkal/enciklopedik-instituty (мөрәҗәгать итү көне: 31.10.2024).

***Зәкиева Резеда Госман кызы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 930.2

***И.Х. Хәлиуллин***

# ТАРИХИ ХӘТЕР: АСЫЛЫ, ФОРМАЛАРЫ, СТРУКТУРАСЫ, ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ, ЯЗМЫШЫ

Статья посвящена освещению сущности, значения и судьбы исторической памяти народа, рассмотрению ее структуры и форм, ее отражения в произведениях татарского устного народного творчества.

**Ключевые слова:** историческая память, формы исторической памяти, виды повествования исторического прошлого, эпос, хроника, татарские дастаны, баиты и предания, этническая идентичность, патриотизм, уроки истории, пути укрепления и возрождения исторической памяти.

The article is devoted to highlighting the essence, meaning and fate of the historical memory of the people, considering its structure, forms, and its reflection in the works of Tatar oral folk art.

**Keywords:** historical memory, forms of historical memory, types of narration of the historical past, epic, chronicle, Tatar dastans, Baits and legends, ethnic identity, patriotism, history lessons, ways to strengthen and revive historical memory.

Шәхеснең карашлары, тормышта тоткан юлы мөһим дәрәҗәдә аның үткәннәр – ерак тарих һәм яңарак булып узган вакыйгалар белән бәйләнеше, элемтәсе, аларга мөнәсәбәте тарафыннан билгеләнә. Тарихи хәтер кешенең үз халкы, иле тарихына катнашы булуын тоемлавына, үткәннәргә карата кичерешләренә нигезләнә, шуңа күрә аны өйрәнүнең төп проблемасы тикшеренү объектының үзенә бертөрле аерым сыйфатлы статусыннан гыйбарәт. Шул сәбәпле, күтәрелгән мәсьәлә буенча татар телендә махсус әдәбиятның булмавы да искә алынып, мәкаләнең максаты тарихи-чагыштыру, тарихи-системалы, гомумиләштерүле алымнарны кулланып, тарихилык һәм объективлык принциплары нигезендә халык тарихи хәтеренең асылын, формаларын, структурасын, аның татар халык авыз иҗаты әсәрләре булган дастаннарда, риваятьләрдә һәм бәетләрдә чагылышын яктыртуны күздә тота.

Л.Н. Мазур фикеренчә, тарихи хәтер формалашуның чыганакларына һәм механизмнарына дин, базар һәм информацион технологияләр кебек факторлар турыдан-туры тәэсир итәләр, алар җәмгыятьнең мәгълүмат даирәсе һәм мәдәнияте үзенчәлекләрен билгеләп кенә калмыйча, тарихи хәтернең тулысынча манзарасы белән идарә итүдә җаваплы роль башкаралар [Мазур, 2013, с. 247]. Тарихи хәтер каршылыклар тудырыру һәм, киресенчә, туплау сәләтенә дә ия [Моисеенко, 2022, с. 44].

Тарихи хәтер күмәк асыллы эчтәлекле. Бу очракта күмәклек асылы аның хуҗасының аерым индивид булудан бигрәк, социаль

төркемнәр, халык иканлегеннән гыйбарәт. Аның социаль үзлеген заманында француз социология мәктәбенең күренекле вәкиле, философ М. Хальбвакс (1877–1945) билгеләп узып, үткәннәрдәге фактларны тулысынча һәм гел чынбарлыктагыча тапшыра алмавын искәрткән иде [Хальбвакс, 2007, с. 140]. Тарихи хәтер билгеле бер дәрәҗәдә халыкның килеп чыгышын, илнең оешуын, аларның үсешен чагылдыра. Әлеге җәһәттән үткән чор – хәзерге заман – киләчәк мәгънәсендә җәмгыять тарихы һәм, аның чыгарылмасы буларак, тарихи хәтер шартлы рәвештә елганы хәтерләтә. Елганың чишмә башы, дәвамы (кушылдыклар тоташкан өлеше) һәм тамагы булган кебек, славян кабиләләреннән башлангыч алган Россия тарихи юл уза: Киев Русе – феодаль таркаулык – Мәскәү бөек кенәзлеге – көч кулланып яки ирекле рәвештә кушылган халыклар һәм территорияләр («кушылдыклар») хисабына киңәйгән-үскән Рус дәүләте – Россия империясе – СССР – Россия Федерациясе. Шушы процессны күздән кичергән тәкъдирдә, россиялеләрнең (Россия халыкларының) тарихи хәтерендә, шул исәптән кушуларның төрле рәвештә һәм төрле ысуллар кулланып гамәлгә ашырылуы сәбәпле, әлеге юлның бертөрле генә чагылмавы табигый. Кайвакыт елгаларның үз юлларын үзгәртүләре мәгълүм, әүвәлге чишмә башлары саега яки корый. Тарихи хәтер дә охшаш үзгәрешләргә дучар була. Мисал өчен, Европада колбиләүчелек строеның тәмамлануы һәм феодализмның башлангычы («елганың чишмә башы»), Көнбатыш Рим империясенең варварлар тарафыннан яулануы нәтиҗәсендә җимерелүе (безнең эраның 476 елы) фактының рәсми танылуы шул чор замандашлары хәтерендә тәфсилле хәлдә һәм ачык итеп «кичәге вакыйга» сыйфатында теркәлә, әмма нибары берничә гасыр узганнан соң әлеге хатирәләр Бөек Карл (742–814) яулап алулары тәэсирендә тоныклана. Вакытлар узу белән соңгылары да, үз чиратларында, риваятьләргә күчә. Л.П. Репина тарихи хәтерне күмәк хәтер, фәннилеккә әлгәр, фәнни, ялган фәнни һәм фәннилектән тыш белемнәрнең, кешеләрнең үткәннәрне массачыл күзаллауларының җыелмасы буларак аныклап, тарихи үткәннәрне бәян итүне икегә – эпос (тарихи хәтерне тапшыруның тавышлы ысулы) һәм хроника (баштан ук язмача теркәү ысулы) төрләренә бүлә [Репина, 2003, с. 12, 14]. Ике очракта да хәбәрче (мәгълүмат бирүче) күрсәтелми. Эпостан аермалы буларак, вакыйга язма рәвештә теркәлгән хроникада даталарга өстенлек бирелә (Көнбатыш Европа хроникалары, рус елъязмалары, Рәшидетдиннең «Елъязмалар җыентыгы» һ. б.).

Тарихи аң кебек үк, тарихи хәтер дә башлыча ике – фәннитеоретик һәм массачыл формаларда булып, беренчесенең нигезендә үткәннәр һәм хәзерге тормыш арасындагы аерымлыкларны тану, тарихны күзаллау өчен мәгълүматның чынлыгы-дөреслеген таләп итү ятса, икенчесе өчен үткәннәрне тәэсири кабул итү, алар белән кызыксынуның социаль тормыштагы хәзерге күренешләр белән бәйләнеше, үткәннәр образын тергезү өчен күзаллауларны иркен, тоткарлыксыз куллану хас [Репина, 2006, с. 19]. Күләм буенча җәмгыять-

тә тарихи хәтернең массачыл формасы күпкә өстенлек итә, бу аның күмәклек асылы белән дә аңлатыла. Системалы рәвештә тарихи белемнәрне камилләштерү белән бергә, аның формалашуына әдәбият, сәнгать (бигрәк тә күргәзмәлек хасияте көчле тәэсирле булган кино сәнгате), массачыл мәгълүмат чаралары, хәзерге вакытта социаль челтәрләр дә йогынты ясый [Ковеленко, 2017, с. 36].

Фәндә кабул ителгәнчә, тарихи хәтер структурасына белемнәр, шул исәптән югарыда телгә алынган тарихи белемнәр белән бергә, халыкның теле, традицияләре, йолалары, гореф-гадәтләре, ритуаллары, кыйммәтләре, символлары, авыз иҗаты, шулай ук социаль-тарихи образлары (үткәннәрнең образлары) керә [Касьянов, 2024, с. 51; Мысливец, 2018, с. 160; Румянцева, 2019, с. 42].

Тарихи хәтернең элементы, фольклорның зур төркеме булган, үз чиратында эпос (үткәннәрне бәян итүдә тарихи хәтерне тапшыруның тавышлы ысулы, язма-китап рәвеше дә бар) һәм лирикага төрләнгән халык авыз иҗатында ерак һәм якын үткәннәрдәге вакыйгаларның урын алуы табигый.

Дастаннар – төрки телле халыклар фольклорында эпик жанр. Татар дастаннары, белгечләр фикеренчә, борынгы һәм Урта гасырлар Шәрык әдәбияты тәэсирендә барлыкка киләләр; жанр архаик-героик («Алтаин Саин Сөмә»), тарихи («Ак Күбек», «Идегәй» һ. б.), мәхәббәт-лирик («Кузы Күрпәч белән Баянсылу» һ. б.) төрләргә аерыла. «Ак Күбек» һәм «Идегәй» дастаннарында вакыйга Алтын Урдада, эчке чуалышлар һәм таркалу чорында бара, геройлары – тарихи шәхесләр (ханнар, әмирләр, гаскәр башлыклары), ике әсәрдә дә барлык төп геройлар һәлак була [Татар энциклопедиясе, 2010, б. 222; Татар энциклопедиясе, 2019, б. 346]. XVII–XVIII гасырларда формалашуы төгәлләнгән «Идегәй»нең алтай, башкорт, казакъ, каракалпак, кырымтатар, нугай, төрекмән, үзбәк милли версияләре дә мәгълүм, аның иң элек барлыкка килгән сюжетларының татар телендә языла башлавы, белгечләр фикеренчә, XVII гасыр башына карый [Мухаметзянова, 2018, с. 537]. Совет дәверендә дәүләт башында коммунистлар партиясе торган рәсми хакимиятнең аңа карата үтә тискәре мөнәсәбәте әсәр милли мирас хәзинәсен тәшкил иткән халыкларның тарихи хәтеренә зыян салса да, соңгы дистәләрчә еллар дәвамындагы милли яңарыш хәрәкәте әлеге хилафлыктан арынуга этәргеч бирде.

Риваятьләр – тарихи хәтер чагылышының бер рәвеше, фольклорның шулай ук эпик жанры әсәрләре. Белгечләр фикеренчә, аларның тамырлары тарихи вакыйгаларга бәйле борынгы заманнарга барып тоташа [Татар халык иҗаты, 1987, б. 10]. Вакытлар узу белән, риваятьләр зур үзгәрешләр кичерәләр, кайберләре, онытылып, юкка чыга. Күп кенә тикшеренүчеләр аларның халык хәтерендә саклану дәверен 200–500 еллар белән чикли [Толстова, 1983, с. 14]. Кайбер искәрмәләр бу караш белән килешмәүгә җирлек тудыра. Дәлил сыйфатында күп кенә галимнәр (С.М. Шпилевский, Н.П. Загоскин, Х.Г. Гыймади, А.Н. Киреев, Ф.И. Урманчеев, А.Х. Халиков һ. б.) фикеренчә, болгарларның

1236 елгы монгол яуларына каршылык күрсәтүе белән бәйле [Халиуллин, 2022, с. 244]. «Барадж нәселе», «Бүләрнең яндырылуы», «Янмас хан кызы», «Кырык кыз», «Изге бабалар», «Унике кыз һәм Мәрҗән каласы», «Хан кызы Алтынчәч» риваятьләренең [Татар халык иҗаты, 1987, б. 31–33, 35–40], Л.Х. Мөхәммәтҗанова хаклы рәвештә искәрткәнчә, хәтта бүгенге көндә дә язып алынуына игътибар итик [Мухаметзянова, 2021].

Атаклы татар галиме, мәгърифәтче һәм дин эшлеклесе Ш. Мәрҗани (1818–1889) үткәннәрне өйрәнүдә риваятьләрнең зур әһәмияткә ия булуын ассызыкласа да, аларны беркайчан да бәхәссез тарихи чыганаклар исәбенә кертмәде [Мәрҗани, 1989, б. 45], чөнки аларда чынбарлык төрлечә һәм эзлексез чагыла. Риваятьләрнең күбесе өчен вакыйгаларны бәянлауда чорларның эзлексезлеге һәм тарихи вакытка туры килмәве (анахронизм) һәм фольклорча буталчыклар (контаминация) хас, әмма тарихи хәтернең сакланышында, шулай ук фәнни кызыксынуны яңа фасылда көчәйтеп яңа тикшеренүләргә китерүендә аларның әһәмияте зур.

Бәетләр – эпик һәм лирик-эпик жанрлардагы әсәрләр; тарихи («Кызыл сугышчы бәете», «Бөек Ватан сугышы бәете»), хәрби-тарихи («Рус-француз сугышы бәете»), гади халыкның авыр хәлен («Лашманнар бәете»), хатын-кыз язмышын, дини ирек даулауны («Урта Тигәнәле бәете»), җир һәм ирек өчен көрәшне («Чынлы бәете») һ. б. тасвирлаган темаларны колачлаган төрләргә бүленәләр [Татар халык иҗаты, 1983, б. 9; Бәетләр, 2000, б. 6]. Әлеге бүленештән чыгып фикер йөрткәндә, «Сөембикә бәете»н берьюлы тарихи һәм хатын-кыз язмышын тасвирлаган бәет дип бәяләргә мөмкин. Анда бәян ханбикә исеменнән бара, реаль тарихи вакыйгалар һәм шәхесләр катнаша. Тарихи бәетләр буларак танылган «Казан бәете»ндә һәм «Шәһри болгар бәетләре»ндә дә үткәннәрне тасвирлауда беркадәр җентеклелек күзәтелә. Бәетләргә хас булган эмоциональлек ышандыру сыйфатын көчәйтә һәм шул рәвешле тарихи хәтер сакланышы тәэмин ителә.

Тарихи хәтернең сыйфаты билгеле бер дәрәҗәдә халыкның тарихи сынауларны җиңү, тарихи мирасны, тарихи хәтернең компонентлары булган милли телне һәм традицияләрне, шулай ук мәдәни казанышларны саклау сәләтендә чагылыш таба. Аның тирәнлек дәрәҗәсе төрле халыкларда төрлечә. Мәсәлән, XVI–XVII гасырлар чигендә Польша-Литва татарлары этник телләрен югалталар, әмма үз диннәрен (ислам) саклап калалар. Хәер, аерым алганда, алар яшәгән территориядә хәзергәчә 1410 елның 15 июлендә булып узган Грюнвальд сугышы хакында хәтерлиләр. Ул чакта аларның бабалары Туктамыш хан улы Җәләлетдин (1380–1412) җитәкчелегендә әлеге орышта катнашып, Тевтон ордены рыцарьларын җиңүгә хәлиткеч өлеш кертәләр. Шушы вакыйганың 600 еллыгы истәлегенә 2010 елның 25 ноябрендә Гданьск шәһәрендә татар атлы яугиренә һәйкәл ачыла; тантанада Россия Федерациясе, Беларусь, Украинаның генераль консуллары, Польша хөкүмәте әгъзалары катнаша, илнең президенты Б. Коморовский нотык тота.

Тарихи хәтер гомумән, һәм, аерым алганда, аның структура составындагы тел һәм традицияләр кебек үк, халыкның рухи яңарышында һәм этник бердәйлегендә фундаменталь әһәмияткә ия. Аның әлеге хасияте, атап әйткәндә, аталар һәм бабалар, буыннар бәйләнеше мисалында, ватанпәрвәрлек тәрбияләүдә дә үзәк урын били. Ул тарих сабакларына бай булуы белән дә кыйммәтле. Дөрес, ул сабаклар белән исәпләшү дәрәҗәбез – аерым мәсьәлә. Бу җәһәттә фикеребезне дәлилләп, шуңа игътибар итик, 1993 елда Европа Берлеге оешу – күмәк Гаребнең тәүге берләшүе түгел иде. Аның агрессив тышкы сәясәте белән дә беренче тапкыр очрашуыбыз түгел иде. Тәре яуларын (1095–1099, 1147–1150, 1189–1192, 1202–1204 (Византиягә каршы), 1217–1221, 1228–1229, 1248–1254, 1270 еллар), «Изге Рим империясе» (962–1806, 1512 елдан – «Герман милләтенең Изге Рим империясе» – герман-француз-көнбатыш славян телле дәүләтләр берләшмәсе) тарихын, 1812 елда Россиягә Наполеон Бонапартның «унике телле армиясе» яу белән килүен, Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларын, нацизмның торгызылуын искә төшерик. Шулай, тарих кабатлана. Шундый кабатланулар нәтиҗәсендә тарихи хәтердәге сабаклар белән санлашмау, онытылу упкыннары ачыла.

Билгеле дәрәҗәдә аерым бер халыкның килеп чыгышын, тарихын, аның менталь үзенчәлекләрен чагылдыруы сәбәпле, тарихи хәтер милли төсмергә ия, бигрәк тә элгәрге этапларда бер халыкның тарихи хәтере икенчесенекеннән күпкә үзгә була. Тарихи хәтер объектив рәвештә тарихи үсеш-үзгәреш кануннарына буйсына; әлеге үсешнең төрле чорларында турыдан-туры эчке һәм тышкы процессларның йогынтысы нәтиҗәсендә үзе үк үзгәрешләр кичерә. Үзгәрешләр уңай юнәлештә генә бармыйча, аларның тискәреләре тарихи хәтернең бозылуына, кайбер вакыйгаларның хәтердән югалуына китерүе ихтимал. Моның сәбәпләре төрле, алар объектив (мәсәлән, мәгълүматка ия булучыларның сугышларда яки табигый афәтләрдә күпләп зур казалар кичерүе яки хәтта һәлакәте) һәм субъектив (максатчыл рәвештә ирексезләп милли яки менталь кыйммәтләрдән читләштерү, үткәннәрне тамырдан бозып сурәтләү һ. б.) факторларга бәйле.

Эчке, субъектив факторларның берсе сыйфатында үткәннәргә һәм тарих фәненә карата мөнәсәбәтнең рәсми хакимият тарафыннан үзе уздырган сәясәт кысаларында чамадан тыш идеологияләштерелүен тану фарыз. Аерым алганда, бу очракта ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карарын, ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты бюросының шул ук елның 6 октябрендә чыгарылган карары нигезендә «Идегәй» дастанының «зыянлы», «ханнар-феодаллар» эпосы дип табылуын һәм ВКП(б) өлкә комитетының 1945 елның 24–27 февралендә узган пленумында өлкә комитеты секретаре С.И. Маловның идеология мәсьәләсенә багышланган докладында галимнәрнең рус һәм татар халкының чит ил илбасарларына каршы

бердәм керәшен өйрәнәсе урында XII–XVI гасырлар әдәбиятына караган чыганакларны тикшерүдә гаепләнүен, тенденциоз рәвештә Алтын Урданың агрессив дәүләт булуы, рус җирләренә юлбасарларча һөҗүмнәр ясавы, «Идегәй» дастанының милләтчелек идеяләре чагылышы сыйфатында күрсәтелүен (әлеге җәһәттә өлкә комитетының беренче секретаре З.И. Моратовның иң элек тарихчы Х.Г. Гыймадины һәм әдип Н.С. Исәнбәтне гаепләвен) искә алу да җитә. Нәтиҗәдә, халык авыз иҗаты тарихи хәтернең бер элементы булуы сәбәпле, татар халкының үз мирасына мөнәсәбәтенә, гомуми караганда исә, милли-менталь хасиятенә күрә, аның тарихи хәтеренә карата бу чараларның гына да нинди авыр нәтиҗәләргә китерүе аңлашыла.

Тышкы процесслар исә күбесенчә дәүләтнең халыкара мәйдандагы хәле белән бәйле.

Соңгы елларда халык хәтерен ясалма рәвештә имгәтү гамәлләре дә активлашты. Мисаллар эзләп ерак барасы да юк – Икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәләрен, шул ук Украина яисә Балтыйк буе дәүләтләре үткәннәрен бозып күрсәтү, фашизмны җиңүдә күпмилләтле совет халкының ролен сызып ташлау омтылышлары... Соңгысына карата үз фикерен белдереп, А.К. Быков Гареб илләрендә сугышлар тарихын бозып тасвирлауның максатка әверелгән төп ике сәбәбен – һәр илдә фаш итүче фактлардан арынып, «чиста», «саф» мисалларда гына фәкать милли кысаларга юнәлеш тоткан ватанпәрвәр буын тәрбияләүгә һәм агымдагы эчке һәм тышкы сәяси проблемаларны ил халкын тышкы дошман образына каршы котыртып хәл итәргә омтылуларны аерып күрсәтә [Быков, 2024, с. 51].

Тарихи хәтерне савыктыру һәм ныгыту – хәзерге чорыбыз һәм киләчәгебез таләбе, чөнки язмыш сынавына яшәешебез, илебезнең азатлыгы һәм иминлеге мәсьәләләре куелган. Әлеге проблеманы комплекслы хәл итү – тарихи хәтерне ныгыту юллары күп планлы һәм эзлекле фәнни-тикшеренү, төбәкне өйрәнү, тәрбия, мәгариф, мәдәни-массачыл, танып-белү эчтәлекле системаны үз эченә ала. Биредә тарихи белемнәрне тарату-популярлаштыру да мөһим роль уйный, нигә дигәндә, төрле сәбәпләр (вакыйганы бәян итү-тасвирлауның үзенчәлеге, тиражның чиклелеге, тикшеренү темасы кысаларының тарлыгы һ. б.) аркасында киң катлау укучының фәнни әдәбият белән танышу мөмкинлеге кими. Татарстан Республикасында бу мәсьәләне хәл итү максатында махсус басмалар – «Гасырлар авазы – Эхо веков» (1995 елдан), «Поволжская археология» (Мари дәүләт университеты белән берлектә, 2012 елдан), «Золотоордынское обозрение» (2013 елдан), «Безнең мирас» (2014 елдан; 1991–2010 елларда – «Мирас», 2012–2014 елларда – «Чын мирас»), «Фәнни Татарстан» (2014 елдан) һ. б. журналлар чыгарыла.

**Әдәбият**

Бәетләр. Казан: Иман, 2000. 192 б.

*Быков А.К.* Социально-педагогическая характеристика фальсификаций истории Великой Отечественной войны 1941–1945 годов и процесса противо-

действия им при формировании исторического и патриотического сознания молодежи // Историческая память: истоки и современные смыслы / под общ. ред. Б.П. Черника. Новосибирск: Агентство Сибпринт, 2024. С. 51–68.

*Касьянов В.В.* Историческая память: учебное пособие для вузов / В.В. Касьянов, В.Н. Нечипуренко. М.: Юрайт, 2024. 217 с.

*Ковеленко В.В.* Историческая память: сущность, роль в обществе // Парадигмы истории и общественного развития. 2017. Вып. 5. С. 35–37.

*Мазур Л.Н.* Образ прошлого: формирование исторической памяти // Изв. Урал. фед. ун-та. Сер. 2. Гуманитарные науки. 2013. № 3. С. 243–256.

*Мәрҗани Ш.Б.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар / төз. Ә. Хәйруллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

*Моисеенко О.А.* Роль исторической памяти в формировании гражданской идентичности современной России // Вестник Московского ун-та. Сер. 21. Управление (государство и общество). 2022. № 4. С. 31–46.

*Мухаметзянова Л.Х.* Рец. на серию в 3 кн.: Фольклор татар Башкортостана /сост., предисл.коммент. И.К. Фазлутдинова. Казань: ИЯЛИ, 2021. Вестн. СВФУ им. М.К. Аммосова. Серия: Эпосоведение. 2021. № 2(22). С. 98–102.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос «Идегей»: эхо сквозь столетия // Золотоордынское обозрение. 2018. Т. 6. № 3. С. 537–550.

*Мысливец Н.Л.* Образы прошлого в исторической памяти: теоретико-методологический аспект // Социально-гуманитарные знания. 2018. № 1. С. 157–164.

*Репина Л.П.* Культурная память и проблемы историописания (историографические заметки). М.: ГУ ВШЭ, 2003. 44 с.

*Репина Л.П.* История исторического знания: учеб. пособие для студентов вузов, обучающихся по специальности 020700 История / Л.П. Репина, В.В. Зверева, М.Ю. Парамонова. 2-е изд. М.: Дрофа, 2006. 288 с.

*Румянцева М.В.* Историческое знание и историческая память в структуре исторической культуры // Диалог со временем. 2019. Вып. 67. С. 41–54.

Татар халык иҗаты: Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.

Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

Татар энциклопедиясе: 6 томда / баш мөхәррир М.Х. Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2010. 2 т.: Г–Й. 656 б.

Татар энциклопедиясе: 6 томда / баш мөхәррир М.Х. Сәлахов, җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2019. 6 т. 1 кис.: Тә–Ч. 612 б.

*Толстова Л.С.* Использование при изучении этногенеза и этнокультурных связей народов // Фольклор и историческая этнография. М.: Наука, 1983. С. 6–22.

*Халиуллин И.Х.* Отголоски монгольского завоевания Волжско-Камской булгарии в 1236 г. в произведениях татарского фольклора // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: Сб. ст. итоговой научной конференции научных сотрудников Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ (г. Казань, 19 мая 2022 г.) / Институт Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ. Казань, 2022. Вып. 14. С. 243–247.

*Хальбвакс М.* Социальные рамки памяти / пер. с фр. и вст. ст. С.Н. Зенкина. М.: Новое изд-во, 2007. 346 с.

***Хәлиуллин Илшат Хәкимулла улы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 372.881,882

*Л.М. Гыйниятуллина,*
*Г.Н. Мөхәрләмова*

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛНЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУ БАРЫШЫН ЦИФРЛАШТЫРУ

В статье рассматриваются вопросы цифровизации процесса обучения родному (татарскому) языку и литературе в образовательных организациях начального, основного общего образования. Цифровой формат обучения дает неограниченные возможности для доступа к необходимой учебной информации. Разного рода учебные медиаматериалы активизируют познавательную и самостоятельную деятельность обучающихся, вызывают у обучающихся интерес к освоению учебного предмета. Эффективность обучения родному (татарскому) языку и литературе обеспечивает использование в образовательном процессе электронных учебников, просмотр обучающих видеоуроков, а также работа на электронных образовательных платформах.

**Ключевые слова:** цифровизация, дистанционное обучение, онлайн-формат, федеральные государственные образовательные стандарты, видеоуроки, электронная образовательная платформа.

The article discusses the issues of digitalization of the process of teaching native (Tatar) language and literature in educational institutions of primary, basic and secondary general education. The digital learning format provides unlimited opportunities to access the necessary educational information. Various kinds of educational media materials activate the cognitive and independent activity of students, arouse students' interest in mastering the subject. The effectiveness of teaching native (Tatar) language and literature provides the use of electronic textbooks in the educational process, watching educational video tutorials as well as working on electronic educational platforms.

**Keywords:** digitalization, distance learning, online format, federal state educational standards, video tutorials, electronic educational platform.

Бүген туган (татар) тел һәм әдәбияты предметларын укытуда нинди яңалыклар күзәтелә, мәктәптә аларны заманча шартларда ни рәвешле, нинди юллар, ысул-алымнар белән, нинди технологияләр кулланып укытырга, ниһаять, яңа дәреслекләр һәм электрон белем бирү ресурслары нинди булырга тиеш – болар методистлар һәм тел-әдәбият укытучыларын борчыган төп мәсьәләләрдән санала.

Билгеле булганча, уку-укыту дәреслек нигезендә һәм уку кабинеты киңлегендә традицион рәвештә үткәрелә. Киләчәктә ул интернеттагы эчтәлеккә, контентка, кешеләрнең белемнәре һәм алар нигезендә аралашу аша тәкъдим ителгән социаль капиталга керү нигезендә төзеләчәк [Jahnke, 2017]. Шул рәвешле, хәзерге шартларда дәресләрдә традицион булып саналган чаралар белән беррәттән заманча цифрлы укыту юлларын куллану да актуаль булып тора.

Укытуны цифрлаштыру – заманча технологияләр кулланып, укыту методларының цифрлы форматка күчү процессы ул [Словарь терминов..., 2021, с. 10]. Әлеге процесс «хезмәт базарындагы, белем бирү стандартларындагы үзгәрешләргә, халыкның яңа компетенцияләрен формалаштыруга ихтыяҗын ачыклауга китерә һәм белем бирү процессын үзгәртеп оештыруга, педагог ролен яңача аңлауга юнәлдерелгән» [Никулина, Стариченко, 2018, с. 109]. Цифрлаштыру, материалны мөстәкыйль өйрәнүне һәм үзләштерүне күздә тотып, белемне читтән торып алуны тәэмин итә [Aydarova, 2017, p. 6]. Әлеге проблема мәктәптә уку предметларын үзләштерүдә, аеруча балаларның гамәли күнекмәләрен формалаштыруны күздә тоткан яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында тагын да актуальләшә [Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования; Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования].

Туган телне һәм әдәбиятны укыту мәсьәләсе Татарстан Республикасының белем бирү системасында һәрвакыт актуаль булып кала. Һәм, барыннан да элек, ул әлеге предмет өлкәсе буенча укыту-методик комплектлар булдыруда чагылыш таба. Бүген гомуми белем бирү оешмаларының 1–11 сыйныфлары өчен, яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры китереп һәм федераль белем бирү программалары нигезендә, «Туган тел (татар теле)», «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку», «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметларыннан укыту-методик комплектлар (УМК) эшләнде. Алар белемнәрне цифрлы формат ярдәмендә дә тапшыруны күздә тота.

Туган телне һәм әдәбиятны укыту укучыларның уку-танып белү эшчәнлеген оештыруның барлык этапларында аудиовизуаль һәм электрон укыту чараларын куллануны күздә тота. Шулай итеп, барлык эшләнгән дәреслекләрнең дә электрон аналоглары бар, алар туган тел һәм әдәбиятны укыту процессын җиңеләйтү һәм төрлеләндерү максатына хезмәт итә. Электрон дәреслектә билгеле бер темага текстларның аудиоязмаларын тыңларга мөмкин. Биредә шулай ук төрле уеннар һәм интерактив биремнәр тәкъдим ителә. Алар барысы да укучыларның кызыксынуларын һәм яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнгән. Электрон дәреслекләрдә төрле табышмаклар, әдәби әсәрләрдән өзекләр, ребуслар, логик биремнәр, башваткычлар җитәрлек күләмдә урнаштырылган.

Электрон дәреслекнең тагын бер өстенлеге булып интерактив уеннар санала. Аларны парларда, төркемнәрдә, тулы бер сыйныф белән уйнарга мөмкин. Алар туган тел һәм әдәбият буенча теоретик материал белән танышуны гына түгел, танып белү мәгълүматын үзләштерүне дә күздә тота.

Әйтергә кирәк, мәктәптә укытыла торган предметларның барысыннан да диярлек мондый материаллар чагыштырмача күп һәм укытучылар дәресләрдә алардан бик теләп файдаланалар. Моны алдагы елларда пандемия шартларында дистанцион укыту барышында

ачык күреп булды. Укучылар тәкъдим ителгән төрле видео, медиаматериаллар, электрон белем бирү ресурсларыннан иркен файдаланып белем алдылар. Әлеге предметлар буенча электрон белем бирү платформаларында эшләү мөмкинлеге дә булдырылды. Туган тел һәм әдәбияттан исә мондый мөмкинлекләр чикле. Гамәлдәге дәреслекләрнең электрон вариантлары бу ситуацияне беркадәр хәл итәргә ярдәм итте, әлбәттә. Шулай да укучыларга белем алу процессында куллану өчен болар гына җитмәве үзен нык сиздерде. Бу проблеманы хәл итүдә берничә юл ачыкланды. Шуларның берсе – гамәли дәресләрне алыштыра, яки шул дәресләрнең аерым бер фрагменты буларак кулланыла алырлык видеодәресләр булдыру.

Шуңа бәйле рәвештә бүген республикада гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен туган тел буларак татар теле һәм әдәбиятыннан видеодәресләр комплектын булдыру юнәлешендә проект гамәлгә ашырыла. Видеодәресләр күләме ягыннан зур булмаган видеороликлардан гыйбарәт. Аларның эчтәлеге яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә һәм алар федераль белем бирү программалары нигезендә эшләнгән. Алар дәреслектәге темаларны нигез итеп ала һәм бердәм кызыклы сюжет линиясенә корылган.

Югарыда әйтелгәнчә, мәгариф өлкәсендә цифрлаштыру бурычларының берсе – онлайн-укытуны үстерү. Мондый укыту укучыларда мөстәкыйль эшчәнлек белән бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга ярдәм итә [Мөхәрләмова, б. 209].

Күп еллар дәвамында укучыларның туган (татар) телне һәм әдәбиятны өйрәнгән вакытта билгеле бер белем бирү платформасында эшләү мөмкинлеге булмады. Шуны истә тотып, республикада тагын бер проект – СберКласс электрон белем бирү платформасында гомуми белем бирү оешмаларының 5–9 сыйныфлары өчен «Туган тел (татар теле)» һәм «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметлары буенча белем бирү контенты булдыру тормышка ашырылды. Әлеге платформа персональләштерелгән белем бирүнең методологик коралы булып тора, аның төп максаты – һәр укучы өчен белем бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Билгеле булганча, белем бирүдә персональләштерү – конкрет кешегә, аның үзенчәлекләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, «юнәлдерелгән» белем бирү маршруты, индивидуаль белем бирү траекториясе. Белем бирүнең эчтәлеге, темасы, структурасы һәм максатлары укуның индивидуаль үзенчәлекләренә бәйле рәвештә төрлечә була [Словарь терминов…, 2021, с. 22].

СберКласста туган (татар) тел һәм әдәбияттан уку материалы модульләргә (тематик блокларга) бүленгән. Бу уку предметын үзләштерүне җиңеләйтә. Әлеге платформада укучылар мөстәкыйль рәвештә үзләренең уку маршрутын планлаштырырга һәм уку материалын үзләштерергә өйрәнәләр. Укытучының бурычы – укучыларда төп теманы, аның структурасын, модульне үзләштерүнең конкрет

максатларын, шулай ук биремнәрне үтәүгә вакытны планлаштыру күнекмәләрен формалаштыру [Гиниятуллина, Шакурова, 2022, с. 67]. Бу очракта укытучы – online-тьютор гына түгел, ә бәлки аналитик һәм мәгълүмати ресурслар менеджеры, интерактив мультимедиа инструментларын кулланып дәресләр, модульләр, фрагментлар эшләүче-конструктор да булып тора [Tchoshanov, 2013]. Шунысын да әйтергә кирәк, цифрлаштырылган заманда белем бирүне проектлау юнәлешендә дидактиканың яңа төре – е-дидактика (цифрлы дидактика) билгеләнде [D'Angelo, 2007].

СберКласс платформасында туган телдән (татар теленнән) 69 модуль һәм туган (татар) телдәге әдәбияттан 82 модуль урнаштырылды. Модульләрнең эчтәлеге федераль дәүләт белем бирү стандатлары таләпләренә тулысынча җавап бирә һәм федераль белем бирү программасының барлык нигезләмәләренә туры килә. Модульләр Россия халыкларының туган телләрен укыту концепциясе нигезләмәләрен дә исәпкә алып эшләнде. Һәр модуль дәреслекләрдә урын алган һәм 3–12 дәрескә исәпләнгән берничә теманы үз эченә ала.

Модульләрдә һәр укучы үз траекториясен сайлый ала. Һәр дәрәҗәдә биремнәр сайлау мөмкинлеге бар. Укытучы, укучыларның белем дәрәҗәсен исәпкә алып, биремнәр тәкъдим итә, чөнки ул «укыту процессын проектлый белергә тиеш, ә моның өчен аңа предмет эчтәлеген, дидактиканы һәм проектлау нигезләрен белү генә түгел, укыту процессын фәнни нигездә проектлый белү дә кирәк» [Петрова, с. 142]. Модульдә шулай ук һәр дәрәҗәдә башкарылырга тиешле биремнәр саны күрсәтелгән. Шул ук вакытта аны арттырырга яки киметергә рөхсәт ителә. Укучы, тәкъдим ителгән планны карап, бирелгән траекториягә үзе үзгәрешләр кертә ала.

Һәр модуль 4 дәрәҗәгә бүленгән. 1.0 дәрәҗәсен мотивацион биремнәр тәшкил итә, биредә уку материалының укучының шәхси тәҗрибәсе, хисләре, зәвыклары, кызыксынулары белән бәйләнеше ачыла. Мотивация блогы нигез идея һәм проблемалы сорау белән таныштыра. Бу этапта төрле текст, аудио-, видео-, иллюстратив һәм график материаллар куллану да күздә тотыла.

2.0 дәрәҗәсе – репродуктив дәрәҗә, биредә укучы теоретик төшенчәләрне өйрәнә, сораулар бирергә, текстларны чагыштырырга, алардан кирәкле мәгълүмат табарга, әсәрләрдән өзекләр белән эшләргә, текстны күзәтергә өйрәнә.

3.0 дәрәҗәсе – төп дәрәҗә. Ул белем бирү программасында каралган бербөтен материалны үз эченә ала. Әлеге этапта укучы текстны гомуми аңлау, тулы интерпретацияләү, икенче дәрәҗәдә ясалган күзәтүләрне синтезлау юнәлешендә эшли, өйрәнелгәннәрне иҗади форматка күчерә. Бу дәрәҗәдә биремнәр укучыларның сөйләм телен үстерергә һәм баетырга ярдәм итә.

4.0 дәрәҗәсе – тикшеренү дәрәҗәсе. Ул проект эшләү, иҗади биремнәр башкару яки тикшеренүләр үткәрү, таныш булмаган ситуациядә күнекмәләрне куллануны күздә тота.

Платформада биремнәр системасы шундый итеп төзелгән ки, укучы алган белемнәрен тулысынча синтезлый, гомумиләштерә, мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр ясый, үзенең тәнкыйди фикерләвен үстерә ала. Аралашуны саклау максатыннан, биремнәрне үтәү парларда яки төркемдә оештырыла. Бу укучыларга мөстәкыйль рәвештә телдән һәм язма текст төзү барышында туган кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Биремнәрнең бер өлеше, тәкъдим ителгән критерийлар системасына нигезләнеп, үзбәяне яки бер-берсен бәяләүне күздә тота. Укучыларда мөстәкыйльлек формалаша, алар хаталанудан курыкмый башлый.

Платформада белемгә ирешүнең төрле дәрәҗәләре укучыларда тезис планы, доклад, аннотация, рецензия язу, алдан игълан ителгән темага проект төзү өчен кирәкле материал җыю һәм мәгълүмат эшкәртү күнекмәләрен формалаштырырга мөмкинлек бирә.

Платформада урын алган татар халкының теле, мәдәнияте, дөньяга карашы, менталитеты, фәлсәфәсе, тарихы буенча материаллар укучыларда милли үзаң формалашуга ярдәм итә. Заманча информацион-коммуникацион технологияләр ярдәмендә укучыны китапханәләрнең, музейларның, театрларның билгеле бер мөмкинлекләре белән таныштыру әдәбият һәм сәнгатьнең кызыклы дөньясына тирәнтен керергә юл ача.

Платформаның иҗади юнәлешен инша, эссе язу, әдәби-иҗади эш башкару кебек биремнәр тәшкил итә. Үз текстыңны булдыру – курсны үзләштерүнең нәтиҗәсен билгели торган төп продукт. Үз текстыңны язу практикасы укучыларда сүзлекләрнең электрон фондын, татар матур әдәбияты корпусын, татар балалар журналларының рәсми сайтларын һәм башка бик күп верификацияләнгән электрон ресурсларны үз эченә алган тышкы чыганаклар белән эшләү күнекмәсен формалаштыра. Беренчедән, бу укытучылар өчен бик уңайлы, икенчедән, укучыларны төрле чыганаклар белән эшләргә, интернет челтәрендә кирәкле материалны табарга, сүзлекләр белән эшләргә өйрәтә. Шулай итеп, СберКласс платформасының бурычларыннан берсе булып мәгълүмати белем бирү киңлегендә ориентлашырга өйрәтү: энциклопедияләр, сүзлекләр, белешмәләр, махсус әдәбият белән эшләү; китапханә каталогларыннан, библиографик күрсәткечләрдән, интернетта эзләү системасыннан файдалану тора.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: цифрлы белем бирү ресурслары укучылар тарафыннан турыдан-туры дәресләрдә һәм дистанцион форматта уку барышында мөстәкыйль белем алуда уңышлы кулланыла. Шулай ук алар дәрестән тыш эштә дә файдалы була ала. Иң мөһиме – кайсы гына очракта кулланылмасын, алар һәрвакыт укучыларның белем алу ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш.

**Әдәбият**

*Jahnke I.* Digital Didactical Designs as research framework: iPad integration in Nordic schools / I. Jahnke, P. Bergstrom // Computers & Education. 2017. № 113. P. 1–15.

Словарь терминов и понятий цифровой дидактики / Рос. гос. проф.-пед. ун-т; авт.-сост.: Н.В. Ломовцева, Н.М. Заречнева, О.В. Ушакова, С.Н. Ярина. Екатеринбург: РГППУ: Ажур, 2021. 84 с.

*Никулина Т.В., Стариченко Е.Б.* Информатизация и цифровизация образования: понятия, технологии, управление // Педагогическое образование в России, 2018. № 8. С. 107–113.

*Aydarova S.H.* Models of media education in teaching tatar language / S.H. Aydarova, L.M. Giniyatullina, R.K. Sagdieva, D.H. Husnutdinov, R.H. Mirzagitov, F.I. Gabidullina // Espacios. 2017. T. 38. № 60. P. 6.

Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования. М.: Просвещение, 2021. 57 с.

Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования. М.: Просвещение, 2021. 124 с.

*Мөхәрләмова Г.Н.* Туган тел һәм әдәбиятны дистанцион укыту шартларында укучыларда танып белү универсаль уку гамәлләрен формалаштыру үзенчәлекләре // Литература и художественная культура тюркских народов в контексте Восток Запад [Электронный ресурс]: материалы Междунар. науч.-практ. онлайн-конф. (Казань, 22–25 окт. 2020 г.) / под ред. Ф.С. Сайфулиной. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. – С. 206-209.

*Гиниятуллина Л.М., Шакурова М.М.* Учебный материал курса «Родной язык (татарский)» на СберКлассе // Актуальные проблемы изучения и преподавания татарской филологии: Материалы Всерос. науч.-практи. Конф. с междунар. участием, посвящ. 55-летию Башкирского гос. Пед. ун-та им. М. Акмуллы и 30-летию кафедры татарского языка и литературы / отв. ред. И.С. Насипов, зам. отв. ред. Н.У. Халиуллина. Уфа, 2022. С. 66–69.

*Tchoshanov M.* Engineering of Learning: Conceptualizing e-Didactics. Moskow: UNESCO Institute for information nechnologies in education. 2013. 194 p.

*D'Angelo G.* From Didactics to E-Didactics-Paradigms, Models and Techniques for e-Learning. Naples: Liguori editore. 2007. 404 p.

*Петрова Е.В.* Цифровая дидактика: проектирование процесса обучения и его сопровождение // Современное педагогическое образование, 2018. С. 141–144.

***Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Мөхәрләмова Гөлназ Нурфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге мөдире*

УДК 371.214.41=512.145

*М.М. Шәкүрова*

# УКЫРГА-ЯЗАРГА ӨЙРӘТҮДӘ Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ МЕТОДИК СИСТЕМАСЫ

В данной статье представляются особенности методических систем обучения грамоте начала XX в. Галимджана Ибрагимова, который работал в направлении совершенствования звукового метода на основе идей развивающего обучения родному (татарскому) языку. Статья посвящена актуальной проблеме обучения грамоте младших школьников начального общего образования. Особое внимание в статье уделяется анализу опыта применения методики Г. Ибрагимова в практике общеобразовательной организации. В работе устанавливается и описывается вся совокупность новых методов, предложенных в методической системе обучения грамоте Г. Ибрагимова.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, методы обучения, татарский язык, алифба (букварь), звук, буква, методическая система.

This article presents the features of the methodological systems of teaching literacy at the beginning of the 20th century by Galimdzhan Ibragimov who worked in the direction of improving the sound method based on the ideas of developing teaching of the native (Tatar) language. The article is devoted to the current problem of teaching literacy to junior schoolchildren of primary general education. Particular attention is paid to the analysis of the experience of applying G. Ibragimov's methodology in the practice of a general education organization. The work establishes and describes the entire set of new methods proposed in the methodological system of teaching literacy by G. Ibragimov.

**Keywords:** Galimdzhan Ibragimov, teaching methods, Tatar language, alifba (primer), sound, letter, methodological system.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында укырга-язарга өйрәтүгә зур кызыксыну уяна, аның киргәклеге ачыклана. Әлифбалар ул чорда зур тираж белән бастырыла, рус һәм татар мәктәпләре өчен дә дәреслек хезмәтен башкарган грамматика китаплары, методик кулланмалар, үз-үзеңә өйрәткечләр чыга (Г. Баруди, Ә. Максуди, М. Мөхәммәтрәхимов, К. Насыйри, Ш. Таһири, И. Гаспринский, Г. Чыгтай, Ш. Әхмәдиев, М. Корбангалиев, Г. Алпаров һ. б.).

Укырга өйрәтү ысуллары ул чорда дүрт төркемгә бүлеп каралган: 1) хәреф кушу ысулы; 2) иҗек ысулы; 3) аваз ысулы; 4) бөтен сүзләр ысулы [Мирзаһитов, 2019, б. 252].

Ысул – укытучы белән укучының белемнәрне үзләштерү өлкәсендә бергәләп эшләү юллары ул. Ысул алымнардан тора: хәрефләрдән иҗекләр төзү алымы; хәрефләрдән сүзләр төзү алымы; өлешчә фонетик анализ ясау; яңа сүзләр белән эшләү; текстны уку; диалог төзү; сорауларга җавап бирү; уен элементлары белән эшләү; башваткычлар, ребуслар чиштерү һ.б. [Шакурова, 2024, с. 65].

XX гасыр башларында укырга, язарга өйрәткәндә «ысулы хәрфия» (хәреф кушу ысулы), мәддия (иҗек) һәм саутия (аваз) ысулларыннан файдаланганнар. Кадими мөселман мәктәпләрендә (традицион тәртипләрне үзгәрешсез саклау юнәлешендә) белем бирү барышында хәрефләрне кушып – иҗекләп уку ысулы кулланылса, җәдиди мәктәпләрдә исә (дини фәннәр белән бергә дөньяви фәннәргә өстенлек бирү, укытуны ана телендә алып бару, яңача укыту) аваз ысулына нигезләп алып барылган [Татар..., 2017, б. 62].

XX йөз башында татарча уку-язуга өйрәтү методикасын үстерүдә Г. Ибраһимовның 1916 елда язган «Татар телен ничек укытырга? (Телебезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» исемле хезмәтенең гыйльми һәм гамәли әһәмияте зур була. Ниһаять, XX гасыр башларында татар мәктәпләре өчен дә лингводидактик хезмәтләр күпләп чыга башлый. Г. Ибраһимов «Татар телен ничек укытырга?» дигән китабының 1 нче бүлегендә әлифба укытуның ысуллары турында тирән мәгълүмат бирә.

XIX гасыр башларында немец галиме Генрих Стефани (1761–1851) укырга-язарга өйрәтүдә иң отышлы синтетик аваз ысулын тәкъдим итә [Штец, 2007, с. 57]. XIX гасыр ахырларында Россиядә Г. Стефаниның фикерләренә тәләктәшлек белдереп, әлеге аваз ысулы ярдәмендә укырга-язарга өйрәтү буенча Н.А. Корф хезмәтләре дә бар [Корф, 1879, с. 90]

Лев Толстой үзенең «Азбука»сын (1872) мәддия ысулы (иҗек ысулы) белән өйрәтә. Татар дөньясында Һади Максуди да «Мөгаллим әүвәл» (1892) дигән әлифбасын мәддия ысулына таянып укыткан. Шулай ук саутия һәм мәддия ысулларын кулланып (ике ысулга таянып өйрәтү), «Беренче мөгаллим» (1914) дигән әлифба язучылар – Галиәсгар Чыгтай һәм Шәһит Әхмәдиев. Алар әлифбаны катнаш ысул (иҗек һәм аваз ысуллары) кулланып укыталар.

Г. Ибраһимов «бездә башлап ысулы саутия белән эшләүче галим – Исмәгыйль Гаспринский», – ди. Ул И. Гаспралының балалар өчен язган «Хуҗаи сыйбъян» («Балалар укытучысы», 1890) әлифбасын күздә тота [Ибраһимов, 2019, б. 248]. Аның укыту яңалыгы – җәдитчә укыту (авазларны һәм авазларның язудагы билгесе – хәрефләрне өйрәтү). Яңа ысулны кулланып укыту бер уку елы дәвамында укырга, язарга, ислам дине нигезләре белән танышырга, арифметика нигезләрен өйрәнергә, Коръән уку серләренә төшенергә мөмкинлек биргән [Татар..., 2017, б. 72].

Г. Ибраһимовның «Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» дигән хезмәте алты бүлектән тора: «Әлифба укытуның ысуллары», «Ана телендә уку дәресләре», «Имля дәресләре», «Ана теленең сарыф вә нәхүен укыту ысуллары», «Ана телендә инша дәресләре», «Сыйныф тышында укыр өчен китаплар бирү».

XX гасыр башларында укырга-язарга өйрәтү барышында хәрефләрне кушып – иҗекләп уку ысулы урынына яңа ысул – саутия ысулы

күпләп кулланыла башлый. Г. Ибраһимов «Әлифба укытуның ысуллары» дигән бүлеккә әлифба укытуның түбәндәге ысулларына туктала һәм һәрберсенә аңлатма бирә: 1) иҗек ысулы; 2) ысулы мәддия (сузыклар ысулы дип тә атый); 3) ысулы саутия [Ибраһимов, 2019, б. 245–249].

Иҗек ысулының нигезендә, Г. Ибраһимов фикеренчә, хәреф ята: балаларга хәрефләрнең исемнәрен ятлатырга, шул хәрефләрдән иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр ясатырга кирәк. Бөтен әлифбадагы хәрефләр шулай ятлатып чыгыла: *әлиф, би, ти, си, җим, даль, заль, къаф, кяф, сад, гайн* һ. б. Аннары бу хәрефләрне кушып укый башлыйлар: *җим әлиф – җа, ти әлиф – та, къаф әлиф – ка, гайн әлиф – гъа, мим йа – ми, сад уау – су* һ. б. [Ибраһимов, 2019, б. 245–246]. Кызганычка каршы, боларны өйрәтүгә бик озак вакыт бирелгән, башта хәрефләрнең исемнәрен күп еллар дәвамында ятлаганнар, аннары иҗекләр ясап, алар ярдәмендә сүзләр төзегәннәр.

Ысулы мәддия белән укытканда нигез итеп иҗек алына. Бер сузык аваз хәрефен бөтен тартыкларга ялгыйлар: *ба, та, җа, са, га, ла, фа* һ. б.; *би, ти, җи, ми* һ. б. [Ибраһимов, 2019, б. 248]. Аннары алты сузык аваз хәрефләр ярдәмендә иҗекләр ясыйлар, иҗекләрдән сүзләр ясап, шул сүзләр белән җөмләләр язалар. Иҗек ысулына караганда күпкә отышлы булса да, бу ысул белән эшләү дә вакытны күп алган, балаларны укырга-язарга озак өйрәткәннәр.

Ысулы саутиянең нигезендә аваз ята. Аваз сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге буларак карала, аннары авазларның язудагы билгесе – хәрефләре өйрәтелә: «Монда баланың үзенә күптән билгеле булган сүзләрнең бүлекләре – авазлар иң элек белдерелә. Китаптагы хәрефләр шул авазның кәгазьгә төшкән сурәте генә икәне аңлатыла» [Ибраһимов, 2019, б. 248].

Г. Ибраһимов «Бу өч ысулның кайсы яхшырак? дигән сорауга, һичшиксез, ысулы саутия дип җавап бирә. Ысулы саутия белән эшләгәндә автор башлыча ике юлны күрсәтә: 1) башта авазны өйрәтеп, аннан – иҗеккә, иҗектән – сүзгә, сүздән җөмләгә күчү, 2) моның киресенчә: бөтен җөмлә әйтеп, аны сүзләргә аеру, сүзне – иҗеккә, иҗекне авазларга бүлү» [Ибраһимов, 2019, б. 238]. Бүгенге көндә беренче юлны синтез ысулы (җыю) дип атыйлар, әлифба укытканда авазны өйрәтүдән башлап, текстка кадәр барып җитәләр (текстны тыңлау мөмкинлеге дә бар), сүзлек эшен башкаралар, сорауларга җавап бирәләр, диалог төзиләр, үзләренең фикерләрен белдерәләр. Икенчесен анализ ысулы (таркату) дип йөртәләр, ягъни текстны – җөмләләргә, җөмләләрне сүзләргә, сүзләрне иҗекләргә, иҗекләрне авазларга (авазларның язудагы билгесе – хәрефләргә кадәр) таркаталар, иҗади эшләргә дә мөмкинлек туа. Ике ысулдан берьюлы файдалансаң, Г. Ибраһимов андый ысулны «катыш ысул» (катнаш ысул. – *М.Ш.*) дип йөртә: язу-уку ысулы (нигез итеп язуны алу), уку-язу ысулы (нигез итеп укуны алу) [Ибраһимов, 2019, б. 252].

Автор ысулы саутия белән әлифба укытуны өч этапка бүлә: 1) башлангыч дәресләр; 2) хәзерлек дәресләре; 3) әлифбага керешү.

Беренче этапта әлифба укытканда үткәрелә торган башлангыч дәресләрнең максаты – балаларны мәктәпкә ияләштерү (баланы мәктәптә үзен иркен тотарга өйрәтү; аның белән танышу; мәктәпкә керү – мәктәптән чыгу; утыру вә тору; китапны, каләмне кая кую; кара такта белән эшләү, акбурның кирәклеген аңлату; уенга, һавага чыгу кебек төп эшләрне ачыклау, укучының табигатен өйрәнү һ. б. [Ибраһимов, 2019, б. 253]. Укытучы һәр баланы өйрәнә, аның белән якыннанрак таныша, һәрберсен күзәтә, үзенең сыйныф коллективын туплый.

Бүгенге көндә иң мөһиме – балаларны уку-язуга әзерләү. Г. Ибраһимов мондый дәресләрне «хәзерлек дәресләре» дип атый. Ул аларның ике төрен күрсәтә: язарга хәзерлек һәм укуга хәзерлек [Ибраһимов, 2019, б. 254]. Автор әлеге дәресләрнең тулы бер методикасын бирә, анализ ясый: баланы кулына каләм тотарга өйрәтүдән башлап, сүз бүлеге (сүзнең иң кечкенә кисәге) – аваз белән таныштыру, яңа сүзләр уйлап, аларны иҗекләргә бүлү, сүзләрнең авазларын әйтү, аларның язудагы билгеләре – хәрефләр белән эшләү һ. б.: *ат, арба, бакча, кеше, килде, китә, кайта* һ. б. Яңа сүзләр *(Мин, бардым)* һәм җөмлә *(Мин бардым.)* дип, түбәндәге мисалларны китерүе бәхәслерәк тоелды. Әле хәзерлек дәресләрендә 1 нче сыйныфта укучы бала өтергә яки паузага игътибар итми, сүзләрне әйтергә дигәндә, *Мин бардым*, дип әйтәчәк. Яңа сүзләр урынына җөмлә килеп чыга: *Мин бардым*. «Әлеге җөмлә ничә сүздән тора?» дисәк, балалар ике сүздән, *мин, бардым* дип әйтерләр иде.

Яңа сүзләр *(Мин, мәктәп, бардым)* һәм җөмлә *(Мин мәктәпкә бардым.)* дип, түбәндәге мисалларны бирсәк тә отышлы кебек: *Мин, мәктәп, бардым* (өч сүз) – *Мин мәктәпкә бардым* (җөмлә). Алга таба да сүзләр һәм җөмләләрне аеруга игътибар итә: Мин, бардым.

– Монда ничә сүз бар? – Ике.

– Мин базарга бардым, дисәм, ничә сүз була? – Өч.

– Җә, үзең ике сүзне кушып әйт. – Мин килдем.

– Монда ничә суз? – Ике.

– Ниләр? – Мин килдем... [Ибраһимов, 2019, б. 255].

«Балаларга бик билгеле сүзләр алынырга тиеш», – ди күренекле методист, *бел, тиз, кыш* кебек сүзләр белән эшләргә тәкъдим итә. Сүзләрне табарга өйрәткәч, сузык авазлар хәреф белән язылмаган сүзләрне сайлап ала, аннары ул сүзләрдәге сүз бүлегенә – авазларга күчә, *бел, тел* дигән сүзләрне башта икегә, аннан өчкә, дүрткә бүлеп тикшертә: б – л (ب һәм ل), т – л (ت һәм ل) һ. б. [Ибраһимов, 2019, б. 256]. Галим мәдсез (сузык авазны белдерә торган хәрефтән башка) ике хәрефле сүзне авазга бүләргә өйрәтә. «Бу сүздә ничә аваз бар?» дип, сүз бүлеген әкренләп «аваз» дип белдерә, «аваз» төшенчәсенә басым ясый.

Башлангыч һәм хәзерлек дәресләрен узганнан соң, Г. Ибраһимов балаларны ысулы саутия буенча төзелгән әлифба китабыннан

хәрефләр ярдәмендә укырга, язарга, сөйләргә өйрәтә. Ул авазлар һәм аларның язудагы билгеләре – хәрефләр белән кат-кат эшләтә, сыйныф тактасында аларның ничек язылуын, ничек кушылуын күрсәтә. Методист бигрәк тә тыныч, юаш, оялчан балаларны күздән ычкындырмаска, хәтердән чыгармаска куша: «Атап сорамасак, тик утыралар, белсәләр дә җавап бирмиләр. Җавап бирмәгәч, белгәнен-белмәгәнен дә аерыр хәл юк», – ди [Ибраһимов, 2019, б. 257].

Г. Ибраһимовның «Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» дигән хезмәтенең «Әлифба укытуның ысуллары» дигән бүлеге белән танышкач, телнең бөтен мөмкинлекләрен күзаллап, укыту методикасын, аның ысуллары һәм алымнарын яхшы белгән тәҗрибәле укытучы икәнлегенә инанасың. Гомумән алганда, XX гасыр башларында күтәрелгән проблемалар – әлифба укыту ысуллары, балаларны йөгерек укырга өйрәтү, логик эзлекле итеп сөйләргә һәм дөрес итеп язарга өйрәтү методикасы – бүген дә актуаль. Укырга һәм язарга өйрәтү эше мәктәпләрдә иң авыр мәсьәләләрдән санала. Һәрбер хәреф дүрт төрле формада языла. Г. Ибраһимов әлифба укытуның иң авыр ягына – «хәрефләрнең баш, ахыр, урта вә ялгыз рәвештә дүрт шәкелдә йөрүенә» игътибар итә.

Тел өлкәсенә караган хезмәтләрендә Г. Шәрәф «Татар теленең фонетикасы» дигән мәкаләсендә [Рухи мирас..., 2021, б. 10] әлифнең сүз уртасында ا / әлиф авазына йөрүе, сүз башында тулы аваз булмаган һәмзә урынына йөрүе сәбәпле, балаларга бер үк хәрефне ике төрле укырга туры килгәнлектән, укылу ягыннан уңайсызлыклар булуын кисәткән.

XX гасыр башларында татар әдәби теленең фонетик нормаларын эшкәртү, әлифба һәм язу өлкәсендә яшәп килгән каршылыкларны хәл итү һәм орфографик кагыйдәләрне бер тәртипкә китерү, педагогика һәм методика фәнен эшләү, укыту ысулларын ачыклау мәсьәләләре бик күпләрне борчый. Шулар арасында укырга-язарга өйрәтү методикасына төпле нигез салучыларның берсе булган М.Х. Корбангалиев тә бар. Ул әлифба укыту ысулларын өч өлешкә бүлеп тикшерә, анализ ясый: 1) *тәркип ысулы* төп гамәле *(хәрефләрне җыеп укыту, синтез)* – «сүзнең өлешләреннән бөтен сүзгә күчү, ягъни укытуның хәрефләрдән яки авазлардан башланып, иҗекләргә вә сүзләргә күчүе; 2) *тәһлил ысулы (анализ)* – укыту бөтен сүздән яки җөмләдән башланып, аларның өлешләренә, ягъни иҗекләргә, авазларга яки хәрефләргә күчү; 3) *тәһлил-тәркип ысуллары (катнаш ысул (синтез-анализ ысулы))*. Болары белән укытканда, тәркип, тәһлил ысуллары бер-берсе белән төрле рәвештә бәйләнеп баралар» [Корбангалиев, 1920, б. 40]. Автор, укырга өйрәткәндә, иң элек сүзләрне күреп, зиһенгә алырга, ягъни күзнең бер хәрәкәте белән төркем сүзләрне берьюлы эләктереп ала белергә кирәклекне күз уңында тота, баланың «уку даирәсен» тиз хасил итү турында уйлана. Укуның тышкы җәһәте (йөгереклеге, дөреслеге һәм кычкырып уку) һәм эчке җәһәте (аңлап һәм тәэсирле уку) турында тирән мәгълүмат бирә.

Чынлап та, кагыйдә ятлатып кына укучыны дөрес укырга һәм язарга өйрәтеп булмый әле. «Сүздәге авазларның ачык, тулы һәм бөтен әйтелүе укуның дөреслеге була», – дип, Г. Ибраһимов әлифбага дикъкатьне кабат юнәлтә, аның мөһимлеген ассызыклый. Ул инша (язма өслүп) дәресләренә һәрвакыт игътибар итәргә куша: «Бала укый белгәч, сүздәге хәрефләрне таный, аларны кушып сүз, җөмләләр ясый һәм дөрес итеп яза белә» [Ибраһимов, 2019, б. 261].

Г. Ибраһимов – чыннан да күпкырлы, бай иҗаты белән кызыклы шәхес. Аның фәнни һәм методик хезмәтләре хәзер дә зур әһәмияткә ия. Әлифба укыту ысуллары арасында бүген дә аваз ысулы иң әһәмиятлесе булып санала. Беренче дәрестән алып аваз, хәреф төшенчәләрен аеру, игътибарны әйтелешкә юнәлтү, хәрефләрне кушып укырга, язарга өйрәтү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерүгә, көндәлек аралашуга бәйле сөйләм этикеты үрнәкләре белән һәрдаим таныштырып баруга зур әһәмият бирелә.

**Әдәбият**

*Ибраһимов Г.Г.* Татар телен ничек укытырга? // Әсәрләр: 15 томда. 9 т. Татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләр / төз. Ә.Х. Алиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. Б. 238–312.

*Ибраһимов Ф.* Белем әлифбадан башлана: татарча грамотага өйрәтү методикасы тарихы һәм әлифбалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. 335 б.

*Корбангалиев М.Х.* Ана теле методикасы. Казан: Корылтай, 1920. 245 б.

*Корф Н.А.* Русская начальная школа: рук. для земских гласных и учителей сельских шк. Изд. 6-е, вновь испр. и доп. СПб.: Тип. М.А. Хана, 1879. 195 с.

*Мирзагитов Р.Х.* Основные формы и методы организации татарского лингвистического образования до начало XX века // Ученые записки – 2 012. Сборник научных статей преподавателей Института филологии и искусств КФУ. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2012. С. 138–143.

Татар педагогик фикере тарихы. Казан: ТФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. 308 б.

*Шакурова М.М.* Современный букварь по родному (татарскому) языку // Казанская наука. 2024. № 6. С. 65–67.

Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Галимҗан Шәрәф. Әсәрләр, хатлар, документлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Галимджан Шараф. Сочинения, письма, документы / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Э.М. Галимҗанова, Г.Н. Зәйниева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.А. Хөснетдинова; кереш сүз авт. Ф.Г. Фәйзуллина. Казан: ТӘһСИ, 2022. 17 нче чыг. 300 б.

*Штец Л.Л.* Теория и методика обучения грамоте в дореволюционной России: Методы обучения первоначальному чтению. М.: МГПУ, 2007. 164 с.

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*М.М. Хәбетдинова,*
*Ә.Р. Миндиәрова*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘХНӘСЕНДӘ С. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-ВОЛЖСКАЯ ОБРАЗЫ

В статье систематизированы художественные произведения татарской литературы, в которых встречается образ первой татарской артистки, основоположницы татарского театра С. Гиззатуллиной-Волжской (1892–1974). Для анализа отобраны произведения, относящиеся к разным родам литературы. Поэзия представлена произведениями Г. Тукая, А. Файзи, Р. Файзуллина, Р. Ахметзянова. В фокусе внимания исследователей оказался роман А. Ахметгалиевой «Туташ», тяготеющий по форме к беллетристике, и его сценические интерпретации в жанре одноимённого моноспектакля на радио (редактор Р. Садри, режиссёр Р. Хадиатуллин), мелодрамы «Яратып туя алмадым» («Волжская») (сценарист А. Ахметгалиева, режиссёр Р. Аюпов, 2020), «Туташ. Прерванный полёт» (сценарист Г. Исламова, режиссёр А. Зиганшин, 2023). Доказано, что татарские писатели разрабатывают этот образ в просветительском, романтическом и трагическом ключах. В поэтике доминируют суфийские образы как дань национальной традиции, а также просветительские и романтические образы. Цель авторов – увековечить образ первой татарской женщины, посвятившей себя созданию национального театра. Писатели чаще всего концентрируют внимание на трагических поворотах судьбы своей героини, игнорируя ее творческий потенциал на сцене и работу в качестве режиссёра. Многограннее всех образ легендарной артистки удалось представить драматургу Н. Исанбету.

**Ключевые слова:** татарская литература, татарский театр, С. Гиззатуллина-Волжская, Г. Тукай, А.Файзи, Р. Файзуллин, Н. Исанбет, Р. Ахметзянова, А. Ахметгалиева**.**

The article systematizes works of art of Tatar literature in which the image of the first Tatar artist, the founder of the Tatar theater S. Gizzatullina-Volzhskaya (1892–1974) is found. Works belonging to different types of literature were selected for analysis. Poetry is represented by the works of G. Tukay, A. Faizi, R. Faizullin, R. Akhmetzyanov. The researchers focused on the novel “Tutash” by A. Akhmetgaliyeva which gravitates towards fiction in form and its stage interpretations in the genre of the one-man show of the same name on the radio (editor R. Sadri, director R. Khadiatullin), the melodrama “Yaratyp thuya almadym” (“Volzhskaya “) (screenwriter A. Akhmetgalieva, director R. Ayupov, 2020), “Tutash. “Interrupted Flight” (screenwriter G. Islamova, director A. Ziganshin, 2023). It has been proven that Tatar writers develop this image in educational, romantic and tragic keys. Sufi images as a tribute to the national tradition, as well as educational and romantic images dominate in poetics. The authors’ goal is to immortalize the image of the first Tatar woman who dedicated herself to the creation of a national theater. Writers most often focus on the tragic twists of fate of their heroine ignoring her creative potential on stage and work as a director. The most multifaceted image of the legendary artist was presented by playwright N. Isanbet .

**Key words:** Tatar literature, Tatar theatre, S. Gizzatullina-Volzhskaya, G. Tukay, A. Faizi, R. Faizullin, N. Isanbet, R. Akhmetzyanova, A. Akhmetgalieva.

Татар әдәбияты белемендә рус һәм чит ил әсәрләрендә Шәрык гүзәлләре [Schimmel]), татар әдәбиятында хатын-кыз образлары [Яхин, Зарипова-Четин һ. б.], хәзерге әдәбиятта гендер проблемалары [Afanasev, Breeva, 2016; Afanasev, Breeva, Osmukhina, 2018; Afanasev, Breeva, Osmukhina, 2018a; һ. б.] ничек бирелүен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр шактый.

Әлеге мәкаләдә татар әдәбиятында Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская образының үсеш-үзгәреш юллары ачыклана, татар артисткасы образын интерпретацияләүдә язучыларның карашларын гомумиләштерүгә омтылыш ясала.

Тикшерү материалы булып беренче татар артисткасы образы очраган әдәби әсәрләр хезмәт итте. С. Гыйззәтуллина-Волжская образы татар әдәбиятында мәңгеләштерелгән, шигърияттә – Тукай [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 3], Ә. Фәйзи [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 179], Р. Фәйзуллин [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 206.], Р. Әхмәтҗанов [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 217–230], драматургиядә – Н. Исәнбәт [Исәнбәт, б. 5–116], А. Әхмәтгалиева [Әхмәтгалиева, 2020], прозада – А. Әхмәтгалиева [Әхмәтгалиева, 2017].

С. Гыйззәтуллина-Волжская (1892–1976) – беренче профессиональ татар һәм мөселман актрисасы, ТАССРның атказанган артисты (1926), татар актёрлар мәктәбенең лиро-романтик юнәлешенә нигез салучы. 1907 елда актриса И. Кудашев-Ашказарский җыйган «Сәйяр» исемле беренче профессиональ татар театр труппасына кабул ителә. 1912 елда С. Гыйззәтуллина-Волжская труппадан китә һәм фикердәшләре белән бергә Уфада икенче «Нур» татар театры труппасын оештыра. Биредә ул 1918 елга кадәр режиссёр, җитәкче вазифаларын башкара. Гражданнар сугышы елларында фронтта театр бригадаларында чыгышлар ясый. 1920 елда Ижауда татар драма театры белән җитәкчелек итә. 1924 елга кадәр Казанда Кызыл Октябрь исемендәге театрда эшли [Кашшаф].

Татар әдәбиятында беренче мәртәбә С. Гыйззәтуллина-Волжская образына Г. Тукай мөрәҗәгать итә. Шагыйрьнең 1909 елда язылган «Ике кояш» шигыре актрисага багышлана. Әлеге шигырь Г. Тукайның үз замандашына туган көн бүләге була. Ул аны тамашачыларның күңелен нурландыручы кояш белән чагыштыра [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 3]. Шагыйрь, драматург Ә. Фәйзи дә Габдулла Тукай традициясен дәвам итә. «Сәхипҗамал» (1958) шигырендә ул XX йөз башы татар җәмгыятендә артистканың ролен ассызыклау өчен, космогоник образларга мөрәҗәгать итә. Шагыйрь С. Гыйззәтуллина-Волжская образын үз халкына хезмәт итүче, аның бәхете өчен көрәшүче, зур сәнгате, алга китеше өчен хәтта үзен корбан итүче буларак сурәтли: «Кирәк булса, гомерен, көлә-көлә, / Корбан итәр, тик яшәсенгә / Үз халкының якты сәнгате!». Ә. Фәйзи артистканың батырлыгы, кайчан да булса, ташта, сәнгать әсәрендә мәңгеләште-

реләчәк дип хыяллана. Замандашлары өчен артистка легенда була [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 179].

Р. Әхмәтҗанов С. Гыйззәтуллина-Волжскаяга поэма-дастан багышлый [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 217–230]. Социаль көнкүреш темасын ача торган дастан формасына тартым булган поэмада беренче татар артисткасының сәнгатьтәге фидакярлеге, аның татар халкына тугрылыклы хезмәте мактала. Әсәр 11 өлештән тора. Гарәп традицияләре буенча, 11 – Аллаһны танып-белү саны. Поэмада Шекспир әсәрләреннән килгән мотивлар да урын алган. «Тормыш үзе – театр» дигән фәлсәфи фикер чагыла. Поэма авторы вакыйгалар үстерелешендә XX гасыр башына алып кереп китә. Дастан традициясе нигезендә поэмада мәхәббәт темасы үсеш ала. Тукайның «Булмаса» шигыреннән өзек тә китерелә («Кем белер кадереңне...») [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 219]. Шагыйрь лирик герой – XX гасыр башында сәхнәне һөнәр итеп сайларга батырчылык иткән татар хатын-кызы алдында баш ия.

Шагыйрь дастан традициясе кысаларында шәһәр өстендә бары шәүләсе генә сизелгән илаһи көч – Волжская белән диалог алып бара: «Синме соң бу, / Сәхипҗамал...» [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 220]. Икенче өлештә артистка образы төсмерләнә башлый – ул С. Гыйззәтуллина-Волжская образына тартым ак шәл ябынып йөрүче рухка әверелә.

Дастанның өченче өлешендә актрисаның Тукайның «халыкка хезмәт итү»гә чакыруын («Әйдә халыкка хезмәткә») кабул итүен, мәңгелеккә туган җир белән берлеге, бәйләнеше барлыкка килсен өчен, үзенә «Волжская» тәхәллүсен сайлавына шаһит булабыз. Дастанның хронотобы әкренләп конкрет төсмер ала – Казан яңа заманга атлый. Шәхеснең үз-үзен билгеләргә тырышуы метафорик «тормыш арбасы» мәгънәсен ала, ул әле «Сәйяр» театр труппасы арбасына, әле «Нур» театрына әверелә [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 221].

4 нче өлештә әдип укучыда татар театрына нигез салучылар Г. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал турында күзаллау формалаштыра. Шагыйрь милли театрның үзешчән театрдан академик театрга әверелү юлын күрсәтә.

Дастанда лирик герой кыенлыкларны җиңеп чыгу аша ачыла. 5 нче өлештә шагыйрь героен сайлау алдына куя: Сәхипҗамал кияүгә чыгудан баш тарта һәм иҗатны – ирекле сәнгатьне сайлый.

Дастанның 6–7 нче өлешләрендә беренче театр труппасындагы күңелсез, аяныч вакыйгалар – таркалу, билгесезлек, шуның белән бергә ачлык еллары сурәтләнә, «Нур» гастрольләре географиясе торгызыла. 8 нче бүлектә горур артистка образы горур татар халкы образына әверелә («горур безнең милләт»). Театр халык күңеленең гәүдәләнеше рәвешендә тәкъдим ителә.

9 нчы өлештә ак шәл бөркәнгән актриса образы – яктылык сибеп торган мәгърифәтче, милли сәнгать каһарманы. Туган илебез өстендә

болытлар куерганда күпләр өчен юл күрсәтүче якты йолдызга әйләнгән образның үзенчәлекле сыйфаты тагын да тулыландырыла.

10 нчы өлештә шагыйрь зиратта йөри. Легендар артистканың иҗатташлары Г. Кариев, И. Кудашев-Ашказарский, Г. Тукай, Ш. Камаллар янында С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның да кабере бар.

Дастанның финалы татар театрын оештыручыларга тирән эчкерсез дога булып яңгырый. Аларның тормышы һәм милләт тәрәккыятенә, сәнгате үсешенә керткән эшчәнлеге өлге буларак билгеләнә [Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, б. 230–231].

Татар драматургиясендә С. Гыйззәтуллина-Волжская тормышына һәм беренче татар театр труппалары «Сәйяр» һәм «Нур»ның оешуына багышланган беренче әсәр Н. Исәнбәт тарафыннан языла – 1944 елда «Гөлҗамал» пьесасы дөнья күрә. 1945 елда бу әсәр татар театрының 40 еллыгына багышланган «Иң яхшы татар пьесасы» конкурсында икенче урынны ала. Н. Исәнбәт милли сәнгатебезне алга өндәүче татар театрының үсүен күрсәтә, беренче татар артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның тормышы белән таныштыра. Архив документлары нигезендә без пьесаның язылу тарихын да күзаллый алдык. Әсәрне язганда драматург Сәхипҗамал ханым белән элемтәгә чыга. Артистка драматургка үзенә күрсәткән игътибары өчен рәхмәт белдерә [Хәбетдинова].

Н. Исәнбәт искәрткәнчә, пьесада документаль башлангыч өстенлек итә. Жанр ягыннан әсәр – легендар татар артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның фидакярлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерүгә юнәлдерелгән тарихи драма. Пьесада С. Гыйззәтуллина-Волжская образы үсеш-үзгәрештә бирелә, алга таба *милләт хадимәсе* дәрәҗәсендә үрнәк затка әйләнә. Язучының драма әсәре роман потенциалына ия була. Н. Исәнбәт бу әсәр замандашлары һәм киләчәк буыннар өчен илһам чыганагы булыр дип ышана, татар халкының рухи горизонтын киңәйткән легендар актриса турында яңа әсәрләр язарга нигез булыр дип хыяллана.

Әсәрдә социаль конфликт – искенең яңалык белән көрәше – шәхси конфликт белән тыгыз бәйләнгән: төп герой даими рәвештә сайлау алдында кала, җәмгыять мәнфәгатьләре өчен шәхси бәхетен корбан итә. Әдәбият галиме Н. Ханзафаровның «Нәкый Исәнбәт драматургиясе» хезмәтендә төрки дөньяның беренче артисткасы турындагы драманың идея-сәнгать үзенчәлекләре җентекләп анализлана [Ханзафаров].

Әлеге драманың режиссёрлар (1963 елда – П. Исәнбәт, 2007 елда – Ф. Бикчәнтәев, 2021 елда – Р. Гәрәев) тарафыннан Камал сәхнәсендә куелу тарихы турында театр [Арсланов; Игламов] һәм әдәбият белгечләре [Хәбетдинова] үз фикерләрен матбугатта язып чыктылар.

А. Әхмәтгалиеваның «Туташ» романы [Әхмәтгалиева, 2017] да укучылар тарафыннан җылы кабул ителде. Әмма әдәбият белгечләре әсәрдәге кайбер даталарда ялгышлыклар, яки, киресенчә, еллар күрсәтелмәү, вакыйгаларда буталчыклык җибәрү һәм XX йөз

башы танылган татар шәхесләренең иҗтимагый позициясен бозып язганы өчен авторга тәнкыйть сүзләрен дә җиткерәләр. Әсәр татар телендә тарихи романнар, татар шәхесләре турында китаплар язу өчен бирелгән Татарстан Язучылар берлеге гранты акчасына иҗат ителгән. Әмма чынлыкта «Туташ» тарихи роман түгел, ә күбрәк беллетристика жанрына тартым [Хәбетдинова, 2018; Мөхәммәтова, 2018].

Әлеге роман нигезендә театр һәм радиоспектакльләр өчен сценарийлар булдырыла. Мәсәлән, Г. Кариев исемендәге Казан Татар Дәүләт яшь тамашачы театрында «Яратып туя алмадым» («Волжская») (сценарий авторы А. Әхмәтгалиева, режиссёры Р. Әюпов, 2020) [Әхмәтгалиева, 2020] спектакле куела, татар радиосында «Туташ» моноспектакле (мөхәррире Р. Садри, режиссёры Р. Һадиуллин, 2020) яңгырый. А. Әхмәтгалиева С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның танылган замандашлары белән мөнәсәбәтенә – Г. Тукай, Г. Камал, К. Тинчурин, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Г. Коләхмәтов, җырчы К. Мотыйгый, җәмәгать эшлеклеләре Х. Ямашев, М. Вахитов белән ничек аралашуына да игътибар бирә. Әлеге образлар төп геройның теге яки бу сыйфатын калкурак итеп сурәтләргә ярдәм итәләр. Әсәрдә труппа режиссёры Г. Кариев белән актрисаның катлаулы мөнәсәбәтенә дә урын бирелә. Романда XX гасыр башындагы татар халкының тормышы, театрның «яктылыкка алып чыгуы» яктыртыла.

А. Әхмәтгалиева әсәрендә С. Гыйззәтуллина-Волжская татар театрына нигез салучыларның берсе буларак ачыла. XX гасыр башында мәйданга чыккан актив татар яшьләренең алгы сафында торган Сәхипҗамал язмыш сикәлтәләре, татар халкы арасында театрга каршы чыгулар, театр труппасы вәкилләре арасында көнләшү, татулык булмау һәм хыянәт, түрәләрнең битарафлыгына карамастан, сәхнәгә беренче булып күтәрелергә батырчылык итә һәм гомер буе яшьлек идеалларына тугрылык саклый. Ул башта «Сәйяр» труппасы, аннары «Нур» труппасы белән спектакльләр куеп, Россия буйлап гастрольләрдә йөри.

Моноспектакльнең хронотобы үз эченә герой тормышындагы төп вакыйгаларны ала: театрга килү, «Сәйяр» һәм «Нур» исемле беренче татар театр труппалары оешу, режиссер Г. Кариев белән мөнәсәбәте, Г. Тукайның химаячелеге, күчмә тормыш авырлыклары. Сценарий куючыларның максаты – 1905 елгы революция шартларында милли театр булдыру юлында үз героеның фидакярлеген ассызыклау. Әмма сценарий куючы игътибарыннан артистка тудырган сәхнә образлары төшеп кала. С. Гыйззәтуллина-Волжская рольләрне режиссёрларча ачу бурычын да куя. Ул үзе киңкырлы актриса була: көлкеле рольләрне дә, драматик рольләрне дә бердәй оста башкара. Тәнкыйтьчеләрне аның нәфислеге, тамашачыларга әсәр героеның күңел хәләтен ихлас итеп җиткерә алуы сокландыра.

Режиссёр Р. Әюпов үз спектаклендә игътибарны бөек актриса тормышының соңгы этабына – Чистай психик авырулар интернатын-

да яшәү чорына юнәлтә. А. Әхмәтгалиева, сценарий язганда, үзенең беллетристик әсәрен пьеса-мелодрамага әйләндерә. Нәтиҗәдә, тамашачы ялгызлык фаҗигасының шаһиты була: С. Гыйззәтуллина-Волжская ялгызы гына үзенең авыруы белән көрәшә. Даһи артистканың тормышы – бөтен җаны-тәне белән ышанып атлаган юлының, ни кызганыч, аяныч фаҗигага илтүе – акылдан язу күренешләре аша торгызыла. Р. Әюпов сәхнәдә бөек татар актрисасы – милләт хадимәсенең бөек образын тудыра. Спектакльнең сюжеты гадилеге белән аерылып тора. Анда яхшылык белән яманлык бер-берсенә кискен каршы куелган. Геройларның репликалары мелодрамага хас югары эмоциональлек белән аерылып тора. «Яратып туя алмадым» спектаклендә акцент гамәлләргә түгел, ә диалогларга ясала. Гомумән, театр, халкы өчен үз бәхетен корбан иткән героиняның катлаулы язмышы шәхси фаҗигасы аша бирелә.

Сценарий Чеховның «палата № 6» реминисценциясенә нигезләнгән. Төп образлар укылышы да шуннан. Пьесада, ялгыз кеше язмышы турындагы мелодраматик сюжет белән беррәттән, театраль сюжет үсеш ала. Күлмәкләр «тормыш карнавалы»нда көлкеле газап чигүче, һәрвакыт нәрсә турындадыр хыялланучы затлы Пьеро костюмына охшый. Чолан хронотобының сценографиясе борынгы амфитеатр образын хәтерләтә. Сәхипҗамалның Жанна д'Арк спектакленә әзерләнү (Халидә Сөнгатуллина) күренеше асылында фаҗига ята. Танылган актрисаның челтәр-рәшәткә үрү метафорасы да ачык укыла... Күрәсең, бөтен спектакль «хакимият һәм халык», «тарихта шәхеснең роле», «иҗади шәхеснең трагедиясе» темалары тирәсендә. Актрисаның Аккош җыры бу дөньяның көчлеләренә мөрәҗәгать итү монологы буларак «укыла».

Иҗади шәхеснең система белән көрәше сюжет үскән саен фаҗигалы төс ала бара. Диспансер директоры (Илфат Камалиев) спектакльдә карикатур рәвештә бирелә, ул ниндидер җен-пәригә тартым. Героиняның харизматик шәхесен ачуда табиб (Илфат Гыйбадуллин) белән икесе арасындагы мөнәсәбәтләргә корылган сюжет линиясе ярдәм итә.

Сюжетның катализаторы булып мәхәббәт өчпочмагы хезмәт итә: түрә – табиб – шәфкать туташы. Кызганыч ки, спектакльдә милли театрга нигез салучы актрисаның иҗади потенциалын ачу детальләре җитми. Ни өчен ул Волжская дип аталырга хаклы булган?!... Волжскаяны татар театрының башка актрисаларыннан нәрсә аерып торган?!... Сирәк репликалар тамашачыга әлеге шәхеснең татар мәдәнияте тарихындагы ролен күзалларга ярдәм итми. Төп героиняның иҗади потенциалы, режиссёр уйлавынча, Волжская – Жанна д'Арк параллеле аша ачыла. Спектакльдә татар хатынының халкы өчен, аның киләчәге өчен кылган батырлыгы шул рәвешле формалаша.

2023 елда Уфаның «Нур» дәүләт татар театры «Туташ. Өзелгән очыш...» спектаклен (режиссёры Азат Җиһаншин) куйды. Ул А. Әхмәтгалиева әсәре буенча әзерләнгән. Инсценировка авторы – Гөлнур

Госманова. Бу спектакль-байопик шулай ук беренче татар актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның катлаулы язмышы турында сөйли, аның тормышындагы күтәрелешләр һәм түбән төшүләр, шәхес һәм җәмгыять арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр үзәк бер сызык буларак үстерелә.

Сюжет хәзерге һәм үткән арасында параллель рәвештә бара. Актриса гомеренең соңгы елларын үткәргән психик авырулар хастаханәсе диварлары вакыт-вакыт «ачылып» китәләр, милли театр булдыру идеясе белән янган артистканың үткәндәге якты һәм бай вакыйгаларын гәүдәләндерәләр. Актриса театр хакына беренче мәхәббәтен дә, туганлык бәйләнешләрен дә, хатын-кыз бәхетен дә корбан итә. Әсәрдәге төп конфликт герой күңелендә, җанында кайнаган эчке каршылыкларга корыла.

Спектакльдә Габдулла Тукай (Айнур Баянов), Кәрим Тинчурин (Руслан Хисаметдинов), Вәли Мортазин (Эльмир Газизуллин, Руслан Хисаметдинов), Габдулла Кариев (Вилдан Мисбахов), Ильясбәк Кудашев-Ашказарский (Айрат Фатыйхов) кебек күренекле шәхесләр образлары очрый [Данилова].

Бу мәкаләдә XX–XXI гасырлар татар әдәбиятының «татар театры анасы» образы очрый торган әсәрләре анализланды. С. Гыйззәтуллина-Волжская шәхесен ачучы беренче язучы – Г. Тукай. Ул космогоник образлар кулланып, актриса образын романтиклаштыра. Бу традицияне Ә. Фәйзи, Р. Әхмәтҗанов һәм Р. Фәйзуллиннар дәвам итә. Актрисаның язмышы фаҗигалы итеп сурәтләнә: төп игътибар аның исән чагында тиешле бәя ала алмавына, ялгызлыгына юнәлтелә. Татар шагыйрьләре, С. Гыйззәтуллина-Волжская образын тудырып, багышлау жанрында шигырьләр (Г. Тукай, Ә. Фәйзи, Р. Фәйзуллин) һәм поэма-дастаннар (Р. Әхмәтҗанов) иҗат иткәннәр.

А. Әхмәтгалиева «Туташ» романы белән үзен татар халкы тарихын колачлап бәяләргә сәләтле язучы буларак күрсәтте. Әйтеп үтелгәнчә, әсәр жанр формасы буенча беллетристикага тартым, дидек. Герой язмышы тирән конфликтлы драматик вакыйгалар аша яктыртыла. Әсәр сюжеты үзәгендә – кайгы һәм шатлыклар, табыш һәм югалтулар белән тулы хатын-кыз язмышы. Драматик бәрелешләр, төп геройның башка персонажлар белән каршылыклары хикәяләүнең алыштыргысыз элементы, бу аның катлаулы характерын ачарга да ярдәм итә.

Радиодагы «Туташ» моноспектаклендә артистка язмышындагы төп вакыйгаларга игътибар бирелә. Финалда аның образы хатын-кыз матурлыгын чагылдырган ак аккош, гомерен халкына багышлаган ак күбәләк – ирек, олылык, хөрлек символы буларак күтәрелә.

«Яратып туя алмадым», «Туташ. Өзелгән очыш» спектакльләрендә С. Волжская-Гыйззәтуллина образы (сценарий авторы А. Әхмәтгалиева, режиссёры Р. Әюпов, 2020), (сценарий авторы Г. Госманова, режиссёры А. Җиһаншин, 2023) тарихи шәхес буларак башка төрле алымнар белән ачыла. Героиняның чын асылы гамәлләре белән генә түгел, тормышка, сәнгатькә мәхәббәте диалоглар аша да күрсәтелә.

Артистканы Жанна д'Арк белән чагыштыру параллеле мөһим роль уйный. Татар хатын-кызы кылган батырлыкның масштабы әнә шулай ассызыклана.

Легендар артистканың күпкырлы образын драматург Н. Исәнбәт «Гөлҗамал» пьесасында [Исәнбәт, 1944] ачып бирә ала, чөнки бу әсәр авторның артистка белән тыгыз хезмәттәшлеге вакытында иҗат ителә. Гомумән, бу әле тикшеренүләребезнең беренче өлеше генә, алга таба С. Волжская-Гыйззәтуллина образының татар сәхнәсендә тормышка ашырылу үзенчәлекләрен өйрәнүне дәвам итәчәкбез.

### Әдәбият

*Арсланов М.Г.* «Гульжамал» Н. Исанбета и П. Исанбета – спектакль о первой татарской актрисе // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2014. № 4-1. С. 60–63.

*Әхмәтгалиева А.* Яратып туялмадым: драма // Режиссёр Р. Әюповның шәхси архивы. Кульязма. 2020. 19 б.

*Әхмәтгалиева А.* Туташ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 527 б.

*Данилова Г.* В Уфе на госпремию выдвинут спектакль театра «Нур» о первой татарской актрисе // URL: https://rg.ru/2024/09/04/reg-pfo/v-ufe-na-gospremiiu-vydvinut-spektakl-teatra-nur-o-pervoj-tatarskoj-aktrise.html?ysclid=m2vbucyxl6532856594 (мөрәҗәгать итү көне: 04.09.2024).

*Игламов Н.* Наки Исанбет «Гульджамал» // 100 лет. Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала: в 2 т. Т. 1. Спектакли. Казань: Заман, 2009. С. 310–312.

*Исәнбәт Н.* Гөлҗамал // *Исәнбәт Н.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. Т. 4. Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 5–116.

*Кашшаф Г.* Беренче артистка: С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның тормыш һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 50 б.

*Мөхәммәтова Р.* «Туташ» турында гәпләшү: «Сары матбугат иртәрәк туса, Волжская, Ильскаялар турында күбрәк белер идек» // URL: https://intertat.tatar/news/tutash-turynda-gapl-sh-sary-matbugat-irt-r-k-tusa-volzhskaya-ilskayalar-turynda-k-br-k-beler-idek?ysclid=l94gnhmw7x695940801 (мөрәҗәгать итү көне: 02.09.2024).

Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская / төз. Җ. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2012. 480 б.

*Хабутдинова М.М.* Заглянув за занавес истории // Звезда Поволжья. 2022. № 27 (1098). 16–22 июля. С. 1.

*Хабутдинова М.М.* Творческая история пьесы «Гөлҗамал» («Гульжамал») в зеркале переписки Н. Исанбета с С. Гиззатуллиной-Волжской // Филология и культура = Philologie and Culture. 2022. № 3 (69). С. 180–187.

*Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 190 с.

*Afanasev A., Breeva T., Osmukhina O.* “Transition Plot” in Dina Rubina's Works of the 1990th (years) // Ad Alta-Journal of Interdisciplinary Research. T. 8. Вып. 1. Спец. вып. 3. 2018. P. 12–14.

*Afanasev A., Breeva T., Osmukhina O.* The Problem of Female Subjectivity in the Novel “The Handwriting of Leonardo” by Dina Rubina // Tarih Kultur Ve Sanat Arastirmalari Dergisi-Journal of History Culture and Art Research. T. 7, Вып. 4, Спец. вып. SI. 2018a. P. 293–299.

*Afanasev A., Breev T.* Gender picture of peace in Russian women rock-poetry (poetic novels “sprinter” and “staLker”by Diana Arbenina) // Journal of Language and Literature. Vol. 7. Issue 1. 2016. P. 159–162.

*Zaripova-Chetin Ch.* “No, my soul does not agree! Limited faith is narrow for me…”: (On the 140th anniversary of Sagit Ramiev’s birth) // Tatarica. № 14. 2020. P. 147–156.

*Yakhin F.* The Image of fn Etnical Woman in the Medieval Tatar Sufi Literature // Philology. Theory &Practice. 2017. № 11-1 (77). P. 50–52.

*Yusupov A.F., Yusupova N.M., Sibgatullina A.T.* The symbolic system in tatar poetry of the first half of the twentieth century: The transformation of nominative meanings // Humanities and Social Sciences Reviews. Vol. 7. № 6, 2019. P. 297–300.

*Zagidullina D.F., Yusupova N.M., Yusupov A.F.* Pair Sufi symbols in Tatar poetry of the 20th century: Complexity and transformation of symbols // XLinguae. Vol. 10. № 3. 2017. P. 75 – 82,

*Schimmel A.* Mystical Dimensions of Islam. Chapel Hill: University of North Carolina Press, 1975. 512 p.

***Хәбетдинова Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел Буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты, Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

***Миндиәрова Әминә Рәмзил кызы,***
*Казан (Идел Буе) федераль университеты татар әдәбияты кафедрасы 1 курс магистры*

УДК 730

*Н.М. Горюнова*

# ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕНДӘГЕ СКУЛЬПТУРАЛАР

На протяжении 70 лет складывался городской ансамбль Лениногорска, исходя из плодотворного участия всех видов искусств. Важную роль в процессе создания гармонической среды для жизни человека играет монументальная скульптура и ее разновидности. Художественный уровень архитектурно-скульптурной среды, в свою очередь, зависит от слаженного осознанного стремления всех участников градостроительного процесса на каждом этапе развития города.

**Ключевые слова:** городская среда, монументальная скульптура, архитектурно-скульптурная среда, арт-объекты.

For 70 years the urban ensemble of Leninogorsk has been taking shape based on the fruitful participation of all types of arts. An important role in the process of creating a harmonious environment for human life is played by monumental sculpture and its varieties. The artistic level of the architectural and sculptural environment in turn depends on the coordinated conscious desire of all participants in the urban development process at each stage of the city's development.

**Keywords:** urban environment, monumental sculpture, architectural and sculptural environment, art objects.

Лениногорск шәһәре 1950 елда палаткалардан башлана, ә 1955 елда шәһәр статусын ала. Шәһәр мохите – физик күренеш булудан бигрәк, социаль күренеш. Ул матди һәм рухи мәдәниятне тулаем колачлый. Камилләшкән шәһәр ансамбле – шәһәр төзелешендә катнашучыларның аңлы һәм эзлекле омтылыш-тырышлыклары нәтиҗәсе ул.

1950 елларда нефть чыгару сәнәгате үсеше белән бәйле рәвештә ТАССР территориясендә генпланнары Совет шәһәр төзелеше казанышларын исәпкә алып эшләнгән яңа шәһәрләр барлыкка килә, Лениногорск та – шундыйлардан. Анда пространство композицияләренең иске неоклассик принциплары саклана, һәм үз инфраструктурасы булган яңа микрорайоннар алар артыннан тезелеп китә сыман. Лениногорскиның баш архитекторы В.И. Бельский шәһәрне ансамбль рәвешендә кору идеясен яклый, аны «Бөгелмәнефть» нефть промыселлары идарәсе җитәкчесе П.В. Васильев, проектчы А.М. Марчевский һәм төзелеш җитәкчесе Н.Н. Гундырев та хуплый. 1958 елда (Ромашкино нефть ятмасының 10 еллыгына) Яшел тауда төзелгән ротонда – бу җир биргән кара алтын, нефтьчеләрнең фидакяр хезмәте өчен рәхмәт хисләренең үзенчәлекле архитектур гәүдәләнеше. Һәм, иң мөһиме, ул кеше һәм табигать гармониясе идеясен чагылдыра. Ул шәһәр төзелешендә композицион доминанта, аны эстетик яктан кабатланмас итүче генә түгел, ә бәлки идея-сәнгать ягыннан

шәһәрнең тышкы йөзен ассызыклаучы корылма, ә соңыннан – визит карточкасы да.

Шәһәр структурасын барлыкка китерүдә катнашкан һәр сәнгать төре, мохитнең гомуми йогынтысын көчәйтеп, аның уртак сәнгати сыйфатын күтәрә һәм нәтиҗәле итә. Монументаль скульптура үзенең идея-тәрбияви вазифасын үти һәм зур киңлектә комплексның бер өлеше буларак кабул ителә. Кызганычка каршы, архитектура-скульптура мохите һәрвакытта да проектланмый, еш кына ул билгеле бер вакыт дәвамында барлыкка килә, шуңа күрә уңышсызлыкларга да очрарга мөмкин. Уңышлы чишелешләр шәһәр мохитен гармонияле итә. Ул архитектура, монументаль сәнгать, дизайн һәм табигый ландшафтны бербөтен итеп берләштерә.

Лениногорск акрынлап сыннарга байый, шәһәрдә скульптуралар саны көннән-көн арта бара, 1950 елларда боларны иҗтимагый архитектура объектларындагы рельефлар тәшкил итә. Алар биналарның билгеләнешен ассызыклый һәм аларны гомуми төзелештән аерып тора (балалар яслесе, I посёлоктагы мәктәп, партия һәм административ органнар бинасы, нефтьчеләр клубы). Түгәрәк скульптура, нигездә, монументаль-декоратив характерда була һәм стандарт үрнәкләргә таянып тудырыла: мәктәп аллеясының ян-якларында пионерларның сыннары, бала тудыру йорты ишеге янындагы бала һәм ана сыннары, стадион һәм урман паркының скульптур бизәлеше. Тәүге таш корылмаларның берсе – балалар яслесе бинасы (1952–1953). Бу симметрияле бер катлы корылма, аның үзәгенә – сюжетлы рельеф белән бизәлгән биек фронтонга образлы рәвештә акцент ясалган. Барельефның тормыш-көнкүрешкә якын, әмма мәһабәтлеген җуймаган сәхнәсендә балаларның тәрбиячеләрне уратып алуы сурәтләнгән. Скульптур композиция бинаның компактлы архитектурасына бик тә туры килә.

Лениногорскида торгызылган беренче корылмалардан ук архитекторларның һәм төзүчеләрнең шәһәрнең сәнгати йөзен булдырырга омтылулары сизелә. Шул ук вакытта партия һәм административ аппарат өчен классик өч катлы сарай формасындагы бина төзелә, аның парадный өченче катында утырышлар залы урнашкан (1953). Цоколь этажы яссы руст белән бизәлгән, икенче һәм өченче катларны Коринф ордеры пилястралары берләштереп тора. Фронтон традицион эчтәлекле барельефны үз эченә ала. Анда СССР гербы урнашкан, бәйрәмчә флаглар һәм тасмалар җилферди. Бина Ленин проспектының башы буларак планлаштырылган. Әлеге проспект күлгә һәм Яшел тауга да алып чыга. Аның буеннан буена (600 м) ике яклап симметрияле рәвештә төрле токымлы үсемлекләр утыртылган, урыны-урыны белән сын, фонтан, эскәмия һәм сукмаклар белән чуарланган ял мәйданчыклары ясалган. Проспект Г. Тукай урамы белән кисешкән урында нәфис позалардагы балериналар гәүдәләндерелгән «Аккош күле» фонтаны белән бизәлгән зур булмаган мәйдан эшләнгән (1959). Үзенең образлы чишелеше белән ул Мәскәү Халык хуҗалыгы каза-

нышлары күргәзмәсендәге (ВДНХ) скульптур төркемнәрне хәтерләтә: алар репрезентатив һәм шул ук вакытта табигый пропорцияләргә ия, шуңа күрә әйләнә-тирә мохит белән органик рәвештә яраша.

Шәһәр үсүдән туктамый, күләм-киңлеккә бәйле яңа чишелешләр, яңа архитектур-образлы акцентлар таләп итә. В.И. Ленин исемендәге мәйдан Калинин исемендәге мәдәният йорты бинасының көнчыгыш фасады һәм Г. Тукай, Ленинград урамнары киселешендәге г-рәвешле дүрт катлы торак йортлар арасында ясалган. 1960 еллар башында төзелгән Мәдәният сарае эре пропорцияләре белән аерылып тора (типовой проект), аның сигез колонналы мәһабәт портигы әйләнә-тирәдәге корылмаларның фасадларында декоратив фронтоннар, сандриклар һәм сылап ясалган күпертмә бизәкле үсемлек орнаментлары, гирляндалар рәвешендә яңгыраш таба.

Мәйдан – шәһәрнең мәдәният үзәге, ул шәхеснең гармонияле үсеше идеясен гәүдәләндерә, үзенең прототипларын – антик ансамбльләрне һәм данлы С.-Петербургны – Ленинградны искә төшерә. 1960 елның июнендә мәйданда В.И. Ленинга монументаль һәйкәл куела (нигез итеп скульптор Г.Д. Алексеевның 1924 елда торгызылган «Өндәүче юлбашчы» сыны алына; архитектор-проектчысы – Казаннан Н. С. Артамонов). Юлбашчының мәрмәр пьедесталга бастырылган монументаль бронза фигурасы шул ук исемдәге мәйданның мәгънәви үзәгенә әверелә һәм Лениногорск шәһәренең исемен идея-сәнгать ягыннан ныгыта.

1970–1980 елларда торгызылган иҗтимагый корылмалар конструктивизм билгеләренә ия. Аларның план һәм күләмнәре геометрик яктан ачык һәм төгәл булуы белән аерылып тора. Тышкы кыяфәтләрендә төзелеш материаллары (металл, пыяла, бетон) һәм монументаль-декоратив бизәлеш зур әһәмияткә ия була башлый. Бу еллар – шәһәр сәнгать тормышы гөрләп чәчәк аткан вакыт, архитекторлар һәм рәссамнар кеше өчен гармонияле мохит булдыру өлкәсендә уртак тырышлык куйган чор. Яшь талантлы архитекторлар төркемен (В. Морозов һ. б.) тәҗрибәле оста, шәһәрнең баш архитекторы В.П. Федотов җитәкли, шәһәрнең баш рәссамы О.А. Кульпин тулыландыра. Шәһәрне монументаль бизәүгә Татарстанның зур сәнгать эшлеклеләре һәм Лениногорск рәссамнары А. Абзгильдин, В. Карамышев, В. Маликов, В. Рогожин, Ш. Шәйдуллин, В. Гецев, Я. Зиннәтуллин, О. Кульпин, Т. Самойлова һ. б. җәлеп ителә. Нәкъ менә шул вакытта зур оригиналь монументаль-декоратив скульптура ансамбльләре (спорт комплексы, автовокзал, яңа кинотеатр), металлдан декоратив арт-объектлар, рельеф, мозаикалар, агач скульптура, шәһәр урамнарында һәм урман-парк зонасында мозаикалы стелалар пәйда була. Шушы чорның беренче мөһим монументаль объекты 1970 елда тантаналы рәвештә ачыла. Ул – күренекле татар революционеры һәм җәмәгать эшлеклесе Мулланур Вахитов һәйкәле. Скульптур портретның авторы – Казан сәнгать училищесында укыганда С.С. Ахунның шәкерте булган, ТАССРның атказанган сәнгать

эшлеклесе В.М. Маликов (Казан) тәэсирле, гомумиләштерелгән образ тудырган. Аңарда документаль портретлык югары монументаль трактовка белән органик рәвештә яраша. Бюст 11 нче номерлы татар гимназиясе янындагы сквер эчендә биек подиумга урнаштырылган. Бу чорның иң күренекле һәйкәле – һичшиксез, Татарстан нефтьчеләренең хезмәт батырлыгына багышланган Нефть монументы. Ул 1975 елда корылган (скульпторы Б.Д. Фузеев, архитекторы А.В. Печорин, Уфа). Аны әһәмиятле шәһәр артериясе үзәгенә куеп, урынга бәйләү проектын Лениногорскиның талантлы рәссамнары В.С. Агеев һәм Д.К. Садретдинов гамәлгә ашыралар. Һәйкәлнең төп композицион элементы – көмешсыман тутыкмый торган корычтан эшләнгән, стильләштерелгән, ургылып чыгучы нефть фонтаны (биеклеге 28 м). Ул бождрага алынган, аның тышкы өслегендә «кырыс стиль» скульптурасы рухында нефтьчеләрнең монументальләштерелгән хезмәт күренешләре чүкеп төшерелгән барельеф урнашкан. Монументка илтүче юлларга мозаикалы бетон плитә түшәлгән, югарыдагы мәйданчыкка менә торган баскычлар гранит плитәләр белән тышланган. Һәйкәл, идея-сәнгать объекты сыйфатында, һәйкәл буларак кына әһәмиятле түгел, ул Ленин проспектының яңа биек доминантасы һәм ул Җиңүнең 50 еллыгы проспекты белән кисешкән җирдә урнашкан мәйданның үзәгенә әверелде. Ул безнең героик үткәнебезне – Бөек Ватан сугышы геройлары аллеясын, данлы бүгенгебез – нефтьчеләр хезмәтен һәм матур киләчәкне – балалар сәнгать мәктәбе бинасын образлы рәвештә берләштерә кебек. 1981 елда Шашин урамында (элеккеге Куйбышев ур.) геолог, СССРның нефть сәнәгате министры булган, гомумән Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәген үстерүгә күп хезмәт куйган В.Д. Шашинга һәйкәл ачыла. Шул вакытта урамның исеме дә үзгәртелә. Гранит плитәләр белән тышланган тәбәнәк, квадрат рәвешендәге бетон постаментка куелуы сәбәпле скульптура әйләнә-тирә мохит белән органик рәвештә бәйләнә. Анда бетоннан эшләнгән тыныч кына утыручы кеше (ике табигый зурлыкта) фигурасы урнаштырылган (скульпторы В.И. Рогожин, архитектор-проектчылары В.П. Федотов, В.П. Морозов). Һәйкәл янында шәһәр халкы өчен яшеллеккә күмелгән уңайлы ял урыны ясала. Соңрак монумент реконструкцияләнә, әмма ул уңай нәтиҗә бирми: постамент биегрәк итеп эшләнә, фигура алтынсу төскә буяла, болар талантлы скульпторның ниятен юкка чыгара. 1985 елда Советлар Союзы геройларының беренче рәсем галереясыннан соң, Җиңүнең 50 еллыгы урамында 12 геройның танылган оста, атказанган сәнгать эшлеклесе В.И. Рогожин ясаган скульптур бюстлары пәйда була (архитекторы В.П. Федотов). Геройлар аллеясы Җиңүче солдатка куелган һәйкәл, Мәңгелек ут белән башланып, Дан портигы белән тәмамлана. Акрынлап аллеяны кайнар нокталарда хезмәт иткәннәргә һәм локаль конфликтларда катнашучыларга багышланган яңа һәйкәлләр – горельефлар тулыландыра. 2000 елдан аллеяны атказанган нефтьчеләргә багышланган стендлар дәвам итә. Ул Җиңүнең 50 еллыгы проспекты

белән Нефть монументын һәм Геройлар аллеясын тоташтыра. Аллея буйлап нефтьне беренче булып ачучыларның горельефлы бронза портретлары ясалган мемориаль такталар урнаштырылган. Шома мәрмәргә аларның исемнәре зур бронза хәрефләр белән язылган. Шулай итеп, Җиңүнең 50 еллыгы проспекты шәһәрнең иң монументаль урамына әверелде.

Сәнгать чаралары ягыннан төрле булган берничә һәйкәл шәһәрнең барлыкка килүенә багышланган. 1985 елда Шашин урамында шәһәрнең 30 еллыгы уңаеннан Лениногорскига нигез салынуга һәм аның беренче төзүчеләренә багышлап стела урнаштырыла. Ул «Лениногорскига 1955 елның 18 августында нигез салынды» дип язылган символик таш калкып торган мәйданчыкны да колачлый. Стеланың өслеге «кырыс стиль» манерасында шәһәр төзелеше сурәтләнгән төсле мозаика белән капланган (авторлары А. Полухин һәм Лениногорск рәссам-проектчысы В. Шуков җитәкчелегендәге студентлар төркеме). Шәһәрнең барлыкка килүе «Вакыт» истәлекле билгесендә дә чагыла. Бу объект 1998 елда Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Г.А. Иванов (Яр Чаллы) проекты буенча Беренче посёлок урамнары чатында әйләнә буйлап борылышның нәкъ үзәгендә нефтьчеләрнең беренче палаткалары торган җирдә урнаштырылган (Яр буе урамы). Биек металл торбалар, җирдән үсеп чыгып, механик сәгать детальләре урнаштырылган түгәрәк белән төгәлләнәләр, астарак, композиция эчендә – сәгатьнең маятнигы. Стелага «1950 – төзүчеләрнең беренче палаткалары» һәм «18.08.1955 – Лениногорск шәһәре барлыкка килде» дип язылган табличкалар беркетелгән.

Танылган сынчы В.И. Рогожин иҗаты Лениногорск шәһәренең йөзен формалаштыруда мөһим роль уйный. Аның эшләре геройларның образларын үзенчәлекле тудыруы белән аерылып тора. 2000 елда куелган Габдулла Тукай бюсты (архитекторы Ф.Ф. Сәйфуллин) аерым күтәренке-хиссилеге белән аерылып тора. Ул классик балюстрада белән әйләндереп алынган, скверга һәм «Аккош күле» фонтанына карап тора. Ансамбльнең билгеле бер дәрәҗәдә йомыклыгы аерым шигърият рухы тудыра һәм ял итәргә чыккан шәһәр халкын, шигърият сөючеләрне үзенә чакырып тора. Шагыйрьнең туган көнендә шигырь бәйрәме нәкъ менә шунда үткәрелә.

Шәһәрдә күренекле җәмәгать эшлеклеләре, нефтьчеләр, язучылар, музыкантлар һәм рәссамнар хөрмәтенә куелган мемориаль такталар турында да берничә сүз әйтәсе килә. Кызганычка каршы, аларның барысын да сәнгать ягыннан уңышлы дип булмый. Иң тәэсирле һәйкәлләрне атыйк. Шәһәрне яшелләндерү эшенә зур өлеш керткәне өчен, рәхмәт йөзеннән, М.Д. Фоминга багышлап, мәрмәрдән ясалган барельефлы истәлек плитәсен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Ул – Ленин проспектындагы чәчәкләргә күмелгән яшел сквер уртасында. Мактаулы нефтьче, «Бөгелмәнефть» нефть-газ чыгару идарәсе башлыгы, Ленин премиясе лауреаты, шәһәрнең Мактаулы гражданины П.С. Васильевка багышланган мемориаль плитә «Лениногорск-

нефть» нефть-газ чыгару идарәсенең 70 еллыгы уңаеннан тантаналы рәвештә шәһәрнең яңа микрорайонында урнаштырыла. Татарстанның нефть төбәгендә балалар сәнгать белеме мәктәбенә нигез салган М.Х. Хәертдиновка (1924–1983) да мемориаль такта бар. Рәссам портреты төшерелгән һәм югары дәрәҗәдә эшләнеше белән аерылып торган такта (скульпторы М. Гасыймов, Казан) мәктәп бинасына 2014 елда куелган.

1990 еллар азагында һәм 2000 елларда шәһәр мохитен гуманлаштыру белән кызыксыну көчәя. Г. Тукай урамының бер өлешендә (Гагарин урамыннан Ленин проспектына кадәр) ял урыннары, җәяүлеләр өчен зоналар булдырыла. Кече формалар урам киңлеген тутырып, аны камералы һәм кеше өчен уңайлы итәргә тиеш була. Янәшәдәге биналар купшы төсләр кертеп ремонтлана, беренче катлар төрле-төрле тышлыклар белән каплана, ә күпертмә бизәкле өлешләре реставрацияләнә. Шәһәрнең төрле районнарында ял зоналары актив төзелә һәм төзекләндерелә. Еш кына алар инде булган яки торгызыла торган һәйкәлләр тирәсендә барлыкка килә. Мәсәлән, Кутузов урамында 11 нче гимназия белән янәшә торгызылган М. Вахитов һәйкәле янындагы, Ленин проспектында фонтан тирәсендәге җирләр, Беренче посёлокка якын күлләр каскады яңартыла.

Бу вакытта экология мәсьәләләре күтәрелә, әйләнә-тирә мохитне глобаль пычрату проблемасын хәл итү омтылышлары күзәтелә. Табигатьне саклау һәм гомумән кешелекнең киләчәге мәсьәләләре аеруча актуаль яңгыраш ала. Шәһәр масштабында бу проблемага төрле яклап якын киләләр. Әйтик, мәгариф системасында бу планлы рәвештә тәрбия эшеннән башлана. Калдыклар белән җавапсыз эш итүгә каршы юнәлдерелгән, аларны сортларга аерырга, шәһәрдә, аннан читтә яшеллек утыртырга һәм аларны карап үстерергә өндәгән төрле экологик акцияләр оештырыла. Әлеге проблеманы хәл итүдә сәнгатьнең потенциалы зур. Яңа дөньялар һәм концепцияләр тудырып, рәссам галимнәр һәм сәясәтчеләр кебек үк дөньяны үзгәртә ала. Табигать һәм кешенең яңа янәшә яшәү системасын һәм киләчәккә альтернатив сценарийлар тәкъдим итеп, рәссамнар җәмгыятьнең җаваплылыгын арттыра алалар. Мәсәлән, Ярославльдән рәссам һәм скульптор Денис Куликов металлоломнан үзенең «Альтернатив революция» сериясен иҗат иткәндә, «чүп-чарга – икенче тормыш» принцибыннан чыгып эш итә, һәм эшкәртелгән калдыклардан эффектлы арт-объектлар барлыкка килә.

Лениногорскида талантлы проектчы рәссам Евгений Завитневич та шушы юнәлештә эшли. Харьков шәһәре архитектура институтын тәмамлап (1978), туган ягына кайткач, ул 30 ел «Лениногорскнефть» идарәсендә бизәүче рәссам була, интерьерларда һәм шәһәр мохитендә төрле объектларның проектларын эшли. Мәсәлән, шәһәр халкы һәм аның кунаклары арасында бик популяр булган «Маяк» арт-объекты һәм шәһәр күлендәге «Пристань», үзәк аллеядагы фонарьлар һ. б. Балачактан ук фәнни фантастика белән мавыккан Е. Завитневич парал-

лель рәвештә бик күп рәсемнәр ясый: бу – ирекле иллюстрацияләр дә, Г. Уэллс, А. Беляев, А. Азимов, Р. Брэдбери әсәрләре мотивлары буенча оригиналь композицияләр дә. Фантаст рәссамның графикасы күп еллар дәвамында шәһәр һәм республика күләмендәге төрле күргәзмәләрдә тамашачыда зур кызыксыну уята. Рәссамның 60 яшьлек юбилеена Лениногорск һәм Бөгелмәдә аның шәхси күргәзмәләре оештырыла. Һәм бу вакыйга совет космонавтикасының 60 еллыгы белән туры килгәнгә, күргәзмә «60 яшь – нормаль очыш!» дип исемләнә. Рәссамның сүзләренә караганда, яшь вакытта «Техника молодёжи» һәм «Крокодил» журналларын җентекләп өйрәнеп, ул үзенең иҗатына нигез әзерләгән. Һәм чыннан да, аның әсәрләрендә романтик, кайчакта фаҗигалы космос картиналары, хыялдагы фантастик дөнья һәм авторның нечкә ирониясе парадоксаль рәвештә бергә кушыла, алар кайбер детальләрдә һәм иҗади эшчәнлеккә якын килүдә чагыла. Гаҗәеп образларга ия, сәнгать, идеяләр, фактуралар матурлыгы, сәер әйберләр, ташландык металл кисәкләре, коры агач ботаклары белән тулы әйләнә-тирә дөнья рәссам өчен бай чыганак булып тора. Аның фантазиясе дә, сәнгати алымнары да чикләнмәгән: фотосурәт, сынлы сәнгать, графика, скульптура, миниатюр һәм монументаль арт-объектлар (күбесенчә металл һәм агачтан). Е. Завитневичның беренче арт-объекты – робот, ул аны гомере буе иҗатка рухландырган. Рәссам үзенең эше белән әйләнә-тирә мохитне чүпли торган кирәксез-яраксыз әйберләрнең сәнгать әсәренә әверелү мөмкинлеген исбатлый. Лениногорск рәссамнарының Шәһәр көненә һәм башка бәйрәмнәргә багышланган урам күргәзмәләрендә агачтан һәм металлдан ясалган объектлар зур уңыш казана, алар балаларны һәм өлкәннәрне сөендерә, конструкцияләр төзүгә кызыксыну уята. Останың фантазиясе башка сыймый. Шунысы кызык, Е. Завитневич үз эшләрен принципиаль рәвештә исемсез килеш калдыра, ул моны тамашачы фантазиясен чикләргә теләмәве белән аңлата. Оста Рей Брэдбериның «Ком кешесе» хикәясен мисалга китерә, анда башка планета кешесе үзенең тышкы кыяфәтен аны ничек атауларына туры китереп үзгәртә, һәм бөтен көчен куеп, моны булдырмаска тырыша. Миңа биргән интервьюсында Е. Завитневич үзенең туган шәһәренә булган хисләре белән уртаклаша: «Городу не хватает красок, ухоженности, интересных архитектурных решений, замысловатых элементов благоустройства…и многого еще». Рәссам үзенең мөмкинлекләреннән чыгып, шәһәр тирәлеген мондый скульптур арт-объектлар белән баетырга һәм җанландырырга тырыша. Аның металлоломнан ясалган атаклы Робин Гошасы кече энесе белән «Бинго» гаилә кафесына килүчеләрне урамда ук каршы ала һәм «Дөньядагы бердәнбер шикле сәнгать музее Макроскоп»ка – рәссам Е. Завитневичның остаханәсенә озата бара. Бу оригиналь музей тиз арада балалар, яшьләр һәм өлкәннәр арасында зур популярлык казанып, шәһәр кунакларын үзенә җәлеп итә һәм гаҗәпкә калдыра. Әлегә Е. Завитневичның иҗатын аның үзенчәлекле остаханәсе үз диварларына сыйдыра, әмма скульптура

объектлары шәһәр урамнарында да үз урынын табып, паблик-артка әверелә.

Шәһәр – үз мәдәни киңлегендә сәнгатьнең яңа форма, идея һәм концепцияләрен туктаусыз эзли һәм шул ук вакытта традицияләр белән бәйләнешен бер дә өзми торган бердәм организм. Камил шәһәр ансамбленең шәһәр төзелеше процессында катнашучыларның аңлы һәм эзлекле омтылышлары нәтиҗәсе булып торуын тагын бер кат басым ясап әйтергә кирәк, шуңа күрә барлык этапларда да эшкә сакчыл һәм профессиональ мөнәсәбәт тәрбияләү, яңа һәм реставрацияләү проектларын раслаганда, белгечләрне җәлеп итү сорала. Һәр заманның – үз идеаллары. Бер генә нәрсә үзгәрешсез кала: Лениногорск шәһәре табигать дөньясы һәм аның төп байлыгы – нефть белән табигый бәйләнгән, әмма ул кешеләр өчен төзелгән, шуңа күрә анда яшәүче һәркем үзен бәхетле хис итәргә тиеш!

### Әдәбият

*Горюнова Н.М.* Искусство и город. Архитектурные ансамбли Лениногорска. Путеводитель. Лениногорск: Изд. ЛМХПУ, 2009.

Здравствуй, мой добрый город! 40-летию города Лениногорска посвящается. Лениногорск, 1995. С. 23, 26–27, 35.

Искусство стран и народов мира. Архитектура. Живопись. Скульптура. Графика. Декоративное искусство: Краткая художественная энциклопедия / гл. ред.: Б.В. Иогансон. М.: Сов. энцикл., 1971. Т. 3. С. 500–505.

*Петрова А.* Детские фантазии взрослого человека // За нефть. 2022. 28 окт. (№ 20). С. 4.

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Республики Татарстан (1960–1990 гг.). Казань, 2001. 194 с.

*Червонная С.М.* Художники Советской Татарии: (Мастера изобразительного искусства Союза художников ТАССР). Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. С. 93–96, 429–430.

***Горюнова Нина Михайловна,***
*Сәнгать белгечләре ассоциациясенең Татарстан бүлеге әгъзасы,*
*Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасы*

УДК 75.03/04

***Ф.Ш. Джумаева***

# ИБН ФАДЛАН «ЯЗМАЛАР»ЫНДАГЫ СЮЖЕТЛАРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ТАТАРСТАН НӘКЫШЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

Ибн Фадлан – арабский историк и географ, который в X веке в составе дипломатической миссии посетил Волжскую Булгарию и оставил записки об этом путешествии. Особое внимание работе Ибн Фадлана уделяли живописцы. В связи с этим представляет большой интерес рассмотрение полотен татарстанских художников, которые обращаются к интерпретации отдельных аспектов трудов Фадлана, а также его путешествия в целом. В статье будет предпринята попытка комплексного анализа живописных произведений, опирающихся на «Записки» И. Фадлана.

**Ключевые слова:** живопись, Ахмад Ибн Фадлан, Волжская Булгария, исторический жанр, история, картина, художник, искусство, текст «Записок», арабское посольство, сюжеты.

Ibn Fadlan is an Arab historian and geographer who visited Volga Bulgaria in the 10th century as part of a diplomatic mission and left notes about this journey. Painters paid special attention to the work of Ibn Fadlan. In this regard, it is of great interest to consider the paintings of Tatarstan artists who address the interpretation of individual aspects of Fadlan's works, as well as his journey as a whole. The article will attempt a comprehensive analysis of paintings based on I. Fadlan's «Notes».

**Keywords:** painting, Ahmad Ibn Fadlan, Volga Bulgaria, historical genre, history, picture, artist, art, text of «Notes», Arab embassy, plots.

Әхмәд ибн Фадлан – X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе һәм язучысы, Көнчыгыш Европада булган азсанлы сәяхәтчеләрнең берсе. 921–922 елларда Габбасилар хәлифе әл-Моктәдир илчелеге Идел Болгары дәүләтенә килә. Илчелекнең максаты – Көнчыгыш Европа илләрендә ислам динен ныгыту, шулай ук сәяси йогынтыны көчәйтү һәм сәүдә өлкәсендә өстенлекләргә ирешү [Крачковский].

Ибн Фадлан Габбасилар хәлифәсе илчелеге сәркатибе буларак сәяхәт итә. Ил гизүләр озакка сузыла, әмма әлеге делегация үз алдына куелган максатларның күбесенә ирешә алмый. Шуңа да карамастан, Ибн Фадлан угызлар, башкортлар, болгарлар, хәзәрләр һәм руслар белән очрашулары турында тәфсилле юл язмалары алып бара. Соңыннан шулар нигезендә «Язмалар» (гарәпчә «Рисалә») дип исемләнгән үзенчәлекле хисап-сәяхәтнамә төзи. Ибн Фадлан «Язмалар»ы – ул сәяхәтченең төрле халыклар, шул исәптән хәзерге Татарстан территориясендә яшәгән болгарлар белән аралашудан алган тәэсирләре тасвирланган документ [Крачковский]. Аның тексты күп кенә рәссамнарыбызны иҗатка рухландырды.

Китапның беренчел тексты югалган. «Язмалар»ның фрагментлары безнең көннәргә XIII гасыр гарәп энциклопедисты Йакут ар-Руминың «Географик сүзлеге» аша килеп җитә. Шул кыяфәттә әсәр беренче тапкыр 1823 елда рус-немец академигы Христиан Френ[1] тарафыннан алман телендә бастырыла [Ковалевский, 1956]. «Язмалар»ның бүгенге көндә билгеле нөсхәсен Ә. Вәлиди 1923 елда Мөшһәд шәһәрендә (Иран) имам Гали ибн Риза каберлеге янындагы китапханәдә таба. XIII гасыр кулъязмасында башка әсәрләр белән беррәттән «Язмалар» тексты да теркәлгән, кулъязманың йомгак өлеше юк.

1937 елда документның фотокүчермәсен Иран хөкүмәте СССР Фәннәр академиясенә бүләк итә. Аның нигезендә совет Шәрык белгече А.П. Ковалевский әсәрне рус теленә тәрҗемә итә, һәм ул 1939 елда И.Ю. Крачковский редакциясендә басылып чыга. А.П. Ковалевский тәрҗемәсенең эшкәртелгән икенче басмасы 1956 елда дөнья күрә [Ковалевский, 1956].

Татар укучыларына ибн Фадлан турында беренчеләрдән булып мәгърифәтче галим һәм дин эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддин хәбәр итә. Ул XX гасыр башында «Язмалар»ны татар теленә тәрҗемәли. Кулъязма басылып чыкмый һәм Уфада СССР мөселманнары Диния нәзарәте архивында саклана. 1967 елда шушы кулъязма СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты архивына тапшырыла.

Ибн Фадлан «Язмалар»ы – тарихта тирән тамыр җибәргән мәдәниятләр һәм мәгънәләр кисешүен тикшерергә алынган рәссамнар өчен куәтле корал. Әлеге теманың актуальлеге шуның белән билгеләнә дә. Хәзерге заман сәнгате контекстында аларның потенциалын бәяләп бетереп булмый: чөнки үткәндәге тарих өчен генә түгел, ә киләчәктә дә актуаль булып, кеше яшәешенең күптөрлелеге гәүдәләндерелгән әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек бирәләр.

Габделбакый Идрис улы Урманче иҗатын тикшерүчеләргә һәм бәяләүчеләргә аның архивында Әхмәд ибн Фадлан «Язмалар»ының күчермәсе һәм бастыру өчен әзерләнгән татарча тексты саклангандыгы билгеле. Урманче балачактан ук Болгар тарихы белән кызыксына. Ибн Фадланның «Язмалар»ына мөрәҗәгать итеп, ул, беренчеләрдән булып, рәссам «Ибн Фадланның Болгарга килүе» картинасын яза башлый. Үз идеясен тормышка ашыру өчен материаллар эзләгәндә Р. Фәхреддин кулъязмасына юлыга. Әлеге хезмәтнең әһәмиятен бәяләп һәм мәгърифәтче галимнең татар тарих фәнен үстерүгә керткән өлешен күрсәтергә теләп, Б. Урманче аны матбугатка әзерли.

---

[1] Френ Христиан Данилович – немец халкының һәм Россиянең күренекле шәркыятчысы, гарәп теле белгече һәм нумизмат. Казан университеты профессоры (1807–1815), Санкт-Петербург Фәннәр академиясе академигы.

Кызганычка каршы, Б. Урманче әзерләгән текст үзе исән вакытта нәшер ителми, әмма кульязма аның шәхси архивында сакланып кала. 2022 елда, ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан, Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее әлеге кульязманы бастырып чыгара [Приезд Ибн Фадлана..., 2022].

Б. Урманченың «Ибн Фадланның Болгарга килүе» картинасы (1973), шушы «Язмалар»га нигезләнеп, картонга темпера белән язылган. Автор тарафыннан җәмәгать бинасының эскизы буларак уйланылганга күрә, тәэсирлелек ягыннан бу әсәр монументаль сәнгать көченә ия.

Картинаның сюжеты Ибн Фадлан катнашындагы илчелек Болгарга килгән вакытны чагылдыра. «Язмалар» текстында билгеләнгәнчә, 922 елның 12 маенда Идел буе болгарлары яшәгән «славяннар иле»нә Гарәп хәлифәлегеннән илчелек килеп төшә. Килеп җитәргә бер тәүлек ара калганда, илчелекне Алмышның дүрт бие каршы ала. «Алар безне кулларына икмәк, ит, тары тоткан килеш каршыладылар һәм юлны бергә дәвам иттерделәр. Патша безне урдасына ике фәрсах (12 чакрым) ара калганда каршы алды. Безне күрүгә, ул атыннан төште, бөек һәм кодрәтле Аллаһка рәхмәтләр укып, сәҗдә кылды» [Ковалевский, 1956].

Ибн Фадлан хәлифәнең Болгар ханына тапшырырга тиешле хатын укыганчы, үзләре белән алып килгән ике байракны җәеп җибәрәләр, бүләк итеп биреләсе атны иярлиләр, ә Алмышның үзенә дингә ихлас ышанучылар патшасы сараендагы югары дәрәҗәле түрәләр кия торган кара кием, башына чалма кидерәләр. Шуннан соң тантананың үткәрелүе өчен җаваплы Ибн Фадлан хәлифәнең хатын укый. Ибн Фадлан үзе Багдад хәлифәсе әл-Моктәдирнең хатын уку күренешен болай тасвирлый: «Тылмач укылган һәр сүзне тәрҗемә итә барды. Хат укылып беткәч, алар барысы бергә дәррәү күтәрелеп «Аллаһе әкбәр!» дип шундый итеп кычкырдылар, бу аваздан хәтта җир тетрәнеп куйды» [Ковалевский, 1956]. Нәкъ менә шул вакытта Идел Болгары исламны дәүләт дине итеп таный һәм мөселман дөньясының бер өлешенә әверелә.

Бакый Урманченың әлеге вакыйгаларга багышланган картинасы, югарыда әйтелгәнчә, эпик колачлы итеп язылган. Рәссам олуг тантананы, дәрәҗәле илчеләрне, чит ил кунакларын сабыр гына күзәткән тыйнак халыкны гаять оста итеп сурәтли. Биредә һәр элемент әһәмияткә ия, ә ачык, якты төсләрнең мул кулланылуы картинаны шатлыклы, тантаналы итә. Фронталь композиция картинада барган вакыйгаларның тамашачыга якын булуын тоярга булыша.

Бу полотнода, Б. Урманченең 1970 елларга караган башка бик күп монументаль эшләрендәге кебек үк, рәссамның чиста, төрле төсләр катнашмаган артык күзгә ташланмый торган тыныч тоннарга өстенлек бирүе сизелә. Мондый палитра татар халык сәнгатендәге традицион гаммага якын: яшел, зәңгәр, ак төсләр сары, кызгылт-сары, кызыл белән яраша.

Б. Урманченың бизәкләре Шәрык халыклары сәнгатенә борынгыдан ук хас булган, аларда ул декоратив элемент кына түгел, ә сәнгати фикерләү ысулы да. Рәссам татар сәнгатен интерпретацияләгәндә нәкъ менә үзенчәлекле милли бизәкне нигез итеп ала.

Шунысын да әйтергә кирәк: Ибн Фадланның Болгарга килүе һәм болгарларның ислам динен кабул итүе турындагы сюжетка мөрәҗәгать иткән башка татар рәссамнары өчен дә Б. Урманченың әлеге полотносы төп өлге булып тора. Шул вакыттан башлап ул Татарстан рәсем сәнгатендә иң популяр сюжетларның берсенә әверелә.

Әлеге эпизодны чагылдырган иң күренекле һәм якты әсәрләрнең берсе – Казан рәссамы, Б. Урманче исемендәге премия лауреаты Булат Гыйльвановның «Идел Болгарында ислам кабул итү» композициясе (2005).

Бу картинасында рәссам Ибн Фадлан текстын мөмкин кадәр тулы һәм җентекле аңлату өчен вакыйгаларның күпсанлы детальләрен тергезә. Тамашачыга хәлифә әл-Моктәдир тарафыннан Болгар ханы Алмышка язылган хатны Ибн Фадланның укуын күрсәтә.

Композицион яктан картина ике өлештән тора. Уң якта – хатыны, гаскәре, якын даирәсе белән Болгар ханы Алмыш, ә сул якта Ибн Фадлан үзе һәм илчелек вәкилләре сурәтләнгән.

Картина икенчел персонажлар – гаскәриләр, хан даирәсендәгеләр һәм аны озатып йөрүчеләр белән тулыландырылган. Рәссам ерак тарихта калган вакыйганың төрле элементларын җентекләп сурәтләргә омтыла. Тамашачы картинада милли орнамент төшерелгән костюм элементларын, кирәк-ярак детальләрен, үзенчәлекле коралларны күреп ала. Бу, һичшиксез, рәссамның кабатланмас осталыгы һәм таланты турында сөйли. Шул рәвешле, рәссам тарихи вакыйганы бөтен тулылыгында һәм соң дәрәҗәдә ышандырырлык итеп сурәтләп бирә.

Б. Гыйльванов картинасы акварель белән эшләнгән, шуңа күрә үтә күренмәлелек һәм җиңеллек эффекты тудыра (моны бигрәк тә арткы планда урнашкан табигать фонында ачык тоемларга мөмкин). Буяулар күчеше йомшак һәм салмак, бу исә әлеге күренешнең рухи-рухани эчтәлеккә ия булуын чагылдыра. Рәссам Идел Болгары дәүләтендә ислам кабул итү вакыйгасын үзенчәлекле рухилык белән тотырырга омтыла. Әмма шул ук вакытта вакыйгаларга хас динамика да сизелә, бу нисбәттән төсләрнең контрастлы күчешләрен билгеләп үтәргә кирәк. Рәссамның техникасы һәм идеясе, һичшиксез, һәркемне сокландыра, һәм ул хәтта сәнгатьтән шактый ерак торган тамашачының да игътибарыннан читтә калмый.

Әлеге сюжетка мөрәҗәгать иткән тагын бер Казан рәссамы – Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлекләре әгъзасы Рөстәм Хуҗин. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Р. Хуҗинның иҗаты, гомумән алганда, хәзерге заман монументаль сәнгате өчен дә үрнәк.

Рәссамның «922 елда болгарларның ислам динен кабул итүе» картинасы күп фигуралы композиция үрнәге булып тора. Рәссам болгар-

ларның ислам динен кабул итү күренешен бөтен нечкәлекләре белән масштаблы итеп яңарта. Картина үзәгендә – тарихи вакыйганың төп герое Ибн Фадлан. Ул ак киемнән, бу төс пакьлекне символлаштыра һәм образга мәһабәтлек өсти. Төп геройны күпсанлы кешеләр сәламли, алар арасында Алмыш хан үзе дә бар. Композициянең үзенчәлеге шунда ки, Р. Хуҗин төп геройны вертикаль рәвештә сурәтли, әйтерсең ул офык өстеннән күтәрелә, бу аның фигурасын тагын да тантаналырак итә. Әлеге алым тамашачыга да картинада сурәтләнгән халык арасына «кереп», гаять мөһим вакыйганың катнашучысы булу мөмкинлеге бирә.

Әсәр монументаль характерда булуга карамастан, рәссам детальләргә зур игътибар бирә, декор элементларын, картинаның төп геройларының киемнәрен, шулай ук сугышчыларны һәм гади кешеләрне җентекләп сурәтли.

Бу картинада табигать аерым урын алып тора. Рәссам вакыйга барган урынны тәфсилләп тасвирлый. Аеруча аның ачык төсләрдән файдалануын билгеләп үтәргә кирәк. Ачык яшел төстәге үлән тамашачыга язгы табигатьне бөтен тулылыгында тоярга мөмкинлек бирә һәм картинада сурәтләнгән һәр герой һәм бөтен Идел Болгары дәүләте тормышына принципиаль зур яңалык керүгә ишарәли, ә еракка сузылган күк йөзе вакыйгаларның масштаблылыгын билгели. Идел буе Болгарында ислам динен кабул итү вакыйгаларының татар рәссамы тарафыннан мәһабәт итеп аңлатылуын һәм шул рәвешле аның халкыбыз тарихындагы әһәмиятен ассызыклауны да искәртеп үтү зарур.

Болгарларның ислам динен кабул итүе темасына кагылышлы тагын бер картина – Татарстанның халык рәссамы Фәрит Вәлиуллинның «Болгарларның исламны кабул итүе» әсәре. Картина традицион акрил буяу белән ясалган һәм мозаикага эскиз булып тора.

Картинаның горизонталь композициясе гаять зур киңлекне тоярга ярдәм итә һәм полотнода детальләрне бик күпләп урнаштырырга мөмкинлек бирә.

Әсәрдә Ибн Фадлан һәм Алмыш хан (хатыны белән) образлары үзәк урынны алып тора. Композициядә алар зур төркемнең бер өлеше буларак кабул ителә торган башка фигуралар белән әйләндереп алынган. Картина изге китап, гарәп хәрефләре белән язулы байрак кебек ислам атрибутларына бай. Калкулыклар, күк йөзе кебек табигый элементлар картинаның фонын тәшкил итеп, аны тирән эчтәлекле һәм күләмле итеп күрсәтәләр. Ачык һәм куе төсләр вакыйгага тантаналылык өсти һәм шатлыклы яңгыраш бирә.

Әсәр монументаль мозаикага эскиз булганлыктан, автор аны иҗат иткәндә үзенчәлекле манера һәм техника куллана. Полотнода төсләр кушылу һәм нюанс күчешләре юк, болар нәкъ менә монументальлеккә ирешергә мөмкинлек бирә дә.

Әлеге сюжетка Равил Заһидуллин, Фиринат Халиков, Нияз Хаҗиәхмәтов кебек рәссамнар да мөрәҗәгать итә. Аларның һәркайсы

бу тарихи вакыйганы үзенчә гәүдәләндерергә тырыша, әмма барысы да диярлек аның масштаблылыгын, мөһимлеген һәм бөеклеген (нинди эш техникасы һәм манерасы сайлауга карамастан) тапшырырга омтыла.

Татарстан рәссамнары Ибн Фадлан «Язмалары»ндагы башка сюжетларга да мөрәҗәгать иткәннәр. Мәсәлән, рәссам һәм график, каллиграф һәм фотограф, Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлекләре әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, халык рәссамы Рушан Шәмсетдинов үз әсәрләрендә Ибн Фадлан шәхесенә һәм аның сәяхәтенә зур игътибар бирә [Шамсутдинов, 2017]. РСФСРның халык рәссамы Лотфулла Фәттахов хәтта Ибн Фадланның портретын язарга алына [Чернецовы, 1970].

Ибн Фадлан «Язмалар»ы Татарстан территориясендә генә түгел, ә дөньяның башка төбәкләрендә яшәгән рәссамнарны да иҗатка рухландыра. Әйтик, рус һәм поляк рәссамы Генрих Семирадскийның «Похороны знатного руса в Болгаре» картинасын гына алыйк. 1882 елда Генрих Семирадский Мәскәү Тарих музееннан әлеге картинаны язарга заказ ала. 920 еллар башында Идел Болгарында булып, анда сәүдә белән килгән русларны үз күзләре белән күргән һәм аларның йолалары турында кыйммәтле тасвирламалар (атаклы рус баен кол хатын белән бергә көймәдә яндыру турындагы таныклык та шулар исәбендә) калдырган Ибн Фадлан «Язмалар»ы Семирадский өчен әдәби чыганак ролен үти. Рәссам һәр этапта тарихи дөреслекне күзәтүче махсус комиссия белән килешенеп эш итә. Картина 1883 елда әзер була, һәм бүгенге көндә дә Мәскәү Тарих музеенда саклана.

Рәсемнәр сайлаганда, картиналарның интернет челтәрендә урнаштырылган фотосурәтләреннән файдаландык, чөнки аларның сыйфаты яхшырак һәм ачык кулланылышта булулары уңайлы. Кайбер әсәрләрнең төп нөсхәләре Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музеенда, тәкъдим ителгән картиналарның икенче өлеше шәхси коллекцияләрдә һәм авторларның үзләрендә саклана.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Ибн Фадлан «Язмалар»ының татар рәсем сәнгатенең тарихи жанры үсешенә йогынтысы зур була, ул күп кенә рәссамнарга тирән эчтәлекле әсәрләр тудыруга этәргеч бирә. Аларның әсәрләре аша без үткәннәргә күз салабыз, болгарлар һәм башка халыкларның тормышы һәм мәдәнияте турында күбрәк белә алабыз. Моннан тыш, Ибн Фадлан «Язмалар»ындагы сюжетларның татар рәссамнары нәкышендә чагылдырылуы безгә ерак үткәннәрнең мәдәни контекстын һәм аның киләчәген тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Большаков О. Г.* Уточнения к переводу «Записки» Ибн Фадлана. Древнейшие государства Восточной Европы. М.: Вост. лит., 2000. 493 с.

*Крачковский И.Ю.* Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу. Изд-во АН СССР. М., 1939.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков: Изд-во. Харьков. гос. ун-та, 1956. 345 с.

*Ковалевский А.П.* Посольство халифа к царю волжских булгар в 921–922 гг. // Исторические записки. «Хазарский альманах». Т. 13. М.: 2015. 64 с.

Приезд Ибн Фадлана в Булгар. «Записка о путешествии на Волгу» с иллюстрированным материалом и переводом художника, скульптора, полиглота Баки Урманче. Из личного архива Б.И. Урманче / сост., автор вступ. ст. и коммент. З.Г. Мухаметшин; редкол.: Р.М. Нургалеева и др.; ил. Р.Г. Загидуллин. Казань: Гос. музей изобразительных искусств Республики Татарстан – Изд-во «Заман», 2022. 144 с.: ил.

*Чернецовы Г.Г. и Н.Г.* Путешествие по Волге. Рисунки авторов. М.: Мысль. 1970. 43 с.

*Шамсутдинов Р.Г.* Рушан Шамсутдинов: Живопись. Графика. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 120 с.

***Джумаева Фирүзә Шәүкәт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 793.31

***Д.И. Умәров***

# УРТА ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫ ХОРЕОГРАФИК ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Народ сохранял свои традиции в обрядовых праздниках, играх и обычаях, передавая их из поколения в поколение. Фольклорный танец – это пляска, исполняемая группой или в индивидуальном исполнении, при проведении различных обрядов, праздников, вечеров. В фольклорной пляске отражаются все бытовые условия присущие той или иной народности, природно-географические и климатические условия, а так же трудовой процесс и форма хозяйственной жизни человека. В индивидуальной фольклорной пляске каждый исполнитель отражает жизненную ситуацию, подражает повадкам животных, природе, идёт своеобразная импровизация, в свое удовольствие. А коллективная фольклорная пляска интересна только для тех кто в ней участвует, так как исполнители играют для себя, а не на зрителя. Коллективная фольклорная пляска может длиться бесконечно, так же как и игра, в ней нет драматургического построения как в постановочном танце, фольклорная пляска имеет свои определённые фигуры и рисунки.

**Ключевые слова:** хореографический фольклор, этнохореография, пляска и танец, народная художественная культура, культурологический подход, обрядовые и игровые танцы, хороводные танцы.

The advanced people from generation to generation preserved their traditions in ceremonial holidays, games and customs. Folklore dance is a dance performed by a group or individually during various rituals, holidays and evenings. Folklore dance reflects all the living conditions inherent in a particular nationality, geographical and climatic conditions as well as the labor process and the form of human economic life. In an individual folklore dance each performer reflects the life situation, imitates the habits of animals, nature. There is a kind of improvisation for his own pleasure. And the collective folklore dance is interesting only for those who participate in it since the performers play for themselves and not for the audience. A collective folklore dance can last indefinitely just like a game. There is no dramatic construction in it as in a staged dance, folklore dance has its own specific figures and drawings.

**Keywords:** Choreographic folklore, ethnochoreography, dance and dance, folk art culture, cultural approach, ritual and game dances, round dances.

Хореографик фольклор, барыннан да элек, халыкларның нинди географик һәм климат шартларында яшәвенә бәйле. Татарстан – күпмилләтле республика. Милләт вәкилләре көн күргән географик урын һәм көнкүреш шартлары халыкларның фольклор традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен билгели. Татарстан Республикасы Көнчыгыш Европа тигезлегенең көнчыгышында, Иделнең урта агымы буйлап, Үзәк Россия белән Идел Буе тоташкан чиктә урнашкан. Көнбатышта – Чуваш Республикасы, көнчыгышта – Башкортстан Рес-

публикасы, төньяк-көнбатышта – Марий Эл Республикасы, төньякта – Удмурт Республикасы һәм Киров өлкәсе, көньякта – Оренбург, Самара һәм Ульяновск өлкәләре белән чиктәш [https://nazaccent.ru/regions/tatarstan/].

Н.И. Заикин болай дип яза: «Деление России на этнические зоны, определенные к началу XX столетия в этнографии, наиболее полно отражает разнообразие танцевальных традиции и представляется наиболее подходящим для изучения региональных особенностей танца» [Заикин, 2012, с. 10].

Татар хореография фольклорының безнең көннәргә кадәр сакланган үрнәкләре күптөрле һәм уникаль. Гай Хаҗи улы Таһиров 100 татар фольклор биюен өйрәнгән [Тагиров, 1960]. Чынлыкта фольклор биюләренең саны күпкә артык. Совет чорында бию фольклорын өйрәнүчеләр аларны эшкәртү һәм профессиональ сәхнәдә күрсәтү өчен генә язып алганнар. Хәзер исә хореографик фольклорны җентекләп тикшерүгә, аның локаль үзенчәлекләрен ачыклауга, семантикасын анализлауга, биюнең табигатен өйрәнүгә игътибар бирелә. Кызганычка каршы, күп кенә фольклор биюләре бөтенләй югалган, әмма Татарстан Республикасы авылларында фольклор үрнәкләре әле дә сакланып калган. Аларны фольклор ансамбльләре чыгышларында да күреп була.

Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап бүгенге көнгә кадәр безнең тарафтан фольклор биюләрен һәм җырлы-биюле уеннарны яздыру һәм саклау максаты белән Татарстан Республикасының барлык районнарына фольклор экспедицияләре оештырылды.

Мәсәлән, Буа, Чүпрәле һәм Тәтеш районнарында – «Шестяк», «Тәре кисү», «Орчык уены», Апас һәм Кама Тамагы районнарында «Зәлидә уены», «Капма-каршы уен» фольклор биюләре, Кайбыч районында Мәлки керәшеннәренең уникаль орнаменталь әйлән-бәйлән уены яздырып алынды. Мәлки керәшеннәренең биюләре лексикасы ягыннан чуваш фольклорына якын. «Чабата» биюенең төрле интерпретацияләре Яшел Үзән, Кукмара һәм Балтач районнарында яздырылган, аны, нигездә, «Сөрән», «Рекрутка озату» йолалары үтәлгәндә ир-егетләр башкара. Ютазы һәм Баулы районнарында уникаль фольклор уеннары һәм биюләре язып алынды. Биредә калкулыклар башлана, алар акрынлап Урал тауларына күчә, шуңа күрә, Мөслим районы фольклоры Башкортстанныкына якын булган кебек, Ютазы районы халкының фольклоры Урал хореографик фольклорына охшаган. Менделеевск, Алабуга һәм Тукай районнары керәшен татарларының фольклор биюләре удмурт биюе лексикасы белән охшаш. Чирмешән районында «Сербияночка» һәм «Такмак әйтеп бию» элек-электән иң популяр биюләрдән саналган, Нурлат районында үзенчәлекле «Чыштым» биюе, Питрәч районында «Питрәч чабатасы» биюе һ. б. яздырылды.

Җырлы-биюле һәм хәрәкәтле уеннар мишәр татарлары фольклор биюләренең төп төрләрен тәшкил итә. Композиция ягыннан

биюләрнең күбесе «Түгәрәк уен»га (түгәрәккә тезелеп басып, әйләнеп йөри-йөри, күмәкләшеп җырлау һәм бию) хас түгәрәк формасына ия. К.М. Бикбулатов фикеренчә, мишәр татарлары биюләрендәге түгәрәк буйлап хәрәкәт итү, Казан татарлары, керәшен татарлары, Себер һәм Урал Буе татарларыныкы кебек үк, күрәсең, кояш культы белән бәйледер [Бикбулатов, 1999, с. 52]. Биюне башкаручыларның түгәрәк буйлап хәрәкәте тылсымлы характерда булып, кояшка йогынты ясарга һәм яз килүне тизләтергә омтылуны чагылдыра. «Өч адымлы хәрәкәт»тән торган җырлы-биюле уеннар һәм түгәрәк буйлап җырлап әйләнү күп кенә төрки телле халыкларның фольклорында очрый. Рус фольклорында ул уен хороводы (игровой хоровод) дип атала.

А.С. Фомин сүзләренә караганда, уен хороводы мәҗүсилек йолаларының бер өлешен тәшкил иткән, аның төп мәгънәсе тәңреләргә, серле көчләргә табынудан гыйбарәт булып, нәтиҗәдә алар табигатьнең үзендә чагылыш тапкан. Ул болай дип яза: «В Древнем Египте, Ассирии, Вавилоне, Индии примерно 6000 лет назад приносились жертвы богам и в их честь исполнялись хороводные пляски вокруг жертвенника… Синкретизм хоровода способствовал выражению основных мотивов просьбы через позу, ритм, жест, композицию хоровода, слово, напев, ритуальные предметы. Их устойчивые канонизированные формы определяли семантику народной и национальной культуры» [Фомин, 2005]. Әрмән этнохореологы С.С. Лисициан фикеренчә, борынгы заманда түгәрәккә тезелү – әйлән-бәйлән уены магик көчкә ия дип саналган – ул явыз рухларның үтеп керүеннән саклаган [Лисициан, 2005, с. 427].

Вакытлар узу белән йола вакытында башкарыла торган җырлы-биюле уеннар трансформацияләнгән һәм яшьләрнең җырлы-биюле уеннарына әйләнгән.

Җырлы-биюле уен җырны, гади адымнар белән түгәрәк буйлап йөрешне һәм бию хәрәкәтләре элементларын үз эченә ала. Мишәр татарларының җырлы-биюле уенындагы биюләрдә җыр аккомпанементы астында йомык түгәрәк буенча хәрәкәт итәләр һәм я хәрәкәтне күрсәтәләр, я партнёрларын алмашып бииләр.

1. Җырлы-биюле «Әлирән-Гөлирән» уены.

Без яздырган җырлы-биюле «Әлирән-Гөлирән» уенында түгәрәк уртасындагы солист гел алышынып тора. Катнашучыларның саны так, алар кулга-кул тотынып, музыка тактына гади адымнар белән түгәрәк буйлап йөриләр, көй 2/4 үлчәүле. Сан буенча атлап, җырның беренче куплеты башкарыла, солист – түгәрәк уртасында.

Мәсәлән:

*Әлирән -Гөлирән әлиә алә ләйли.* / 2 тапкыр

Кушымта:
*Ямьле су буе, кошлар сайрый җәй буе.* / 2 тапкыр

Кушымта башланганчы солист үзенә кызлар арасыннан пар сайлый һәм, алар, ике куллап тотынышып, өчләтә тыпырдау хәрәкәтен башкарып, түгәрәк эчендә әйләнәләр. Хәзер инде элеккеге солист тарафыннан сайланган пар солист була, һәм әйлән-бәйлән уены шулай бик озак дәвам итәргә мөмкин.

Җырлы-биюле уеннарның күбесендә төп куплет барлык катнашучылар тарафыннан моңлы итеп сузып, биючеләрнең тыныч кына хәрәкәт итүенә туры килә торган уртача темпта, ә кушымталар – кыска һәм тиз-тиз, ләкин шул ук көй материалында җырлана. Моңа охшаш «Аллия, Гөллия» җырлы-биюле уены Җ. Фәйзи төзегән җыентыкта да бар.

2. Җырлы-биюле уенда «Елан биюе».

«Тинә-нә тинә-нә» җыры астында барлык катнашучылар, алдагы җырлы-биюле уендагы кебек, куллар тотышып, әмма солистсыз, җырның беренче куплетын җырлый-җырлый әкрен генә баралар. Кушымтада, түгәрәкне өзеп, ике катнашучы кулларын тоташтырып ясаган капкага узалар, кушымтаның темпын арттырып, куллар тотышып, елан кебек хәрәкәт итәләр, аяклары белән «беренче йөреш»кә охшаган хәрәкәт ясыйлар.

К.М. Бикбулатовта «Елан биюе»нең тасвирламасы да бар: «Вполне вероятно, что в прошлом ассоциация изображения самого змея в пластике танцующих исполнителей, а в дальнейшем и змеевидной фигуры в танце не что иное, как воплощение символа добра и благосостояния» [Бикбулатов, 1999, с. 7–8].

Болгар сәнгатендә дә елан сурәтләре бар. Моннан тыш, X гасырда Болгарда булган Әхмәт ибн Фадланның шаһитлык итүенә карагандa, алар «еланнарны аеруча хөрмәт иткәннәр, үтермәгәннәр һәм зыян салмаганнар» [Фомин, 2005, с. 90].

Җырлы-биюле уеннардан тыш, мишәр татарлары фольклорында төп мизансценалар сызыклар, колонналар рәвешендә булып, ярымтүгәрәк ясап утырып яки басып уйнала торган уеннар да бар. Без яздырып алган һәр уен җыр яки речитатив такмак астында башкарыла. Кайбер биюле уеннар Идел Буе татарларының башка этнографик төркемнәре фольклорында да очрый. Мәсәлән, «Бәрәңгеләр чәчтек без», «Каеш сугып уены» Әстерхан татарлары фольклорында да бар. «Күпер төзү», «Бармак уены» кебекләре Урта Идел Буе татарлары фольклорында да популяр.

Татар биюе үзенә генә хас характерга һәм пластикага ия. Алар бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Теләсә кайсы халыкның хореографик культурасы яшәү урыны һәм көнкүреш шартлары белән билгеләнә. Татар хореографиясендә авыл тормышындагы хезмәт процессларын күрсәткән хәрәкәтләр бик күп: эрләү, чигү, каз йолку, ризык (токмач, бәлеш, сөт әйберләре) әзерләү һ. б. Ирләр башкаруындагы биюләрдә чапкан атка охшарга тырышу, аучылык, умартачылык, кыр эшләре (печән чабу, җир сөрү, чәчү, урып-җыю һ. б.),

итекчелек һөнәре белән бәйле хәрәкәтләр өстенлек итә. Татарларның Кама, Идел, Казансу елгалары буенда төпләнеп яшәүләрен дә билгеләп үтәргә кирәк. Шуңа бәйле рәвештә балык тоту, көймәдә йөрү, боз өстендә кышкы уеннар, ташу вакыты сурәтләнгән биюләр дә бик күп. Шулай да кешенең хезмәт эшчәнлеген нигез итеп алган татар бию сәнгате хезмәтнең гади имитациясе генә түгел, иң элек бию образлы эмоциональ характерга, темпераментка, матурлык идеалына ия. Тормыш-көнкүрештә дә, табигатьтә дә яхшылыкка һәм яманлыкка мөнәсәбәтне билгели. Татар биюләрен аутентик башкаручылар, оста гармунчылар кебек үк, халыкның мәхәббәтен яулый һәм ихтирамын казана. Элек-электән һәр оста биюче, татар халкына хас үзенчәлекләрне саклап, бию хәрәкәтенең искергән элементларын яңаларына алыштырган. Шунысы да игътибарга лаек: һәр аутентик биюченең үз музыканты, гармунчысы булган, ул уйнаганда бию һәм матур хәрәкәтләр башкару уңайлырак тоелган. Туйларда биючегә оста биегәне өчен акча түләгән очракта, ул аны гармунчы белән дә бүлешә торган булган, янәсе, әгәр гармунчы өздереп уйнамаса, ул шулай матур итеп бии алмас иде. Ислам кануннары нигезендә кызларның егетләр белән аралашуы тыелса да, кар эри башлауга, алар калкулыктагы кырга «җыен»га чыкканнар, гармунга кушылып, төрле җырлы-биюле уеннар башкарганнар («Сигезле бию», «Ике кат сигезле бию», «Алтылы бию», «Бишле бию», «Кара-каршы бию», «Бәлеш урлап бию», «Аерым бию», «Кондыра биюе», «Зада уены», «Кукуруз уены», «Мич капкачын сугып такмак әйтү», «Такмаклар әйтеп, аерым бию», «Түгәрәк уен», «Чүпләп уены», «Читән үреш уены»).

Казан татарларының иң популяр биюе – «Әпипә» (кызлар исеме). Әлеге биюне беренче татар балетмейстеры, татар бию мәктәбенә нигез салган Гай Хаҗи улы Таһиров үзенең «100 татарских фольклорных танцев» китабында болай дип тасвирлый: «Один из вариантов происхождения танцевальной песни и танца на мелодию «Әпипә» мне пришлось услышать в 1929 году из уст бывшего потомственного ямщика Салих-бабая, проживающего в районе Сенного базара (ныне улица Парижской Коммуны). Когда он еще был молодым джигитом, отец его любил рассказывать вечерами за чаепитием интересные случаи о виденном, слышанном, а также разные истории из своей жизни. Салих-бабай хорошо помнил, как его отец рассказывал о музыкальном дуете Мафтухи-апы и ее внучки, которые жили в татарской слободе («Яңа бистә»). Они ходили по дворам, распевая песни-частушки, зарабатывая себе на пропитание... Жители татарского квартала города любили своих бродячих артистов Мафтуху-апу и ее юную внучку, плясунью Апипу. Особенно была пленительна и грациозна Апипа. Когда она плясала, ее сравнивали то с белым лебедем, плывущим по зеркальной глади озера, а то и с райской птицей. Поражала пластичность Апипы, изящный поворот головы, сдержанный задор в глазах, грациозность и нежность исполнения танца» [Тагиров, 1988, с. 14].

Шул ук китапта Г. Таһиров ялгыз биюне дә тасвирлап бирә: «...один из участников молодежного вечера пускается в пляс по кругу: выбивая «дроби» перед гармонистом, он снова и снова идет по кругу, показывая сложное мастерство. Заканчивая первый исполнитель выбирает другого любителя и мастера поплясать. Приблизившись к нему, также выбивает дробь, нагнувшись в полупоклоне. Это и приветствие, и вызов – приглашение продолжить танец, принять участие в соревновании. Второго танцора сменяет третий, потом четвертый и так далее, пока не выступят все мастера «аерым бию». Только после этого начинаются массовые танцы. Девушки танцуют мягко, сдержанно, застенчиво, со скрытым кокетством, их движения неширокие скользящие, без больших прыжков. Танец юношей задорный, активный и мужественный, их движения чеканные, изобилуют легкими подскоками и акцентированными притопами. Танцуя, юноша держит себя уверенно, гордо, он напорист в своих движениях» [Тагиров, 1988].

Моннан күренгәнчә, Казан татарлары хореографиясендә җиңел һәм салмак хәрәкәтләр көчле тыпырдау белән яраша. Кызлар башкаруындагы бию хәрәкәтләре лексикасы егетләрнекеннән шактый аерыла, чөнки кызлар биюендә хәрәкәтләр тыйнак, алар бер куллары белән битләрен яулык белән каплап, түбән карап бииләр. Егетләр биюендә хәрәкәтләр көчле һәм темпераментлы, горур кыяфәт һәм күпсанлы сикерешләр ярдәмендә һәркемгә югарыдан карау иярдә утыру гадәтен чагылдыра («Егетләр», «Чалыштыру», «Борма», «Өч почмак» биюләре).

Фольклор бию мәдәниятен тәңгәллек төшенчәсе күзлегеннән өйрәнүгә культурологик якын килүгә таянып, Татарстан Республикасында яшәүче барлык халыкларның этник һәм мәдәни тәңгәллеген тикшерергә, этник территория барлыкка килүнең йола, дин һәм сәнгать контексты белән бәйләнешен күзәтергә, этник һәм мәдәни тәңгәллекне формалаштыруда һәм саклауда традицион бию мәдәниятенең ролен һәм урынын нигезләргә кирәк.

Фольклор биюе дөнья картинасына, мәдәни тәңгәллеккә туры китереп оештырыла, барлыкка килгән урыны (ландшафт) һәм вакыт белән билгеләнә, ул тел константаларын үз эченә ала, табигать һәм цикллылык, тарих һәм үсеш юнәлеше, илаһи (табигатьтән тыш) көчләр һәм тәртип турындагы күзаллауларны чагылдырган ритуал, йола, гореф-гадәт, шулай ук бәйрәмнәр кебек мәдәни формалар аша белдерелә.

**Әдәбият**

*Бикбулатов К.М.* Танцы татар-мишарей. Казань, 1999. 202 с.

*Заикин Н.И.* Этнография и танцевальный фольклор народов России: учебное пособие. 3-е изд. Орел: Орловский гос. ин-т искусств и культуры, 2012. 64 с.

*Лисициан С.С.* Старинные пляски и театральные представления армянского народа. Ереван: Изд-во АН Арм. ССР, 1958. Т. I. 612 с.

*Тагиров Г. Х.* 100 татарских фольклорных танцев. Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. 160 с.

*Тагиров Г.Х.* Татар биюләре = Татарские танцы. Казан: Татар кит. нәшр., 1960. 220 б.

*Фомин А. С.* Танец в системе воспитания и образования. Т. I: Природа, теория и функции танца: Учебное пособие. Новосибирск: Новосибирский полиграфкомбинат, 2005. 624 с.

Интернет ресурс. URL: https://nazaccent.ru/regions/tatarstan/

***Умәров Дәүләт Исмәгыйль улы,***
*культурология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт мәдәният институтының хореография сәнгате кафедрасы укытучысы*

УДК 398

***И.Г. Закирова,***
***Г.Г. Гыйлемҗанова***

## ТАТАР МУЗЫКАСЫ ҺӘМ ФОЛЬКЛОР БЕЛГЕЧЕ ИЛГИЗ КАДЫЙРОВКА 85 ЯШЬ

В декабре 2024 года свой 85-летний юбилей отмечает известный этномузыколог, собиратель татарского фольклора, автор книг по музыкальному фольклору сибирских татар Ильгиз Кадыйров. В статье приводится фрагмент из его будущей книги об экспедициях к сибирским татарам, основанной на воспоминаниях автора.
**Ключевые слова:** Ильгиз Кадыйров, татарская фольклористика, татарское музыкально-поэтическое творчество, наследие сибирских татар.

In December 2024, the famous ethnomusicologist, collector of Tatar folklore, author of books on the musical folklore of the Siberian Tatars Ilgiz Kadyrov celebrates his 85th anniversary. The article contains a fragment from his future book about expeditions to the Siberian Tatars, based on the author's memoirs.
**Keywords:** Ilgiz Kadyrov, Tatar folklore, Tatar musical and poetic creativity, the heritage of the Siberian Tatars.

*Декабрь аенда танылган музыкасы белгече, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илгиз Шәфыйк улы Кадыйров үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп уза.*

Илгиз Кадыйров – гомерен халык музыкасын өйрәнүгә багышлаган кеше. Ул үзе белән болай дип таныштыра: «Мин – Себер татарлары музыкаль-поэтик иҗатын җыючы. 1968–1977 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторында эшләгән дәвердә Омск, Төмән, Новосибирск, Томск һәм Кемерово өлкәләренә фәнни экспедицияләргә барып, 500 дән артык җыр-көйләрне язып алу бәхете миңа насыйп булды».

И.Ш. Кадыйров – кабинет галиме генә түгел. Ул дистәләгән экспедицияләргә чыгып, Себердә яшәүче милләттәшләребезнең музыкаль мирасын туплаган, аларны нотага салып, яңадан халыкка кайтарган кеше. Бүгенге көндә ул – халык музыкасы, бигрәк тә Себер татарлары музыкаль мирасы буенча иң олпат белгечебез.

Галим күпсанлы экспедицияләр вакытында Себердә яшәүче милләттәшләребезнең гасырлар дәвамында җырлаган җырларын, уникаль мирасы булган дастан назымнарын, скрипка сарыннарын магнитофон тасмасына яздыра. Соңрак аларны нотага төшереп, яңадан халыкка кайтара, тикшереп-өйрәнеп, фәнни әйләнешкә кертә. Радио-телевидение һәм газета-журналлар аша, фәнни конференцияләрдә докладлар белән чыгыш ясап, бу уникаль моңнарны популярлаштыру һәм пропагандалау белән шөгыльләнә.

Аның эшчәнлеген немец галиме, академик В.В. Радловныкы белән чагыштыру да урынлы булыр. Әгәр бездә дистәләгән дастаннар турында мәгълүмат бар, аларның текстлары бүгенге көнгә килеп җиткән икән – В.В. Радловка рәхмәтлебез. Шушы ук дастаннарның яңгырашын күзаллыйбыз икән, бу – И.Ш. Кадыйров эшчәнлеге нәтиҗәсе. Татар халкының музыкаль эпик һәм лиро-эпик иҗаты сүз белән музыка берлегендә генә яши ала.

Илгиз Кадыйров соңгы елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән фәнни хезмәттәшлеген яңартып җибәрде. Шушы хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе буларак, экспедицияләр вакытында тупланган халык көйләренең ике җыентыгы дөнья күрде. Аларны саллы кереш мәкаләләр тулыландыра. Илгиз абый бүген дә актив эшли. Ул татар халкының лирик җырлары тупланган китабын тәмамлап килә. Уникаль хезмәт – татар халкының скрипка көйләреннән тупланган җыентык мөхәррирләр кулында. Соңгысы экспедицияләр вакытында тупланган язмаларны тыңларга да мөмкинлек биреп, куар-кодлар белән әзерләнә.

И.Ш. Кадыйровның басмага әзерләнә торган бу хезмәтендә Себернең татарлар яшәгән авыллары, информантлары турында сүз бара, бу язмаларда ул үзенең юлдашларын, бигрәк тә фольклорчы галим Ф.И. Урманчеев белән сәфәрләрен искә төшерә. Әлеге язмалар, бер яктан, фольклорчы хезмәтен күзалларга мөмкинлек бирә. Икенче яктан, милләттәшләребез яшәгән Себер авыллары, Себер информантлары – борынгы җырларны белгән, дастан назымнарын көйләгән кешеләр – китеп барган буын, халык җырлары, фольклорның хәзергә кадәр сакланмаган жанрлары – могамнар, сарыннар һәм назымнар турында мәгълүмат саклый.

2023 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Кемерово өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең рухи мирасын өйрәнү максаты белән комплекслы экспедициядә эшләде. Экспедиция вакытында Юрга районы Кышлау, Сарсаз авылларында И. Кадыйров шушы авылларда язып алган көйләр дә кергән китапларны бүләк иттек, авылдашлары җырларын аудиоязмада тыңлаттык. Халык әби-бабайларының җырларын елый-елый тыңлады.

Илгиз абыйның басмага әзерләнә торган китабыннан Кышлау авылы, анда яшәгән информантлар турындагы өзек тәкъдим итәбез. Аның елъязмалардан һәм истәлекләрдән торган яңа җыентыгы киләче елга укучылар кулына барып җитәр дип өметләнәбез.

### Илгиз Кадыйров. Фольклорчы көндәлегеннән

*25 сентябрь, 1969 ел.*

Яуштәдән көндез чыгып киттек. Нижнийдагы катерга 5 минутка соңга калганмын. Озак көттем икенчесен. Суда бару рәхәт. Киттем такси белән автовокзалга. Машина юк. 17.30 Томск-Бийск поездына утырдым. Юргага төнлә килеп төштем. Гостиницада кундым.

*27 сентябрь.*

Юрга чибәр генә, чиста шәһәр. Көн салкынча. Горкомга барып килдем. Барганда икенче юл белән киткәнмен. Бер шофёр Кышлау юлына китереп куйды. Кышлауның сөт ташучы машинасында матраслар өстендә килдем. Анда яхшы гына квартира таптым.

*27 сентябрь.*

Кичә Гафур бабай белән очрашу турында сөйләшеп куйган идек. Бүген очраштык. Себердә мин язып алган җырчыларның иң-иң өлкәне ул – 87 яшь аңа! Мине бик яхшы каршылады. Янда энесе Шулаяков Сөнгатулла абый (1900 елгы). Бер-берсенең сүзен хуплап, бер-берсенә көч биреп торалар.

Иң беренче итеп Гафур абыйның «Кыз озату җырын» яздырдык.




Китәсең, туганым, ай, китәсең,
Атларга да авыр итәсең.
Атларга да авыр, йатка җиңел,
Әткәң-энкәң ташлапы китәсең.
Өстеңдә лә кигән күлмәгеңне
Керләнсә дә салып җуарсың;
Әткәң берлән энкәң исеңә төшсә,
Аулак җиргә чыгыпы җырларсың.

Мин бу җырны беренче мәртәбә Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Белехте авылында Йосыпова Шәмсенур ападан (1950 елгы) 1968 елның көзендә «Тамчы тама» исеме белән язып алган идем. Шәмсенур апа миңа бу җырның Кемерово өлкәсендәге Кышлау һәм Эскәтем авылларында җырлауларын да әйткән иде. Һәм менә быелгы көзге экспедиция шушы җырны ачыклау өчен махсус рәвештә оештырылды да.

Гафур һәм Сөнгатулла абыйлар миңа бер киңәш бирделәр. Бу җырны күрше Эскәтем авылыннан Сәгыйрь абый Таминдаров яхшы белә икән. Тик ул хәзер …. Казанда яши! Алар миңа Сәгыйрь абыйның адресын бирделәр. Һәм без аның белән күрештек тә.

Гафур абыйның икенче җыры – «Ишек бавы җыры». Бу җырның икенче исеме «Кийәүне кыз куйнына кертү җыры».




Җиңгәләр: Саранланыр чак түгел,
Бир, кияү, комсызланма;
Акча бирми керетмәбез,
Тукта, сабырсызланма.

Бирсәң бир син күп безгә,
Без риза түгел азга.
Йаудыр көмеш-алтын безгә,
Бакыр төрмә кәгазьгә.

Егетләр: Урамнарда үтәргә,
Койман биек сүтәргә.
Җырны озак җырлатмагыз,
Төннәр кыска көтәргә.

Пыяла шкаф эчләрендә
Пешкән алма тәгәри.
Оҗмахтагы хур егете
Булмас кияү кадәре.

Сөнгатулла абыйның репертуары шактый киң: «Хуш, авылым» (С. Сәйдәшев җыры), «Саз» (Г. Тукай сүзләре), «Айбулган Хәлил җыры», «Көй», «Кызны озату җыры», «Хатынымны аердым», «Ак тирмәләр», «Зәйнәбем – Майтабым», «Кама буйлары» *(бу җырны Сәгыйрь абыйга тапшырырга!)*

Гыйззелбанат

Томскийның параходы
Күрмәдем күмелгәнен.
Күтәрелми күңелләрем,
Кыскадыр гомерләрем.

Гыйззелбанат, яулыгың!
Уйнамыйсың да көлмисең,
Әллә йукмы саулыгың?

Я, кем әйтер икән миңа – Илгиз себер татарларына хезмәт итмәде дип!

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Гыйлемҗанова Гөлназ Гыйльфан кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 394

***Л.Ш. Гарипова,***
***Ә.К. Булатова***

# МОРДОВИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНА ФӘННИ СӘФӘР НӘТИҖӘЛӘРЕННӘН

С 27 мая по 7 июня 2024 года Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан была проведена очередная комплексная экспедиция (первая в этом цикле состоялась в прошлом году) в татарские населённые пункты Республики Мордовии. Были исследованы татарские деревни Дубёнского, Кочкуровского, Инсарского, Рузаевского, Кадошкинского, Тербеевского и Зубово-Полянского районов. Полевые исследования проводили учёные-специалисты по фольклористике, диалектологии, археографии, эпиграфике, декоративно-прикладному искусству. Был собран уникальный материал по каждому из направлений, который в настоящее время находится в стадии анализа.

**Ключевые слова:** научная экспедиция, культурное наследие, татарская культура, Республика Мордовия, татарский народ.

On 27.05–07.06.2024 the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan conducted a comprehensive expedition to the Tatar settlements of the Republic of Mordovia. The Tatar villages of Dubensky, Kochkurovsky, Insarsky, Ruzaevsky, Kadoshkinsky, Terbeevsky and Zubovo-Polyansky districts of Mordovia were studied. Field research was conducted by scientists-specialists in folklore studies, dialectology, archeography, epigraphy, decorative and applied arts. Unique material has been collected for each of the areas that are currently under analysis.

**Keywords:** scientific expedition, cultural heritage, Tatar culture, Republic of Mordovia, Tatar people.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, оешкан көненнән башлап, татарлар яшәгән төбәкләргә фәнни экспедицияләр уздыра. Соңгы елларда ул комплекслы рәвештә үтә һәм төбәкне өйрәнүнең тел, фольклор, гамәли сәнгать, музыка, археография, эпиграфика кебек өлкәләрен колачлый, «нәтиҗәдә теге яки бу төбәктә яшәүче татарларның тарихы берьюлы берничә аспектта тикшерелә, бу исә һаман да үсештә-хәрәкәттә булган мәдәни-тарихи мирасыбызның ерак тамырларына тирәнрәк үтеп керүдә гаять әһәмиятле адым булып тора» [Милли-мәдәни мирасыбыз, б. 6].

Мордовия Республикасында алтмышка якын татар авылы теркәлгән. Хәзерге Мордовия җирләрендә төркиләр бик борынгыдан яшәп киләләр, бигрәк тә XVI–XVII гасырларда татарлар әлеге төбәккә күпләп барып урнашалар, бу исә Россия империясенең чик сызыкларын сафка бастыру эшчәнлеге белән дә бәйле.

Институтның экспедицияләр планы нигезендә әлеге төбәктә фәнни-тикшеренү эшләрен өч ел дәвамында алып бару каралды. 2023 елда Мордовия Республикасының 15 торак пункты өйрәнелде (Ләмбрә, Ромодановский районнары). 2024 елның 27 маеннан 7 июненә кадәр Мордовиянең берничә җирлеге – Дубёнка, Кочкурово, Инсар, Кадошкин, Рузаев, Тәрби һәм Зубово-Поляна районнарындагы татар авылларына Институт галимнәре фәнни сәфәргә чыкты. Барлыгы 15 татар авылында эшләдек. 2025 елда да әлеге төбәккә экспедиция каралган.

Билгеле булганча, Мордовиянең татарлар яши торган авылларында рухи хәзинәләрне барлау, туплау узган гасыр урталарыннан ук башлана. Танылган фольклорчы галим Хәмит Ярми (1904–1981) җитәкчелегендә әлеге төбәккә оештырылган фольклор экспедициясендә шактый материал туплана, бүгенге көндә алар Институтның Язма мирас үзәгендә саклана (42 нче коллекция). Узган гасырның 50–80 нче елларында Институт диалектологлары да Мордовия өлкәсендә яшәгән татарлар сөйләшен тирәнтен өйрәнәләр. Алар тарафыннан теркәлгән фактлар «Татар халык сөйләшләре атласы»нда, фәнни мәкаләләрдә беркетелә [Атлас татар..., 1989; Борһанова, 1962 һ. б.].

Бу мәкаләдә Мордовия Республикасының Кочкурово, Инсар, Кадошкин районнарындагы татар авылларына 2024 елдагы сәфәребезнең кайбер нәтиҗәләре белән уртаклашабыз.

Кочкурово районы Татар Пешләсе авылына XVII гасырда нигез салынган, аерым документлардан әлеге җирләрнең 1631 елда Инсар өязе суды тарафыннан Уразай Тәңкәчиев исемле татар кешесенә (морзасына) бирелгән булуы күренә. 1869 елгы «Пенза губернасы торак пунктлары исемлеге»ндә ул 345 хуҗалыктан торган авыл буларак теркәлгән.

Авыл исеменә килгәндә, ул Пишли елгасы атамасыннан алынган. Мукшы телендә *пяше-ляй* – ‘юкәле елга; яр буйларына юкәләр күпләп үсә торган сулык’ мәгънәсендә йөри [Топонимический словарь..., 1987, с. 224]. Янәшәдә генә шулай ук Мордва Пешләсе (Мордовская Пишля) атамасын йөрткән мукшы авылы да бар.

Милли составына килгәндә, кайчандыр саф татар авылы булган Татар Пешләсендә бүген төрле милләт вәкилләре яши. Бу, үз чиратында, торак пунктның район үзәге Рузаевкага һәм Мордовия Республикасы башкаласы Саранскига якын урнашуына да бәйледер.

Татар Пешләсе Мәдәният йортында Туган якны өйрәнү музее эшләп килә. Музей зәвык белән оештырылган, экспонатлар да урынлы һәм системалы урнаштырылган. Авыл китапханәсе дә заманча җиһазландырылган. Биредә китап сөючеләрне кызыксындыру өчен төрле чаралар үткәрелә, шулай ук мәктәп яшендәге балалар һәм яшүсмерләрне җәлеп итүгә дә күп көч куела. Мисал өчен, анимация ясау түгәрәге эшли, безгә балалар тарафыннан Г. Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасы буенча эшләнгән татар телендәге фильм тәкъдим ителде.

Татар Пешләсе авылы – классик язучыбыз Шәриф Камалның (1884–1942) туган авылы. Авыл мәктәбендә язучыга музей булдырылган. Биредә әдипнең тормышын һәм иҗатын яктырткан экспозицияләр белән бергә, авыл тарихына, аның үткәненә кагылышлы бай материал да тупланган.

Мәктәп музее белән танышканнан соң, укучылар һәм укытучылар катнашында оештырылган чарада булдык. Язучы Ш. Камалның тормыш һәм иҗат юлына багышланган кичә бик җылы тәэсир калдырды. Әдипнең «Уяну», «Буранда» һ. б. әсәрләреннән өзекләр искиткеч зур осталык белән башкарылды. Билгеле булганча, язучы скрипкада, мандолинада уйнарга яраткан. Кичәдә бу моментны да онытмаганнар: скрипка тавышы күңелнең иң тирән кылларын да тибрәнергә мәҗбүр итте. Гомумән, һәр чыгыш бик тәэсирле, мәгънәле иде. Әдип иҗаты һәм тормыш юлындагы һәр вакыйга оста итеп тәкъдим ителде. Кызганыч ки, чара күбрәк рус телендә барды.

1957 елда Институт тарафыннан оештырган экспедиция кысаларында Татар Пешләсе авылы да өйрәнелә. Институт галимнәре авыл халкы белән танышалар, мәктәптә очрашу уздыралар. Ул вакытта мәктәп директоры булган Ибраһим Муса улы Ларинның мәктәп турындагы язмасы Институтның Язма мирас үзәгендә саклана: «Татарская деревня “Пешлә” расцвела, повысился материальный уровень жизни населения села: сейчас по улицам села не увидишь избушек, покрытых соломой. Село полностью электрофицировано и радиофицировано. Теперь имеем полную возможность тесной связи с очагом татарской культуры г. Казанью. В 1936 году к моменту открытия семилетней школы насчитывалось 111 учащихся, в 1956–57 учебном году учащихся было 413 человек» [Язма мирас үзәге, 41 колл., 44 сакл. бер].

Төзек, матур Татар Пешләсе авылы мәктәбендә бүгенге көндә мәктәптә 209 укучы белем ала. Мәктәп милли гореф-гадәтләрне саклау, онытмау җәһәтеннән дә күп көч куя. Әйтик, мәктәп ел саен төрле брошюралар чыгара. «Обычаи села Татарская Пишля», «Татарская кухня», «Сабантуй – любимый праздник» кебек кечкенә китапчыкларда Пешлә авылының матур гореф-гадәтләре яктыртыла, бу як өчен генә хас аш-су рецептлары тәкъдим ителә.

Авылда бүгенге көндә 2 мәчет эшли, XX гасыр башында, инкыйлабка кадәр, биредә алты мәчет булган. Шунысы әһәмиятле, Рузаевка районы мәчетләре буенча 2017 елда юлкүрсәткеч нәшер ителгән. «Мусульманские святыни родного края (путеводитель по мечетям Рузаевского муниципального района)» дип аталган бу китапта Пешлә авылының яңа җамигъ мәчетенә нигез салыну, аның төзелү тарихына киң урын бирелә, чөнки ул – Рузаевка районындагы иң зур мәчет, мәйданы 1000 кв.м тәшкил итә. Мәчет тау башында төзелгән. Ул мөфти Тәлгать Таҗетдиннең ярдәме һәм авыл халкының тырышлыгы белән 90 нчы елларда салына башлый, 1995 тә, төзелеп бетмәсә дә, эшен башлый – тирә-якка азан тавышы яңгырата.

Рәсми ачылышы – 2013 елда. Җирле мөселман дини оешмасының рәисе Рәшит Хөсәен улы Торпищев мәчет турында, аның тарихы хакында сөйләде: «30 ел Мәскәү шәһәрендә яшәдем, отставкага чыккач, Пешлә авылына кайттым, әкренләп авылның өлкәннәре белән мәчеткә якынайдым, намазга бастым», – диде ул. Авылда мәчет төзелешенә аның беренче имамы булган Зариф Касыйм улы Сәитов иницитивасы белән керешелә, Илшат Җиһанша улы Демкин, Әнвәр Хәсән улы Сәитов бу эштә башлап йөрүчеләрдән була. Проект әзер булып, мәчет төзү эшенә керешкәнче, әле бик күп урау юллар үтәргә туры килә. Эш җиңел генә бармый. Ләкин ничек кенә булмасын, уртак тырышлык белән мәчет күтәрелә. Р. Торпищев билгеләп үткәнчә, Аллаһ йортын күтәрүдә татарлар гына түгел, башка милләт вәкилләре – рус, мордва һ. б. да бик теләп катнаша. Иң куанычлысы – бүгенге көндә әлеге мәгърур, мәһабәт мәчетнең ишекләре ябылып тормый, халык җомгаларга йөри, бәйрәм көннәрендә исә 300–400 гә якын кеше җыела.

Мәчет борынгы мирасыбызны саклап калуда да зур эш башкарып килә. Без биредә күп кенә гарәп язулы басма китаплар белән таныша алдык. Алар арасында «Мөхәммәдия» (Казан, 1900), «Бәдәвам» (Казан, 1907), «Җәмигъ әр-рөмуз» (Казан, 1905), «Рөәя төш күрү», Хөсәен һәм Мөхәммәдзариф Әмирханнар төзегән «Фәваид» тәфсиренең тулы басмалары, география, табигать белеме, тарих буенча китаплар бар. Р. Торпищев аларны алга таба да туплау һәм шулай ук тиешле шартларда саклауны тәэмин итү буенча эш алып барылачагын ассызыклады.

Татар Пешләсе авылында борынгы мирасыбызга яшьләрнең дә битараф булмавы куандырды. Мәсәлән, Лиана Наил кызы Чавкина бабасыннан калган китаплар белән таныштырды. Алар арасында төрле эчтәлектәге мөнәҗәтләр, догалар язылган кульязма дәфтәр, шагыйрь, фольклорчы, тарихчы Ф. Туйкинның (1887–1938) «Җырлар әхтәрисе», татар әдәбиятының күренекле язучысы Ф. Халидинең (1850–1923) «Залим ачлык испанияле Сәет Яхъя бәянында» драма әсәрләренең тулы басмалары бар.

Рузаевка районындагы Татар Шебдасы, халык телендә Субдач авылы – бер урамлы кечкенә генә авыл. Авыл атамасы Шебдас исемле елга атамасы белән бәйле [Топонимический словарь..., 1987, с. 225], районда шулай ук Рус Шебдасы (Русский Шебдас) авылы да бар. Биредә җәй көне генә бераз җанлану сизелә, ди авыл халкы. Ташландык, караусыз өйләр бик күп, нигезләрне агачлар күмеп бара. 1962 елда Субдачда зур янгын була, кызганычка каршы, авылның күп өлеше, янып бетә, нигезсез калган кешеләр, якындагы башка торак пунктларга күчеп китәргә мәҗбүр була. Табигатьнең гүзәл бер почмагында урнашкан бу авылның киләчәге ничек булыр, авыл яшәрме яки юкка чыккан авыллар исемлегенә керерме? Авылдан әнә шундый уйлар белән чыгып киттек...

Рузаевка районындагы Югары Өрләдем авылында 50 гә якын кеше яши. Авыл Инсар чик сызыгында хезмәт итүче йомышлы та-

тарлар тарафыннан XVII гасырда нигезләнгән дип карала. Ул Үрләй (Урли, Урля, Урлудим, Урледим) елгасы буенда урнашкан, авыл атамасы да шушы гидронимнан алынган, этимологиясенә килгәндә, ул мукшы теленең *ур* 'үр, өр' һәм *ляй* 'елга, чишмә' сүзләреннән килеп чыккан [Топонимический словарь..., 1987, с. 47]. Елганың өске агымын күрсәтү максатыннан югары сүзе өстәлә, халык телендә югары сүзе төшеп калып, ешрак Өрләдем дип кенә әйтелә.

Бу торак пунктта безне авыл мәчетендә каршы алдылар. Клуб мөдире булып эшләгән София Зиннур кызы Морарьга һәм авыл советы рәисе Рифат Рафикъ улы Рахмуковка зур рәхмәтебезне белдерәбез, алар безне һәр йорт саен диярлек йөртеп, эшебез барышында зур ярдәм күрсәттеләр.

Авылда мәчет 1996 елда ачылган. Аны төзүгә чыгышы белән Өрләдем авылыннан Айнулла Камалетдин улы Сәитов (1927–2003) зур ярдәм итә, төп иганәче булып тора. Мәчет салдыру – әтисенең дә васыяте була. Мәчет ачылганнан соң, Зиннур Хөсәен улы Сәитов (1934–2017) аның имамы булып торган. Авылдашлары аны зур хөрмәт белән искә алалар. Кызганычка каршы, бүгенге көндә шундый күркәм бу мәчеткә авыл халкы Ураза, Корбан гаетләре кебек зур бәйрәмнәр уңаеннан гына җыела. Биредә безгә кайбер басма китаплар һәм кулъязмалар белән танышу насыйп булды. Алар арасында «Кыйссасел-әнбия», Коръән китабы, «Әнвәрел-гашыйкыйн» һ. б. китаплар бар. Нурия Хөснетдин кызы Исямова (1940 елгы) Мирасханәгә кулъязма Коръән китабы бүләк итте. Кулъязма тулы түгел, XIX гасыр урталарына карый, каллиграф кулы белән башкарылган. Сүрә башлары һәм аятьләр арасындагы билгеләр кызыл каләм белән язылган. Әлеге табыш Язма мирас үзәгендәге кулъязма Коръәннәр тупламасын тулыландырачак.

Югары Өрләдем белән янәшәдә Түбән Өрләдем – Үгәнә дип исемләнгән татар авылы урнашкан. Бик кечкенә авыл. Әлеге торак пунктта эпиграфика белгече В. Усманов кына тикшеренү алып барып, авыл зиратында сакланып калган ташъязмаларны өйрәнде.

Инсар районындагы Яндавище (Яндовище) да – елдан-ел кечерәя барган авылларның берсе. Бүгенге көндә биредә 160 лап кеше яши. Торак пунктка Россия дәүләтенең көньяк-көнчыгышындагы Атемар-Инсар чик сызыкларында хезмәт иткән йомышлы татарлар тарафыннан XVII гасырның икенче яртысында нигез салынган. Авылның атамасы исә рус телендәге *яндово* диалекталь сүзеннән алынган дип карарга мөмкин, әлеге лексема 'чокыр' мәгънәсендә йөри, чынлыкта да авыл уйсулыкта урнашкан [Топонимический словарь..., 1987, с. 252].

Очрашу авыл клубында булды. Клуб бинасында китапханә дә урнашкан, музей бүлмәсе дә бар. Булганны ничек тә саклап калырга тырышып яши биредә халык. Авыл мәчете, элекке авыл советы бинасын төзекләндереп, 2009 елда ачылган. Имам вазифаларын Равил Абдулла улы Курамшин (1960 елгы) башкара. Кызганычка каршы, бу

авылда да мәчеткә бары бәйрәмнәр уңаеннан гына җыелалар. Халык җомгаларга йөрми. Моны мәчетнең авыл читендәрәк урнашуы белән дә бәйләп аңлаталар. Равил абый Курамшин безне үзендә сакланган китаплар белән таныштырды. Алар арасында гарәп язулы кулъязма китаплар да бар. Китаплар XIX гасыр ахырына карыйлар, сакланышлары әйбәт. Беренчесен Иса авылыннан Галимбик бине Габделгафур Дәүләткилдиев күчереп язган. Әлеге җыентыкның беренче өлешендә фикъһ буенча төп мәгълүматлар, шулай ук хәдисләр тупланган. Язма гарәп телендә кара кара белән язылган. Бүлек һәм хәдис башларын язганда кызыл кара кулланылган, кустодлары бар. Икенче өлешендә исә гарәпчә «Шорут әс-салат» китабының күчермәсе урнаштырылган. Шулай ук кара кара белән язылып, аерым битләрдә текст рамкага алынган, кустодлары да бар. Икенче кулъязма китапның күчерүчесе мәгълүм түгел, китап читендәге язудан күренгәнчә, ул «Исхак бине Мирзагосман Дәүләткилдиевка» бүләк ителгән. Сакланышы уртача, кара кара белән язылган, кустодлар һәм пагинация юк, бит кырларында күп кенә искәрмә һәм аңлатмалар теркәлгән. Күләмле бу китапта төрле аять-хәдисләр, аларның фазыйләтләре бирелә, бөти язу һәм куллану кагыйдәләре төрле таблицалар рәвешендә аңлатыла.

Мордовия Республикасының Кадошкин районында өч татар авылы бар – Иса (Большая Поляна), Насакан-Потьма һәм Латышовка.

Иса авылында бүгенге көндә 300 кеше яши, 9 еллык мәктәбе бар. Авыл тарихы, аның күренекле кешеләре белән безне укытучы Света Шамил кызы Абаева таныштырды: «Авыл тарихы тирәннән башлана – Иса авылы рәсми мәгълүматларда 1603 елда искә алына. Авыл тарихын өйрәнүче төбәк тарихчыбыз да бар – Равил Харисович Казанбаев. Ул безгә, архивларда эшләп, әлеге документны җибәрде. Ул – салым документы, димәк, авылга иртәрәк тә нигез салынган дигән сүз. Октябрь революциясенә кадәр авылда 7 мәчет булган. Ләкин дингә каршы елларда мәчетләр тар-мар ителә. Соңгысы – Күл мәчете, кызганычка каршы, бары нигезе генә бераз беленә, инде күле дә кибеп бара. Авыр елларда да халык шул мәчет урынына килеп дога кылган. Бүгенге мәчетебез шул Күл мәчете урынына якын гына җирдә 2005 елда ачылды. Халык мәчеткә йөри, балаларга да дин дәресләре укытыла».

Иса авылының атамасы елга исеменнән килеп чыккан, биредә Исса елгасы бар.

Иса – халык җырларын оста башкаручы Абдулла Кротов авылы. Шунлыктан экспедициядә катнашучы фольклор белгечләренә авылда тикшеренү алып бару аеруча кызыклы булды.

Билгеле булганча, 1957 елгы экспедиция вакытында Иса авылында яшәүче Абдулла Кротовтан күп кенә җырлар язып алына. Алга таба аның белән хезмәттәшлек дәвам итә, җырчы 1958, 1960 елларда Казанга да чакырыла, шул рәвешле, Институтның Язма мирас үзәгендә уникаль җырлар тупланмасы барлыкка килә.

2009 елда Институт, А. Кротов язмаларын туплап, компакт-диск чыгара, 2010 елда исә, җырчы мирасы тагын бер кат барланып, «Халык җырчысы Абдулла Кротов» дигән китап нәшер ителә [Халык җырчысы..., 2010].

Насакан-Потьма халык телендә Потьма(й) дип кенә йөртелә. Исеменә килгәндә, ул мукшы телендәге потма (потмо) ‘урман куелыгы, урманда яшерен, аулак урын’ сүзеннән килеп чыккан. Насакан атамасы исә Насакин исемле йомышлы татарларга бәйле [Топонимический словарь..., 1987, с. 155].

Авылда даими яшәүче 10 лап кына кеше калган. Шулай да Потьма(й) авылы яңа археографик табышларга бай булды. Адилә Исмәгыйль кызы Дербердеева (1954 елгы) әтисеннән калган китапларны саклый. Әтисе – Иса авылыннан Исмәгыйль Габделҗәлил улы укымышлы нәселдән була. Китаплар арасында күн тышлыклы, төрле төсле кәгазьдә басылган Коръән китабы (1900) бик яхшы сакланган. Китапның бер битендә Исмәгыйль Габделҗәлил углы Капкаев үзенең имзасын да калдырган. Палеографик билгеләре буенча XVIII гасырга караган кулъязма җыентыкта исә татар һәм гарәп телендә иман нигезләре, фарызлар хакында сөйләнә. Кызганычка каршы, кулъязманың сакланышы начар, битләре ертылган, язулары, дым тарту сәбәпле, күп урында юкка чыккан. Текст ачык коңгырт кара белән язылган, кустодлары бар. Болардан тыш, төрле догалар, багышлаулар язылган кулъязма битләр дә сакланып калган.

Потьма авылында Яналеева Нәкыя Абдулла кызында (1941 елгы) гарәп язулы мөнәҗәтләр, бәетләр дәфтәре саклана. Ул 1980 елда Мәрхабә Алдаркина тарафыннан кардәше Әминәгә атап язылган. Мөнәҗәтләрдә иман, ахирәт, үлем темалары калку чагыла, шулай ук яхшы гамәлләр кылып, ахирәт көненә әзерләнү турында, әхлак кыйммәтләренең юкка чыгуына борчылып иҗат ителгән мөнәҗәтләр дә урын алган.

Кадошкино районындагы Латышовка (Латыш) – чагыштырмача зур авылларның берсе. Бүгенге көндә бирердә 700 гә якын кеше яши. 9 еллык мәктәбе бар, кечкенә булса да, музей эшләп килә.

Авыл Потиж елгасы буенда урнашкан, нигез салынуы шулай ук XVII гасырга карый һәм Атемар чик сызыгын саклауда катнашкан, йомышлы татарлардан булган Осташко Латышев исеменә бәйле [Топонимический словарь..., 1987, с. 119].

Латыш авылында безне «Изге нур» ансамбле сәламләде. Әлеге ансамбль 2013 елда Алия Абдулла кызы Кильмаева тарафыннан оештырыла, хәзер исә аны Алия Ибраһим кызы Абушаева җитәкли. Ансамбль халык авыз иҗатын торгызуда, саклап калуда искиткеч зур эш башкара. Безгә тәкъдим ителгән «Чорлар аша килгән татар җыры канат куйсын һәрбер бәйрәмгә» шигаре астында узган концертта да борынгы татар җырлары яңгырады, Абдулла Ибраһим улы Кротовның бай мирасындагы җырларны да онытмадылар.

Латышовка авылы безне археографик табышлар белән дә куандырды. Шундый кыйммәтле табышларның берсе – Әдилә Сөләйман

кызы Вяльшинаның (1937–2023) үз кулы белән язган дәфтәре. Анда күп кенә мөнәҗәт-бәетләр урын алган. Шулай ук бу дәфтәр авыл тарихын язучылар, төбәкне өйрәнүче тарихчылар өчен дә әһәмиятле чыганак булырга лаеклы. Әдилә ханым дәфтәренә берничә ел дәвамында үзе соңгы юлга озаткан кешеләрнең исемнәрен, аларның кушаматларын һәм нинди авырудан вафат булуларын теркәп барган. Тәһлил, зикер әйтү, аларның фазыйләтләре хакында мәгълүмат туплаган. Мөэмин-мөселманның тормыштагы урыны, вазифасы, яшәү мәгънәсе турында уйланулар рәвешендә иҗат ителгән мөнәҗәтләргә дә язмада зур урын бирелә:

Динебезнең кадерен белик,
Иблис артыннан йөремик,
Үзебезнең тәнебезгә
Тәмуг утын теләмик.
Сират күперен кичкәндә
Аягымны тайдырмагыл.
Без – Мөхәммәд өммәтләрен
Җәһәннәмдә яндырмагыл.

Дәфтәрдә «Васыятьнамә» исеме астында мөрәҗәгать, дини өндәмәләр дә урын алган. Гомумән, бу җыентык тарихи чыганак буларак зур әһәмияткә ия.

Латышовка авылында басма китаплардан «Мөхәммәдия»нең тулы басмасы (Казан, 1903), «Намаз хуҗасы», Коръән тәфсирләре, «Хисап кагыйдәләре», Р. Фәхреддиннең «Шәкертлек әдәбе», «Тарихеәнбия», «Мохтасарел-викая», Мөгаллим Лотфи Вафаның «Сөаль вә җаваплы җиңел тәҗвид» (Оренбург, 1913) китаплары табылды. Китап читендә «Рөшди 1 нче сыйныфның шәкертләреннән Әсма бинте Галимбик Самакаева» дигән юлларны укыйбыз. Халисә Хәмзә кызы Фәхретдинова (1958 елгы) гаиләсендә саклаган кулъязма китап әһәмиятле чыганаклардан саналырга хаклы. Иман нигезләре хакындагы кулъязма Мәрҗани мәдрәсәсендә XX гасыр башында Хәсән бине Муса бине Гыйбай әл-Пензави әл-Латыши тарафыннан күчерелгән. Китап күн тышлыкта, сакланышы яхшы, каллиграфик яктан матур, төзек хәрефләр белән язылган. Язмалар төрле төстәге кәгазьдә, төп текст кара кара белән, ә бүлекләрне аеру өчен кызыл каләм кулланылган. Алдагы берничә биттә текст кызыл рамкага алынган. Кустодлары бар, пагинацияләр китерелми.

Рәфыйк Хәлил улы Сюняев (1967 елгы) гаиләсендә кайбер басма китаплар белән бергә аерым кулъязма битләр саклана. Кызганычка каршы, алар нык таушалган. Битләрдә ике багана рәвешендә поэтик текст урнаштырылган, кустодлар юк. Бит читләрендә кайбер искәрмәләр теркәлгән. Гомумән, табылган кульязма хәзинәләр бу төбәк халкының бай рухи тормыш белән яшәвен күрсәтә, кулъязма китап традициясенең бик борынгыдан килүенә дәлил булып тора.

Күрсәтелгән торак пунктларда милләттәшләребез белән очрашып, җирле сөйләш үрнәкләре дә язып алынды, диалектологлар әлеге ареалны узган гасырның 1950–1970 елларында өйрәнгән. Без исә сөйләш үзенчәлекләрен заманча техника ярдәмендә яздырып, татар шивәләренең хәзерге торышын өйрәнүгә нигез булган бай фактик материал тупладык. Торак пунктта яшәүче татарларның сөйләме көнбатыш диалектның ләмбрә сөйләше таралыш ареалына керә дип билгеләнде. Тоташ текстлар һәм аерым лексемаларның бирелеше дә теркәлде.

Шулай ук халык күңелендә сакланып калган халык авыз иҗаты әсәрләре дә барланды, бүген дә халык хәтереннән җуелмаган мөнәҗәт, озын һәм кыска җырлар, бәетләрне язып алдык. Әлеге төбәктә урын алган йола фольклоры да өйрәнелде. Кызганычка каршы, әлеге халык хәзинәсен белүчеләр, хәтердә тотучылар саны хәзер бик аз. Олы яшьтәге апа-абыйлар үзләренең әби-бабаларыннан отып алган халык иҗаты җәүһәрләрен киләчәк буыннарга да җиткерә алсыннар иде. Китапларда урын алган, телевидениедә күрсәтелгән стандарт фольклор күренешләреннән аермалы, үзләренең туган якларында таралган, әби-бабалары, әни-әтиләре тарафыннан башкарылган фольклор үрнәкләре буыннар арасында бәйләныш булдырсын иде, дигән теләктә калабыз.

Экспедиция барышында белгечләребез кул эшләре осталары белән очрашып, аларның эшләнмәләре белән дә танышты. Сандыкларда сакланып калган, элек өй-йорт бизәлешендә кулланылган чигелгән сөлге, тукылган келәмнәр, челтәрләп бәйләнгән пәрдәләр дә чыгарылды. Затлы һәм зәвыклы әлеге кул эшләнмәләре биредә яшәүчеләрнең осталыгын да, нинди һөнәр ияләре булуларын, көнитешләрен дә күрсәтеп тора.

Йомгаклап әйткәндә, әлеге төбәктә татар халкы тарихилыкны саклап, үткәне белән кызыксынып, милләтебезнең гореф-гадәтләрен яшь буынга җиткерү өчен бөтен көчен куеп яши. Сәфәребез фольклор, археография, тел, музыка, гамәли сәнгать белгечләре өчен дә уңышлы һәм файдалы булды. Безне каршы алучыларның, оештыручыларның, авыл халкының җылы мөнәсәбәтен тоеп, ярдәмнәрен күреп эшләү дә сәфәрнең нәтиҗәлелеген бермә-бер арттырды. Аларның һәрберсенә чиксез зур рәхмәтебезне белдерәбез. Шунысы куанычлы: безнең хезмәттәшлек туктамый. Гарәп язулы басмалар, кулъязмалар, һәртөрле борынгы документлар табылса, милләттәшләребез алар белән уртаклашырга ашыга. Алга таба да мирасыбызны бергәләп саклау эше өзелмәс, дәвамлы булыр дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**

Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / науч. ред: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова; сост: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова (I т.), Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыкова, Т.Х. Хайрутдинова (2 т.). Казань, 1989. Прил.: Комментарии к Атласу. Казань, 1989. 300 с.

Атлас татарских народных говоров. URL: https://atlas.antat.ru/ (дата обращения: 30.09.2024).

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

*Борһанова Н.Б.* Татар теленең Мордва АССР территориясендә таралган сөйләшләре турында // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 93–124.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Арча. Казан, 2017. 369 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унбишенче китап).

Топонимический словарь Мордовской АССР: названия населенных пунктов / сост. И.К. Инжеватов. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 1987. 263 с.

Халык җырчысы Абдулла Кротов: мәкаләләр, интервьюлар, истәлекләр, җыр текстлары. Казан, 2010. 180 б.

***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.09

*И.С. Насипов*

# МӘШҺҮР ГАЛИМ, КҮРЕНЕКЛЕ ЯЗУЧЫ ҺӘМ ОЛУГ ШӘХЕС

## *(С.Ш. Поварисовның тууына 100 ел тулу уңаеннан)*

В статье рассматриваются этапы жизни, научная и творческая деятельность Суфияна Шамсутдиновича Поварисова. Также раскрываются некоторые его человеческие качества. Материал написан в связи со 100-летием со дня рождения известного учёного и народного писателя Башкортостана, участника Великой Отчественной войны. Он прошёл сложный, но славный жизненный путь. Детство и юность сельского мальчика были трудными. Совсем молодым он встал на защиту Родины от немецко-фашистстких захватщиков. Прошёл героческий путь миномётчика от Курской дуги до Дрездена, принял участие в освобождении Украины, Польши, Венгрии, Чехославакии, Германии. После войны учился, был учителем, журналистом, учёным и писателем, стал доктором филологических наук, профессором. До последних дней своей жизни усердно трудился, активно занимался наукой и творчеством. Общественность Башкортостана и Татарстана достойно отметила юбилей славного сына своего народа.

**Ключевые слова:** Суфиян Поварисов, ветеран войны, педагог, учёный, журналист, писатель.

The article examines the stages of life, scientific and creative activity of Sufiyan Shamsutdinovich Povarisov. Some of his human qualities are also revealed. The material was written in connection with the 100th anniversary of the birth of a participant in the Great Patriotic War, a famous scientist and national writer of Bashkortostan. He went through a difficult but glorious life path. A difficult childhood and youth of a rural boy, very young he stood up for the defense of the Motherland from the Nazi invaders. He passed the heroic path of a mortar man from the Kursk Bulge to Dresden, took part in the liberation of Ukraine, Poland, Hungary, Czechoslovakia, and Germany. After the war he studied, was a teacher, journalist, scientist and writer, became a doctor of philology, professor. Until the last days of his life he worked hard, actively engaged in science and creativity. The public of Bashkortostan and Tatarstan worthily celebrated the anniversary of the glorious son of their people.

**Keywords:** Sufiyan Povarisov, war veteran, teacher, scientist, journalist, writer.

Татар халкының күренекле улы – филология фәннәре докторы, профессор, Башкортстанның халык язучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны Суфиян Шәмсетдин улы Поварисовка 2024 елның 29 августында 100 яшь тулган булыр иде.

С.Ш. Поварисов 1924 елда Башкорт АССРның Илеш районы Тыпый авылында дөньяга килә. Туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, колхозда эшли. Чыгышы руханилардан булганлыктан, 1 яшьтән ятим калган малайга тормышның ачысын-төчесен бик иртә татырга туры килә. Мал-мөлкәте тартып алынган, йорт-җиреннән урамга куылган биш балалы гаиләгә көн күрү җиңел булмый. Тамак

туйдыру, исән калган туганнарын кайгырту аны Себердә тимер юл төзелешендә эшләргә дә мәҗбүр итә.

Бөек Ватан сугышы барышында, Суфиян Поварисов 1942 елның августында, Кызыл Армия сафларына алына һәм фронтка җибәрелә. Курск дугасыннан Дрезденга кадәр 469 нчы полкның миномёт расчёты командиры вазифасында данлыклы хәрби юл үтә. Украина, Польша, Венгрия, Чехославакия, Германияне азат итүдә катнаша. Күп орден һәм медальләр белән бүләкләнә, батырлыклары өчен 21 тапкыр Югары Баш командующийның мактавына лаек була. Сугыштан соң Венгриядә хезмәт итә. Үзлегеннән мажар телен үзләштерә, еш кына тәрҗемәче вазифасын да башкарырга туры килә аңа. 1947 елның мартында армиядән демобилизацияләнә.

С. Поварисов сугыштан соң туган авылына кайта. Берничә тапкыр хәрби хезмәтен армия сафларында дәвам итәргә, һичьюгы – военкоматта эшләргә чакырылуга кармастан, фронтташ дуслары белән Урта Азия якларына чыгып китә. Башта бер ел Кыргызстанда балалар укыта, аннан Үзбәкстанда урта мәктәптә хәрби җитәкче булып эшли. Үзлегеннән укып, 10 сыйныфны гел яхшы билгеләргә тәмамлый. Укыту осталыгы серләрен үзләштерә, дидактика һәм педагогика нигезләре белән таныша.

1951 елда Казан дәүләт педагогика институты тарих-филология факультетының татар бүлегенә укырга керә. Аны кызыл дипломга тәмамлагач, 1955 елдан Татарстан АССРның Актаныш районы Бурсык авылы җидееллык мәктәбендә өч ел директор булып эшли. 1958 елда Башкортстанга кайта, һәм «Кызыл таң» газетасында әдәби хезмәткәр вазифасын башкара. 1960 елдан башлап, гомеренең соңгы көненә кадәр Башкорт дәүләт университетында эшли: ассистенттан профессорга кадәр хезмәт юлы үтә.

Суфиян Поварисов фәнни һәм иҗади эш белән студент елларында ук җитди рәвештә шөгыльләнә башласа да, аңа кадәр үк каләм тибрәтүе дә билгеле. Аның беренче иҗат тәҗрибәсе фронт елларына туры килә, хезмәттәшләренең һәм үзенең батырлыклары турында хәбәрләре, хәрби корреспондентлар тарафыннан редакцияләнеп, фронт газеталарында басылып тора. Урта Азия мәктәпләрендә укытканда «Комсомолец Узбекистана» газетасы белән дә хезмәттәшлек итә. Әдип кайда гына булса да, тормышның бар нечкәлекләрен өйрәнә, халык тормышындагы кайгы-шатлыкларны күңеле аша үткәрә. Киләчәктә болар барысы да аның төрле әсәрләрендәге вакыйгаларда, геройларның шөгыль-характерларында чагылыш таба. Аның фәнни тикшеренү нәтиҗәләре дә әдәби әсәрләренең иҗадисәнгатьчә камиллегенә уңай йогынты ясый. Суфиян Шәмсетдин улы – фән өлкәсендә һәм әдәбиятның төрле жанрларында бердәй югарылыкта һәм нәтиҗәле иҗат итүчеләрнең берсе. Шул ук вакытта аның укытучылык хезмәте һәм педагогик осталыгы аерым игътибарга һәм ихтирамга лаек.

Суфиян Поварисов – күркәм кешелек сыйфатларына да ия шәхес. Ул башкаларның шатлыгына чын күңелдән куана, ялгышларын эчкерсез гафу итә, кимчелекләренә ачына, абынганга кул да суза белде. Үз мәнфәгатьләрен башкаларныкыннан бервакытта да өстен куймый, авырлыкларга зарланмый иде.

Ата-ана тәрбиясе дә бу асыл сыйфатларны булдыруга үз өлешен керткәндер һәм нәсел җепләре дә йогынтысыз калмагандыр. Аның нәселе әнисе Әсма яклап Илеш районы Иске Күктау авылының күренекле шәхесе Локман хәзрәткә тоташа, әтисе Шәмсетдин шул районның Тыпый авылы мулласы була.

Суфиян Поварисов әдәбиятның төрле жанрларында уңышлы иҗат итә. Аның әсәрләренә тематик төрлелек хас. Гадәти тормыштан алынган геройлары безнең арада яши. Алар дәһшәтле сугыш елларында – солдат, тыныч тормышта – тырыш эшче, фидакяр укытучы һ. б. да гәүдәләнә. Геройларны ачуда тирән психологик күңел кичерешләре урын ала, шатлыклы-аянычлы хәл-вакыйгалар оста сурәтләнә. Әйтергә кирәк, әдипнең әсәрләре кайсы телдә генә язылса да, башкорт һәм татар укучысы аларны бердәй яратып кабул итә, көтеп ала һәм кызыксынып укып бара.

С. Поварисов шигърият өлкәсендә дә үз урынын таба. Журналист буларак та танылa,тәрҗемәче булып та хезмәт куя. Заман герое – җир кешесенең көндәлек тормышын яктырткан, рухи дөньясын бар нечкәлекләре белән ачкан ялкынлы очерклары һәм публицистик язмалары аны сәләтле әдип буларак таныта. «Бәхет турында легенда» китабы Суфиян Поварисов иҗатында үзенчәлекле урын алып тора, аның сәнгатьчә эшләнеше дә, композицион бирелеше дә игътибарга лаек.

Әдипнең драма әсәрләреннән «Кәрлә йолдыз», «Туй бүләге», «Авылымның алсу таңнары», «Вәгъдә», «Яңа көй», «Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел», «Кояш чыккандай булды», «Яхшы сүз – җан азыгы» һ. б. республика театрлары сәхнәләрендә уңышлы куела, күпмилләтле тамашачы күңеленә хуш килә. Үзешчән сәнгать коллективлары, укытучы һәм укучылар сәхнәләштергән әсәрләр халык арасында аеруча популярлык казана.

Язучы буларак Суфиян Поварисов аеруча проза әсәрләре белән танылa. Хикәя, повесть һәм роман жанрларында иҗат иткән әдип үз укучысына үзенчәлекле әсәрләр бүләк итте: «Яратам сине тормыш», «Сөмбел», «Алтын йолдызлы Ләйлә», «Ышанам сиңа», «Яшьлек еллары», «Биш партизан», «Ялгызлык» һ. б. хикәя, повестьлары; «Язмыш корбаннары», «Ут эчендәге мәхәббәт» кебек зур күләмле романнары. Гомеренең соңгы көннәрендә ул укытучылар тормышына багышланган чираттагы әсәрен – «Гәүһәр күгәрченнәре» романдилогиясен тәмамлый. Ул укытучы тормышын һәм эшчәнлеген гарәп чүлләрендәге һәүһәр асылташларын чүпләүче күгәрченнәргә тиңләп сурәтли.

Күренекле татар галиме, дәүләт эшлеклесе һәм язучы Г. Ибраһимовның тормышы, әдәби һәм гыйльми казанышлары Суфиян Поварисовның әдәби һәм фәнни эшчәнлегендә аерым урын били. Аның «Пәйгамбәр таңы» трилогиясе («Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» романнары) әдәбият тарихында зур вакыйга булды. Алар әдип иҗатына тиешле бәя бирүгә дә этәргеч ясады – Суфиян Поварисов Башкортстанның халык язучысы исеменә лаек булды. Аны Г. Тукай премиясенә тәкъдим итү дә шушы трилогиягә бәйле иде.

Суфиян Поварисов Г. Ибраһимовның фәнни хезмәтләрен өйрәнә. Татар стилистикасы формалашуның зур бер чорын ул Г. Ибраһимов эшчәнлеген бәяләү аша яктырта. Академик М.З. Зәкиев җитәкчелегендә язылган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре дә, татар стилистикасы буенча күпсанлы хезмәтләре дә күренекле әдипнең иҗат осталыгын өйрәнү белән бәйле. Әлеге эшчәнлеге өчен Суфиян Поварисов Г. Ибраһимов исемендәге премиягә лаек була.

Суфиян Поварисовның тел һәм әдәбиятка бәйле стилистиканы татар тел белемендә мөстәкыйль лингвистик тармак итеп үстерүгә өлеше зур булды. Галимнең теоретик, шул ук вакытта гамәли әһәмияткә ия «Сүз һәм сәнгатьле сөйләм», «Татар теленең практик стилистикасы», «Тел – күңел көзгесе», «Роль Г. Ибрагимова в развитии татарского литературного языка», «Г. Ибрагимов поэтикасында фразеология», «Г. Тукай поэтикасында чагыштырулар» һ. б. фәнни хезмәтләре аның зур казанышы булып тора. Гомеренең соңгы елларында гына да ул берничә монографик хезмәт яза – алар арасында «Проблемы изучения языка художественных произведений», «Г. Ибрагимов – величайший мастер художественного слова» кебекләре дә бар. Аның нәтиҗәләре төрки телләр стилистикасын өйрәнү өчен дә нигез булды, гомумтөрки стилистик мөмкинлекләрне ачыклауга зур йогынты ясады [Насипов, 2014, с. 14–18].

Гомумән алганда, Суфиян Поварисовның гыйльми эшчәнлеге дәүләт тарафыннан зур бәяләнде. Ул Россия Федерациясе югары белеменең Мактаулы хезмәткәре, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе кебек мактаулы исемнәргә лаек булды.

Ул яшь галимнәр әзерләүгә дә зур өлеш кертте. Аның шәкертләре урта һәм югары мәктәпләрдә уңышлы укыта, фән белән шөгыльләнә. Әйтик, аның җитәкчелегендә Раушания Гәрәева, Рәзил Миргалеев, Гөлназ Габбасова, Алисә Камалова, Зәбирә Кәримова кандидатлык диссертацияләрен уңышлы якладылар, алар нигезендә монографияләр һәм күпсанлы уку-укыту әсбаплары бастырдылар [Габбасова, 2002; Гареева, 2001; Камалова, 2005; Каримова, 2008; Миргалеев, 2002].

Суфиян Поварисов Башкортстан Республикасының иҗтимагый тормышында да актив катнаша. Әдәбият, сәнгать өлкәсен аеруча игътибар үзәгендә тота. Замандаш әдипләрнең казанышларына тәнкыйди караш аның күзәтүләрендә объектив реальләште. Күренекле язу-

чылар белән беррәттән, яшьләр иҗатын да читтә калдырмады. Бу яктан караганда, яшь буын тәрбияләүгә, заман кешесен формалаштыруга ул зур көч салды. Югары уку йорты укытучысы вазифасын да тырышып башкарды. Башкорт дәүләт университетында хәзерге татар әдәби теле морфологиясе, татар теленең стилистикасы кебек фәннәр укытты, гамәли дәресләр алып барды һәм курс, диплом эшләренә җитәкчелек итте. Әйтергә кирәк, күпчелек предметларны һәм махсус курсларны ул үзе башлап язды һәм укытты, бик күп укыту-методик әсбаплар бастырды. Мәсәлән, татар әдәби теле тарихы һәм практик стилистика курсларын ул үзенең фәнни эзләнү нәтиҗәләренә таянып төзеде.

Укытудан тыш, Суфиян Поварисов тәрбия эше белән дә күңел биреп шөгыльләнде. Студентларның «Тел чишмәсе» гыйльми-иҗат түгәрәге аша гына да ул күпме яшьләргә туган тел серләрен ачты. Суфиян Шәмсетдин улы республиканың башка уку йортларындагы татар бүлекләрен төзүдә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләүдә актив катнашты. Озак еллар М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетында татар бүлегендә укытты.

Суфиян Поварисов кебек күренекле шәхесләрнең булуы куанычлы, гомеренең соңгы көненә чаклы актив эшчәнлек алып баруы да күпләр өчен үрнәк. Республиканың күпсанлы иҗтимагый оешмалары эшчәнлегендә катнашып, ул шулай ук бик әһәмиятле эш башкарды. Мәктәп балалары белән дә даими очрашып торды. Аның бу эшчәнлеге бүген дә тиешенчә бәяләп бетерелмәгән әле [Насипов, 2014, с. 60–62; Насипов, Сунагатуллина, 2014, б. 216–219].

Башкортстан Республикасы киң җәмәгатьчелеге Суфиян Поварисовның тууына 100 ел тулуга багышлап матур чаралар оештырды. Тантаналар аның туган ягы – Илеш районында ел дәвамында барды. Туган авылы Тыпыйда һәм район үзәге Югары Яркәйдә мәшһүр якташларына багышлап тантаналы кичәләр узды [Исламова, 2024]. Аларда Башкортстанның һәм Татарстанның күренекле шәхесләре, галимнәр, язучылар, дәүләт хезмәткәрләре һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашты. «Кызыл таң» республика газетасы һәм «Маяк» район газетасы иҗади конкурслар оештырдылар, аңа багышланган материалларны даими рәвештә бастырып килделәр [Мирзаянова, 2024]. Галим һәм педагог озак еллар хезмәт куйган Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы аңа багышлап фәнни-гамәли конференция үткәрде. Киң җәмәгатчелек катнашында Башкортстан Республикасы хөкүмәте Суфиян Поварисов 1978–2016 елларда яшәгән йорт диварына элмә такта урнаштырды [В Уфе увековечили...]. Халык язучысы, галим һәм легендар шәхеснең тормышы, фәнни эшчәнлеге һәм иҗаты турында туганнары, якыннары, хезмәттәшләре, якташлары, гомумән, аны яхшы белгән шәхесләрнең истәлекләре, мәкаләләр, әңгәмәләр, аңа багышланган шигырьләр һәм язмалар, фотосурәтләр тупланган китап басылып чыкты [Суфиян Поварисов..., 2024].

**Әдәбият**

В Уфе увековечили память народного писателя Башкирии Суфияна Поварисова // Башинформ. 2024. 27 августа / https://www.bashinform.ru/news/culture/2024-08-27/v-ufe-uvekovechili-pamyat-narodnogo-pisatelya-bashkirii-sufiyana-povarisova-3900716 (дата обращения: 04.10.2024).

*Габбасова Г.З.* Средства выражения экспрессивности в татарском литературном языке: (На материале имен существительных и прилагательных): автореф. дис... канд. филол. наук. Уфа, 2002. 26 с.

*Гареева Р.Р.* Лексико-стилистические проблемы творчества Ильдара Юзеева: автореф. дис... канд. филол. наук. Уфа, 2001. 23 с.

*Исламова З.* Ак каенлы Илешем // Кызыл таң. 2024. 28 август / https://kiziltan.ru/articles/kultura/2024-08-28/ak-kaenly-ileshem-3902653

*Камалова А.Ф.* Стилистические функции глагольных фразеологических единиц в современном татарском литературном языке: автореф. дис... канд. филол. наук. Казань: 2005. 24 с.

*Каримова З.С.* Поэтика фразеологизмов Аяза Гилязова: автореф. дис... канд. филол. наук. Уфа, 2008. 23 с.

*Миргалеев Р.М.* Парные слова в татарском языке: Лексико-семантический и стилистический аспекты: автореф. дис... канд. филол. наук. Уфа, 2002. 21 с.

*Мирзаянова Г.* Илеш илчесе булды // Маяк. 2024. 17 март.

*Насипов И.С.* Ватан солдаты һәм мәшһүр галим (С.Ш. Поварисовның 90 яшенә // Солдат Родины и известный ученый (К 90-летию С.Ш. Поварисова) // Учитель Башкортостана. 2014. № 8. С. 60–62.

*Насипов И.С.* Суфиян Поварисов: мәшһүр галимнең фәнни казанышлары // Актуальные проблемы современной татарской филологии: Сб. статей Всероссийской научно-практической конференции (г. Уфа, 12 декабря 2014 г.) / Отв. ред. И.Ф. Зарипова. Уфа: РИЦ БашГУ, 2014. С. 14–18.

*Насипов И.С., Сунагатуллина З.Х.* С. Поварисов – халкыбызның олуг шәхесе, мәшһүр галиме һәм күренекле язучысы //Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: материалы V Международной научно-практической конференции (Казань, 19–22 ноября 2014 г.) / Под общ. ред. проф. Р.Р. Замалетдинова. Казань: Отечество, 2014. С. 216–219.

Суфиян Поварисов – яугир, ғалим, яҙыусы: иҫтәлектәр, мәҡәләләр, шиғырҙар / төҙ. Г.Т. Сәлимова, И.С. Насипов. Өфө: Китап, 2024. 160 б.

***Насипов Илшат Сәхиятулла улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының*
*татар теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры*

УДК 82-1(=512.145)

***Ф.И. Габидуллина***

# ГАДИЛЕК ҺӘМ ГАЛИМЛЕК ҮРНӘГЕ

## *(Ә.М. Закирҗановның 65 яшьлек юбилее уңаеннан)*

В статье освещаются основные направления научно-исследовательской и методической деятельности татарского литературоведа, методиста А.М. Закирзянова. Подробно описана его биография, жизненный путь, приведший его в мир науки. Основное внимание в статье уделяется деятельности учёного в области татарского литературоведения, актуальности трудов, научной новизне и определяется значимость его деятельности в этой области.

**Ключевые слова:** татарское литературоведение, методика, А.М. Закирзянов, история и теория литературы, литературная критика.

The article highlights the main directions of scientific research and methodological activities of the Tatar literary critic, methodologist A.M. Zakirzyanov. His biography and the life path that led him to the world of science are described in detail. The main attention in the article is paid to the scientist's activities in the field of Tatar literary studies, the relevance of his works, scientific novelty and the importance of his activities in this field is determined.

**Keywords:** Tatar literary criticism, methodology, A.M. Zakirzyanov, history and theory of literature, literary criticism.

Татар халкының тирән мәгънәле әйтеме бар: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер». Бу көннәрдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Әлфәт Мәгъсүмҗан улы Закирҗанов кебекләр хакында уйлаганда нәкъ шул фикергә киләсең. Әлеге шәхес үзенең ярдәмчеллеге, якты йөзе, тәмле теле, кешелеклелеге һәм ихласлыгы белән һәркемне җәлеп итә. Ә инде якыннан аралаша башлагач, аның тирән белемле, кызыксынучан, игътибарлы һәм ихтирамлы, үз-үзенә таләпчән, туры сүзле фикердәш булуына инанасың. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Мәгъсүмҗан улын киң җәмәгатьчелек әдәбият галиме, тел һәм әдәбият укытучыларының якын дусты, киңәшчесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, татар сәнгате белән даими кызыксынып баручы зыялы зат, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Язучылар берлегенең Җ. Вәлиди (2010), Ш. Маннур (2019) исемендәге премияләре лауреаты буларак белә. Әлеге мактаулы исемнәргә ирешкәнче, ул гомер юлының шактый каршылыклы сукмакларыннан атлый.

Әлфәт Закирҗанов 1959 елның 7 октябрендә Мамадыш районы Югары Яке авылында туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә алганнан соң, күршедәге Кече Кирмәндә (бу авыл татар әдәбиятына Ринат Мөхәммәдиев, Рафаил Газизов, Вәрис

Миңнегалиевләрне бирә) сигезьеллык, Урта Кирмәндә (хәзер эзтабар язучы Шаһинур Мостафин исемен йөртә) урта мәктәпне тәмамлый. Кешенең язмышы алдан язылып куелган дисәләр дә, тормыш үзенең үзгәрешләрен кертә икән шул. Яшьтән спорт яратып, күрше авылларга яз-көз велосипедта һәм җәяү, кышын чаңгыда йөреп шактый ныгыган егет чаңгы спорты буенча район мәктәпләре укучылары арасында өч тапкыр җиңүче була, авыл районнары арасында республикада ике тапкыр призлы урын яулый. Әлеге уңышларга нигезләнеп, үзенең киләчәген физик тәрбия, спорт белән бәйләргә уйлый һәм Казандагы физкультура институтына (филиал) юл тота. Әмма конкурстан уза алмыйча, кире әйләнеп кайта. Сәер яңгыраса да, бу урында «бәхеткә» дип әйтәсе килә. Укырга кергән булса, аның бик яхшы тренер булуына шикләнмибез, әмма татар әдәбияты фәне бер галимен югалткан булыр иде. Алдагы ике елын ул Түбән Кама шәһәрендә химия комбинаты төзелешендә үткәрә һәм шул вакытта чын-чынлап әдәбият дөньясына тартыла. Эштән һәм спорт күнегүләреннән бушаган арада китап уку белән мавыга. Нәтиҗәдә, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Студент елларында матур әдәбиятның серләрен ачуга, аны фәнни нигездә бәяләүгә омтылыш бигрәк тә XIX гасыр рус әдәбияты, аеруча Ф. Достоевский, Л. Толстой, М. Лермонтов әсәрләре белән танышкач көчәйде, дип искә ала ул бер әңгәмәдә [Закирҗанов, 2024, б. 17]. Ә инде Р. Сверигин, Ф. Хатипов, Ф. Галимуллин, М. Җәләлиева кебек укытучы-галимнәрдән белем алу, әдәбиятның тирән тамырларына, үсеш-үзгәрешенә һәм чор әдәби процессы үзенчәлекләренә төшенү аларны тагы да тирәнрәк өйрәнү омтылышы тудыра.

Ә.М. Закирҗанов 1983–1995 елларда Мамадыш районы Урта Кирмән һәм Уразбахты мәктәпләрендә, Казандагы 10 нчы интернат-мәктәптә (аннары 2 нче номерлы татар гимназиясе итеп үзгәртелә), Милли мәктәпләр институтының Казан филиалында эшли. Бу елларда ул татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерү, дәресләрнең нәтиҗәлелеген күтәрү юлларын, алым-чараларын фәнни һәм гамәли планда өйрәнә башлый. 1989–1993 елларда Мәскәүдә Милли мәктәпләр институтында аспирантурада укый һәм «Татар мәктәпләренең өлкән сыйныфларында драма әсәрләрен өйрәнү» дигән темага кандидатлык диссертациясе (җитәкчесе С.К. Бирюкова) яклый.

1995 елда Ә.М. Закирҗанов Казан дәүләт университетының (2010 елдан Казан (Идел Буе) федераль университеты) татар әдәбияты кафедрасына эшкә килә һәм өлкән укытучы, доцент, профессор, кафедра мөдире вазифаларын башкара. Әлеге чорда ул баш-аягы белән уку-укыту һәм фән дөньясына чума. Үз эшенә гаять җаваплы каравы, яңалыкка омтылуы, ярдәмчеллеге белән тиз арада хезмәттәшләре арасында үз урынын таба, аларның хөрмәтен казана. Студентлар аны үз эшенең остасы булуы, мәгълүматлы һәм кызыклы лекцияләре өчен ярата. Ә инде тәрбия һәм социаль мәсьәләләр буенча декан урынбасары булып эшләгән елларда оста оештыручы, ак-

тив җәмәгать эшлеклесе булып таныла. Студентларны тулай торакка урнаштыру, яшәү шартларын яхшырту буенча күпләргә ярдәм итә. «Беренче курстагылар көне», «Студентлар язы», «Ягымлы яз» кебек фестиваль-бәйрәмнәр студентларның зур активлыгы һәм җитди әзерлек белән үтә. Ә.М. Закирҗанов әлеге һәм башка мәдәни чараларда яшьләрнең киңәшчесе һәм ярдәмчесе булып тора. Бигрәк тә «Студентлар язы»ннан соң, студентлар чыгышына бәйле бәяләмә-мөнәсәбәтен чагылдырган язмалары урынлы хуплавы, үз итеп тәнкыйтьләве белән зур кызыксыну уята.

2017 елда ул, укытучыларны һәм студентларны аптыраышта калдырып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына китә һәм әдәбият белеме бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Әлфәт Мәгъсүмҗан улы монда да, җиң сызганып, фәнни һәм оештыру эшенә тотына: «Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгын (2014–2021) язу эшенә фәнни көчләрне туплау; татар классикларыннан Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, төрки әдәбиятларның танылган вәкилләре Ч. Айтматов, А. Кунанбаев, М. Җомабаев, Мәхтүмколый һ. б. юбилейлары уңаеннан халыкара фәнни конференцияләр, әдәбият фәненең актуаль мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәлләр, семинарлар кебек күп вакыт һәм көч сорый торган һәр эшне оештыручылардан булып тора.

Ә.М. Закирҗановның күпкырлы фәнни эшчәнлегенең башлангычы татар әдәбиятын мәктәптә укытуның методологиясен һәм методларын өйрәнү белән бәйле. «Татар мәктәпләренең өлкән сыйныфларында драма әсәрләрен өйрәнү» дип аталган кандидатлык диссертациясендә әдәбият дәресләрен оештыруның төп принципларын, әдәбиятны сүз сәнгате буларак һәм милли үзенчәлекләрне ачуга бәйле өйрәнү кирәклеген билгели. Үзенең мәктәптәге эш тәҗрибәсенә таянып, күзәтү төсендәге һәм аерым әдип иҗатын өйрәнү дәресләрен үткәрүнең фәнни-теоретик нигезләрен тикшерә. Нәтиҗәлелекне үстерүгә, укучыларны актив эшчәнлеккә тартуга йөз тоткан укыту методларын, алым-чараларны файдалану мәктәп программасындагы драма әсәрләрен өйрәнүгә бәйле аңлатыла. Яшь галимнең бу өлкәдәге эзләнүләре 5, 7, 9 һәм 11 сыйныфлар өчен «Татар әдәбияты» (1996–2010, 2016–2023, автордашлыкта) дәреслекләрендә; «11 сыйныфта татар әдәбиятын укыту» (2001) һәм «9 сыйныфта татар әдәбиятын укыту» (2016, автордашлыкта) методик ярдәмлекләрендә, шулай ук «Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре» (1997), «Сыйныфтан тыш уку дәресләре» (2002); «Татар әдәбияты: теория, тарих» (2004, 2006, автордашлыкта), «Татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләнәбез» (2023, автордашлыкта) кебек гомуми белем бирү мәктәпләре өчен чыгарылган методик хезмәтләрдә тулы чагылыш таба. Аның фәнни һәм методик характердагы фикерләре югары уку йортлары өчен эшләнгән «Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» (2007, автордашлыкта), «Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре» (2010) хезмәтләрендә урын ала. Аларның төп үзенчәлеге һәм фәнни яңалыгы әдипләр иҗатын, аерым әсәрләрне

һәртөрле идеологик чикләүләрдән арындырып өйрәнү, гамәли эшчәнлеккә йөз тоту, укытуда татар методистлары тәҗрибәсеннән һәм рус, башка халыклар әдәбиятын укытудагы казанышлардан иҗади файдалану белән аңлатыла.

Студент елларыннан ук әдәби тәнкыйть белән кызыксыну Ә.М. Закирҗановны әдәбият белеме фәненә, аның төрле тармакларын максатчан тикшерүгә китерә. Галимнең бу юнәлештәге эзләнүләре «Яңарыш юлыннан» (2008) исемле монографиясендә урын ала. Казан дәүләт университетында үткәрелгән «Иң яхшы фәнни хезмәт» конкурсында призлы урынны алган китапта шул чор татар әдәбият белеменең хәл-торышы, аеруча әдәбият тарихын яңача өйрәнүнең теоретик җирлеге, төп принциплары өйрәнелә. Хезмәттә шулай ук әдәби процессны ачуда нигез булган тәнкыйтьнең торышы, бурычвазифалары ачыклана, әйдәп баручы тәнкыйтьчеләрнең төп хезмәтләре тикшереп бәяләнә. Әлеге өлкәдәге эзләнүләрен дәвам итеп, галим татар әдәбияты фәненең методологик һәм фәнни-теоретик нигезләрен тикшерүгә алына. Рус телендә дөнья күргән «Хәзерге татар әдәбият белеменең төп юнәлешләре» (2011) монографиясендә аның концептуаль нигезе болай билгеләнә: «Әдәбият теориясендәге табыш-нәтиҗәләрне, күпгасырлык әдәбият тарихына заман биеклегеннән чыгып бирелгән караш-мөнәсәбәтләрне һәм әдәби тәнкыйтьтә барган эзләнүләрне бәяләү, иҗтимагый аңның бер формасы булган сүз сәнгатенең җәмгыятьтә тоткан урынын, әдәби-эстетик һәм әхлакый-фәлсәфи вазифаларын тулырак аңлауга да җирлек әзерли» [Закирзянов, 2011, с. 4]. Галимнең әлеге хезмәте 2012 елда якланган «Хәзерге татар әдәбият белеме: традицияләр һәм яңа тенденцияләр» дип аталган докторлык диссертациясенең нигезендә ята. Аның фәнни яңалыгы татар әдәбият белемендә галим-белгечләрнең күпсанлы монографияләренә, китапларына, мәкаләләренә традицияләр һәм яңа тенденцияләр контекстында һәм урта гасырлардан алып хәзергегә кадәрге әдәби процессның теоретик һәм методологик мәсьәләләренә бәйле рәвештә тирән шәрехләүле анализ ясалган, системалаштырылган беренче бөтенлекле тикшеренү булуы белән аңлатыла.

XXI гасыр башында татар әдәбият фәне төрле юнәлештә җитди эзләнүләр алып бара. Әдәбият теориясенә нисбәтле фәнни юнәлешләр, агымнар-мәктәпләр үсеше, аерым жанрлар табигате, аларның эволюциясе, шулай ук поэтикасына караган мәсьәләләр Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов, А. Шәмсутова, Л. Ибраһимова, А. Хәбибуллина һ. б. тарафыннан тикшерелсә, әдәбият тарихының төрле чорлардагы үсеш-үзгәреше мәсьәләләре Д. Заһидуллина, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Н. Хисамов, Ф. Галимуллин, Р. Сарчин, Н. Йосыпова, А. Хасавнех, А. Шәрипова, Л. Надыршина һ. б. хезмәтләрендә диахрон һәм синхрон яссылыкта бәяләнә. Ә инде әдәби тәнкыйть өлкәсендә Т. Галиуллин, Ф. Галимуллин, Р. Сверигин, Д. Заһидуллина, Р. Рахмани, Р. Рахман, Н. Йосыпова, Л. Минһаҗева, Г. Гайнуллина, Л. Галит-

зуллина һ. б. язмалары дөнья күрә. Ә.М. Закирҗанов, төрле тармактагы күпсанлы хезмәтләрне өйрәнеп, табыш-яңалыкларын билгели, традицияләр дәвамчанлыгын, үсеш-үзгәреш тенденцияләрен ача. Алдагы тикшеренүләренең дәвамы буларак яңа хезмәтләргә нисбәтле нәтиҗә-фикерләре татар һәм рус телләрендәге китапларында чагылыш таба: «Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре» [Закирҗанов, 2018] һәм «Современное татарское литературоведение: традиции, закономерности и новые поиски» [Закирзянов, 2019].

Әдәбият фәненең бер тармагы булган әдәби тәнкыйть Ә.М. Закирҗанов тикшеренүләрендә һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Бу тармакка караган язмалары даими рәвештә «Казан утлары», «Мәйдан», «Идел» журналларында, «Мәдәни җомга» газетасында чыгып килә. Берничә ел «Казан утлары» журналында «Әдәби тәнкыйть» бүлеген җитәкләве, шулай ук Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть секциясенә җитәкчелек итүе дә бу мәсьәләне күз уңында тотуга уңай йогынты ясый. Әлфәт Мәгъсүмҗан улының татар әдәби тәнкыйтенең торышы турында язучыларның әдәби ел йомгаклары, корылтай утырышларындагы чыгыш-докладлары да күтәп алына. Әлеге эзләнүләр нәтиҗәсе буларак «Заман белән бергә» (2004), «Рухи таяныч» (2011), «Иҗат тылсымы» (2022) кебек әдәби тәнкыйть җыентыклары басылып чыга. Әлеге китаплар XXI гасыр башы әдәби процессының елъязмасы кебек кабул ителә. Дөрес, автор татар әдәбиятының XIX һәм XX гасырлары әдәби хәрәкәтен дә иңләп ала. Г. Кандалый, К. Насыйри, Г. Сәмитова, М. Акмулла, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, М. Фәйзи, К. Тинчурин, М. Җәлил, Т. Гыйззәт, Г. Афзал кебек классиклар, беренче чиратта, рухи иҗат мирасы белән кадерле булса, икенчедән, автор аларны дөнья әдәбиятының бер өлеше буларак татар сүз сәнгатенең үсеп китүенә зур өлеш керткән язучылар буларак бәяли. Шуның белән бергә, әлеге җыентыкларда җанлы әдәби процесс мәсьәләләре үзәк урынны алып тора. «Заман белән бергә», «Хәзерге татар драматургиясендә Г. Камал традицияләре», «Сәхнә әдәбиятында – замандаш», «XX гасыр ахырында татар драматургиясе», «XXI гасыр башы драматургиясе» дип аталган күзәтү мәкаләләрендә традицияләр дәвамчанлыгы белән бергә, әлеге чорлар әдәбиятының социаль-мәдәни җирлеге, әдипләрнең сәнгати эзләнүләрендә чор рухының классик һәм классик булмаган дөнья сурәтләре тикшереп бәяләнә [Закирҗанов, 2004, б. 16–45, 81–92; Закирҗанов, 2011, б. 25–35; Закирҗанов, 2022, б. 48–86, 87–122]. Сыйфат үзгәрешләренең сәбәп-шартларын, төп тенденцияләрен һәм киләчәктә үсеш юлларын фаразлау күзәтү мәкаләләренең тагын бер үзенчәлеге булып тора.

Ә.М. Закирҗановның фәнни тикшеренүләрендә татар әдәбиятының XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр башындагы үсешен әдәби-эстетик планда өйрәнү мөһим урын били. Аларның бер өлеше сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның 4, 6, 7, 8 томнарында

монографик мәкаләләр буларак урын ала. Татар драматургиясенең төрле чорларын үз эченә алган күзәтү язмалары, әдәбият белеме һәм тәнкыйтьнең үсеш баскычларын һәм үзенчәлекләрен билгеләү, шулай ук Т. Миңнуллин һәм Р. Мөхәммәдиев (автордашлыкта) иҗатлары буенча мәкаләләре фәнни-теоретик нигезе, фактларга байлыгы, әдәби әсәрләрне, хезмәтләрне бәяләү методикасы һәм уңышлы гомумиләштерүләре белән аерылып тора. Ә инде Ф.И. Габидуллина белән берлектә чыгарылган «Татар прозасында әдәби-эстетик эзләнүләр (XX гасырның икенче яртысы)» монографиясендә XX гасырның икенче яртысы татар прозасы үсешендәге төп тенденцияләр, тема-проблемалар төрлелеге, әдәби-эстетик эзләнүләр тикшерелә. Хезмәттә төп урынны әлеге төргә караган сәнгати табышларны билгеләгән язучыларның әсәрләренә бәяләмә алып тора. Шулай ук традицияләр дәвамчанлыгы аша җитди яңачалыкка килү юллары, сурәтләүдәге табышлары, рухи тормышыбыздагы урыннары билгеләнә [Закирҗанов, 2020].

Фән дөньясына беренче адымнарын драма әсәрләрен мәктәптә өйрәнү буенча ясаган Әлфәт Мәгъсүмҗан улы алдагы елларда да сәхнә әдәбиятын даими игътибар үзәгендә тота. Татар драматургиясе классикларын һәм замандаш әдипләр иҗатын системалы тикшерү, бу төрнең үсеш закончалыкларын тема-мотивлар төрлелеге белән бергә, жанр һәм жанр формалары өлкәсендәге эзләнүләрне ачыклау мәсьәләләренә багышланган дистәләрчә мәкаләләре журналларда, конференция җыентыкларында басылып чыга. Югарыда аталган җыентыкларда да Г. Исхакый, Г. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Т. Гыйззәт кебек классиклар янәшәсендә замандашларыбыз Ф. Садриев, Р. Хәмит, Ю. Сафиуллин, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, З. Хәким, М. Гыйләҗев, Г. Каюмов, Аманулла, Д. Салихов, Р. Зәйдулла, Р. Сәгъди иҗатларына багышланган мәкаләләр урын алган. Аларда әдипнең үзенә хас сурәтле дөньясын ачу, әсәрләренең тел-стилен, поэтик үзенчәлекләрен билгеләү үзәктә тора. Галим һәр драматург иҗатын шәхесе белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүне максат итә. Шуңа да язмаларда язучының сәнгати фикерләү үзенчәлеге әсәрнең язылу тарихы, герой концепциясе, театр сәхнәсендә куелышы кебек мәсьәләләр белән үрелеп бара. Болар барысы да әдип иҗаты турында бөтенлекле күзаллау булдыруга хезмәт итә.

Ә.М. Закирҗановның фәнни эзләнүләрендә чорыбызның танылган драматургы Т. Миңнуллин иҗаты аерым урын тота. Драматургның аерым әсәрләре, аларның сәхнә тарихы турында язмалары даими чыгып килә [Закирҗанов, 2019; Закирҗанов, 2020; Закирзянов, 2020; Zakirzyanov, 2016]. Галимнең әлеге тикшеренүләре нәтиҗәсе буларак «Туфан Миңнуллин драматургиясе» (2022) дип аталган монографиясе дөнья күрә. Т. Миңнуллин драматургиясен XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр башы сәхнә әдәбияты үзенчәлекләренә нисбәтле тикшереп бәяләүне максат иткән хезмәттә «драматург иҗатының төп этапларын аерып чыгару, аларга хас сыйфат үзгәрешләрен билгеләү

өчен, сәнгати үзенчәлекләр аеруча тулы чагылган пьесаларына бәя» [Закирҗанов, 2022, б. 23] бирелә һәм эзлекле рәвештә әсәрләрендәге тема-проблематика төрлелеге, жанр формалары байлыгы, бу өлкәдәге табышлары, сюжет-конфликт кору остасы булуы, үз йөзләре белән аерылып торган геройлары, әдип яклаган фикерләрне укучыга җиткерү юллары, заман рухын чагылдыруга хезмәт иткән бай алым-чаралар, гомумән, сәнгати фикерләү үзенчәлеге ачыклана. Гомумән, чорыбызның мәшһүр драматургы, фикер иясе тормышы, иҗаты турында бөтенлекле күзаллау булдырылып, әдәбиятыбыз тарихындагы урынын билгеләү омтылышы ясалган хезмәт аерым әдип иҗатын монографик тикшерүнең уңышлы бер үрнәге булып тора [Габидуллина, 2023].

Сәхнә әдәбияты мәсьәләләрен эзлекле тикшерү Ә.М. Закирҗановны театр сәнгате белән кызыксынуга китерә. Бу аңлашыла да, чөнки драма әсәре бөтен тулылыгында бары сәхнәдә генә ачыла ала. Шул ук вакытта спектакль күмәк иҗат җимеше булып тора. Драматургның фикерләре, ул яклаган идея режиссёр күзаллавында һәм артистлар уены аша тамашачыга җиткерелә. Шуңа пьесага кертелгән билгеле бер үзгәрешләр, автор карашлары белән режиссёр концепциясенең туры килү-килмәве һәрвакыт бәхәсләр уята. Әлфәт Мәгъсүмҗан улының газета-журнал битләрендә урын алган, бигрәк тә «Театр – серле дөнья» (2023) китабында туплап бирелгән күпсанлы рецензияләре соңгы елларда татар театр сәхнәләрендә куелган спектакльләргә үзенчәлекле бәяләмәләре, төрле яссылыктагы мәсьәләләрне кыю күтәрүе белән кызыксыну уята. «Халыкның рухи ихтыяҗына җавап биреп, матурлыкны, изгелекне, әдәп-әхлакны яклауга һәм саклауга хезмәт итүче» [Закирҗанов, 2023, б. 3] театр татар милли рухын тамашачыга җиткерүдә гаҗәеп зур роль уйный. Ул бүген чын мәгънәсендә милләт сагында тора. Шуңа да театр репертуарындагы пьесаларның сыйфаты, коллективның максатчан эшчәнлегенең һәрдаим игътибар үзәгендә булуы – ул заман таләбе. Ә.М. Закирҗанов язмаларын әлеге фикер иңләп үтә. Шуңа да аларга драматурглар һәм режиссёрлар гына түгел, театр сөючеләрнең дә мөрәҗәгать итүенә шикләнмәскә мөмкин.

Ә.М. Закирҗанов бүген дә актив хезмәттә булып, фәнни тикшеренүләрен дәвам итә. Үзенең хезмәттәшләре белән бергә, татар әдәбияты тарихының, теориясенең, тәнкыйтенең актуаль мәсьәләләре буенча халыкара, бөтенроссия, республика фәнни конференцияләрендә доклад белән чыгышлар ясый, рухи байлыкны киң җәмәгатьчелеккә җиткерү буенча яңадан-яңа проектларда катнаша, мәктәпләрдә, уку йортларында, китапханәләрдә очрашуларда уй-фикерләре, табышнәтиҗәләре белән уртаклаша.

**Әдәбият**

*Габидуллина Ф.И.* Әдәбият фәненә җитди өлеш (Ә.М. Закирҗановның «Туфан Миңнуллин драматургиясе» китабына бәяләмә) // Фәнни Татарстан. 2023. № 2. Б. 156–163.

*Закирҗанов Ә.М.* Китап уку – ул... // Сөембикә. 2024. № 8. Б. 17.

*Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.

*Закирҗанов Ә.М.* Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре. Казан: ТӘһСИ, 2018. 352 б.

*Закирзянов А.М.* Современное татарское литературоведение: традиции, закономерности и новые поиски. Казан: ИЯЛИ, 2019. 372 с.

*Закирҗанов Ә.М.* Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. 175 б.

*Закирҗанов Ә.М.* Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит.нәшр., 2011. 287 б.

*Закирҗанов Ә.М.* Иҗат тылсымы: әдәби портретлар, күзәтү мәкаләләре, рецензияләр. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2022. 416 б.

*Закирҗанов Ә.М.* Татар прозасында әдәби-эстетик эзләнүләр (XX гасырның икенче яртысы) / Ә.М. Закирҗанов, Ф.И. Габидуллина. Казан: Школа, 2020. 168 б.

*Закирҗанов Ә.М.* Туфан Миңнуллин драматургиясе: монография. Казан: ТӘһСИ, 2022. 252 б.

*Закирҗанов Ә.М.* Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында әдәби-эстетик эзләнүләр // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 57–64.

*Закирҗанов Ә.М.* Җан иреге // Казан утлары. 2020. № 8. Б. 67–69.

*Закирзянов А.М.* Трагикомедия Т. Миннуллина «Обет» на театральной сцене // Современная наука: актуальные проблемы теории и практики. Серия «Познание». № 10 (октябрь). 2020. С. 11–14.

*Закирҗанов Ә.М.* Театр – серле дөнья: әңгәмәләр, очерклар, бәяләмәләр. Казан: Рухият, 2023. 352 б.

*Zakirzyanov A.M., Ghilazov T.Sh.* Tufan Minullin drama: the synthes is of eastern and western traditions // Man in india, 96 (7), 2016: 2357–2365.

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел Буе) федераль университетының Алабуга институты доценты*

УДК 908

***Гали Рәхим***

## ӘШ-ШӘРКЫЯТЬ

В публикации представлена статья учёного Гали Рахима (1892–1943) «Аш-шаркиййат», посвящённая изданию сорок третьей книги серии «Труды по востоковедению». Серия издавалась в Москве Лазаревским институтом. Статья Г. Рахима была опубликована в общественно-политической газете «Ил» от 12 декабря 1914 года. В эти годы он учился в Коммерческом институте в Москве, параллельно изучал литературу и историю Запада и Востока. В газете он регулярно публикует статьи о событиях в Москве, о литературных вечерах, организованных татарами и для татар. В статье «Аш-шаркиййат» Г. Рахим пишет не только о переводах, но и дает краткую информацию об исследованиях русских и западных ученых, научных журналах, изучающих татарскую историю, культуру, в особенности литературное наследие. Целью этого сборника, изданного на русском языке, по мнению автора статьи, является ознакомление читателей с художественной литературой народов Востока посредством переводов. Из пятисот страниц данной книги, сорок посвящены творчествам Гаяза Исхаки и Габдуллы Тукая.

**Ключевые слова:** Гали Рахим, татарская литература, периодика, перевод, Гаяз Исхаки, Габдулла Тукай.

The publication presents an article by the scholar Gali Rahim (1892–1943) “Ash-sharqiyat”, dedicated to the publication of the forty-third book of the series “Works on Oriental Studies”. The series was published in Moscow by the Lazarevsky Institute. The article by G. Rahim was published in the socio-political newspaper “Il” on December 12, 1914. During these years, he studied at the Commercial Institute in Moscow and simultaneously studied the literature and history of the West and the East. In the newspaper he regularly published articles about events in Moscow, about literary evenings organized by Tatars and for Tatars. In the article “Ash-sharqiyat” G. Rahim writes not only about translations but also gives brief information about the research of Russian and Western scientists, scientific journals studying Tatar history, culture and especially literary heritage. The purpose of this collection published in Russian according to the author of the article is to familiarize readers with the fiction of the peoples of the East through translations. Of the five hundred pages of this book forty are devoted to the works of Gayaz Iskhaki and Gabdulla Tukay.

**Key words:** Gali Rahim, Tatar literature, periodicals, translation, Gayaz Iskhaki, Gabdulla Tukay.

*Татар әдәбияты, фәне мәйданында тирән эз калдырган, шул ук вакытта гаепсезгә рәнҗетелгән талантлы шәхесләребезнең иҗатын танытуга Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты зур өлеш кертә. Шуларның берсе – Гали Рәхимнең (1892–1943).*

*Мәсәлән, Язма мирас үзәге тарафыннан әзерләнә торган «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясе – шул эшчәнлекнең бер дәлиле. Әлеге сериянең 9 нчы чыгарылышында Гали Рәхимнең фәнни, әдәби-публицистик эшчәнлегенә, 15 һәм 16 нчы саннарында – Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин тарафыннан әзерләнгән һәм 1922–1924 елларда 3 том булып нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенә урын бирелә.*

*Журналыбызның бу санында исә аның бүгенге укучыга таныш булмаган «Әш-шәркыять» исемле мәкаләсе тәкъдим ителә.*

*Гали Рәхимнең «Әш-шәркыять» мәкаләсе «Шәрыкны тану юлындагы хезмәтләр» сериясенең кырык өченче китабы басылып чыгу уңаеннан язылган. Билгеле булганча, әлеге серия Мәскәүдәге Лазарев институты тарафыннан нәшер ителгән. Рус телендә басылган бу мәҗмуганың максаты – тәрҗемәләр аркылы Шәрык халыкларының матур әдәбияты белән таныштыру. Мәкалә иҗтимагый-сәяси «Ил» газетасының 1914 елгы 12 декабрь санында басыла. Гали Рәхим бу елларда Мәскәүдәге сәүдә (коммерция) институтында укый, параллель рәвештә әдәбият, тарих белән дә кызыксына. Мәскәү шәһәрендә татарлар белән бәйле вакыйгалар, әдәби кичәләр хакында газета битләрендә даими рәвештә мәкаләләрен бастырып килә. «Әш-шәркыять» дигән мәкаләдә ул китапта тәкъдим ителгән тәрҗемәләр турында гына фикер йөртеп калмый, шулай ук татар тарихын, мәдәниятен, аеруча әдәби мирасын өйрәнүче рус, Көнбатыш галимнәренең тикшеренүләре, фәнни журналлар турында да кыскача белешмә бирә.*

*Китапта Гаяз Исхакый белән Габдулла Тукай иҗатына зур урын бирелгән. Автор фикеренчә, Г. Исхакый әсәрләренең тәрҗемәләре һәркайсы бик матур һәм уңышлы чыккан, әмма Г. Тукай шигырьләренең тәрҗемәләре «бик килешсез һәм көлке күренәләр. <...> Шигырьне хәрфия тәрҗемә (хәрефкә хәреф күчерү) аркылы шигырь белән язарга куәте җитә торган икенче бер кешедән тәрҗемә иттерү» күпкә отышлырак булган булыр иде.*

*Мәкалә гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, сүзлек һәм аңлатмалар белән тулыландырылып тәкъдим ителә.*

Шушы көннәрдә Мәскәүдәге Лазаревский институт тарафыннан нәшер ителә торган «Шәрыкны тану юлындагы хезмәтләр» сериясенең «Әш-шәркыять» исемендәге кырык өченче китабы басылып чыкты. Рус телендә нәшер ителгән бу мәҗмугадан максат: тәрҗемәләр аркылы Шәрык халыкларының нәфис әдәбияты белән таныштыру булырга кирәк. Мәҗмугада гарәп, фарсы, татар, азәрбайҗан, төрек, кыргыз, әрмән, гөрҗи, маҗар һәм яһүд әдипләреннән тәрҗемәләр бар. Күбрәк бу халыкларның соңгы заманда туган яңа әдәбиятлары алда тотылган. Бары гарәп һәм фарсы кыйсемендәге

нәмунәләр[1] генә бу ике халыкның төрки заманнарындагы иске әдәбиятыннан алынган.

Гомумән, бу – бик мөһим вә һәркем өчен күрелүе матлуб булган[2] бер китап[3]. Бу әсәрнең безнең өчен бигрәк тә мөһим булган ягы – яңа татар әдәбиятына хасланган кыйсемедер. Биш йөзгә якын битле бу китапның кырык бите Гаяз Исхакый белән Габдулла Тукаевка багышланган.

Мәҗмуганың башка урыннарын мөтәхассыйсларга[4] калдырып, бу мәкаләдә үзебезгә тәгъликъле булган[5] кыйсеменә генә бер күз йөртеп чыкмакчы булам.

Башта Лазаревский институт профессоры мөстәшрикъ В. Гордлевский[6] җәнаблары тарафыннан Гаяз әфәнде Исхакыйның тәрҗемәи хәле һәм әдәби хезмәте хакында кыскача гына мәгълүмат бирелеп, Гаяз әфәнденең әсәрләреннән өч нәмунә китерелгән. Беренчесе – «Мулла бабай»[7] романыннан шәкертләрнең хозурга чыгуларын тасвир ителгән урыны. Бу кыйтга Коммерческий институт студенты Шәйхулла әфәнде Алкинның[8] булышлыгы белән шул ук Гордлевский тарафыннан тәрҗемә кылынып, алдыннан иске татар мәдрәсәсе тормышы белән таныштыра торган бер мөкаддәмәдә дәрҗ ителгән[9].

Икенчесе – «Башкорт бәхете» хикәясенең[10] ахыры. Тәрҗемә кылучысы Акчурин[11].

Өченчесе – «Әлмансур»[12] исемле хикәя. Лазаревский институт студентларыннан кырымлы Сәедягкуб Сәедмәхмәд әфәнде тарафыннан тәрҗемә ителгән.

Тәрҗемәләр һәркайсы бик матур һәм муаффәкыятьле[13] чыккан.

Тукаев тәрҗемәләре алдыннан Акчурин әфәнде тарафыннан кыскача тәрҗемәи хәле белән әдәби хезмәте хакында бераз мәгълүмат дәрҗ ителгән.

---

[1] Нәмунәләргә – үрнәкләргә.

[2] Матлуб булган – көтелгән, теләнгән.

[3] Бәһасе өч сум. Түбәндәге адрес белән соратып алырга мөмкин: Москва, Склад изданий в Прав. Лазар. Институт. яки Москва, Книжн. магаз. «Нового врем». *(Г. Рәхим иск.)*

[4] Мөтәхассыйсларга – белгечләргә.

[5] Тәгъликлы булган – караган.

[6] В. Гордлевский – Владимир Александрович Гордлевский (1876–1956) шәркыятчы-тюрколог.

[7] «Мулла бабай» – Г. Исхакыйның 1913 елда басылган романы.

[8] Шәйхулла әфәнде Алкин – Алкин Шәйхулла Сигатулла улы (1893–1918 елдан соң) сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы.

[9] Мөкаддәмәдә дәрҗ ителгән – кереш сүздә аңлатылган.

[10] «Башкорт бәхете» хикәясе – Г. Исхакыйның 1912 елда басылган хикәясе.

[11] Акчурин – Акчурин Йосыф Хәсән улы (1876–1935), сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист.

[12] «Әлмансур» – Г. Исхакыйның 1906 елда басылган «Мансур» исемле хикәясе.

[13] Муаффәкыятьле – уңышлы.

Тукаев шигырьләреннән «Мәхәббәт», «Өзелгән өмид», «Шүрәле» Казан цензоры Ашмарин[1] тарафыннан, «Милли моңнар», «Бер татар хатыны авызыннан», «Бишек җыры» Сәедягкуб әфәнде тарафыннан, «Теләнче», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Мөбарәк тәсбих өзелде» Акчурин тарафыннан тәрҗемә ителгәннәр.

Бердән, Тукаев, тар мәгънәсе белән милли татар шагыйре булганга, икенчедән, хәрфия мәгънәсе сакланылып, нәсер белән тәрҗемә ителгәндә, гомумән, шигырь үзенең табигый матурлыгын югалтканга, бу тәрҗемәләрне Гаяз әфәндедән кылынган тәрҗемәләр шикелле үк шома һәм матур чыккан дип әйтеп булмый. Татар теленә генә хас җөмлә әйләнешләре, әдәби тәшбиһләр[2] Гаяз әфәнде әсәрләрендә дә, рус күз карашыннан торып караганда, ятрак тоелалар. Тукаевның исә, беренче фасыйләтләреннән булган өслүб[3] матурлыгы тәрҗемәләрдә бөтенләй югалган. Хәтта бәгъзы тәгъбирләр, безнең күк авыл әсәрләренең оригиналлары белән таныш булганнарга да, бәгъзан[4] бик килешсез һәм көлке күренәләр (мәсәлән, «Бишек җыры»[5] шигырендә ананың баласын топленое масло[6] дип атавы шикелле).

Габдулла Тукаев шигырьләре урынына Сәгыйть Рәмиевнең бәгъзы шигырьләре тәрҗемә ителгән булса, рус укучысына татар шигыре хакында күп мәртәбә яхшырак һәм йөрәккә ятышлырак тәэсир калдырыр иде дип уйланыла. Ләкин мәҗмуга нәшер итүчеләрнең төп мәкъсуды[7] хәзерге татар әдәбияты белән танышасы килгәннәргә, татарларның иң сөеп укый торган шагыйренең иң типичный әсәрләре һәм авыл әсәрләрендәге идеяләр белән таныштыру булганга, Тукаевны алда тотканнардыр. Шулай булса да, тәрҗемә итүчеләргә, илтифат беләнрәк сайлап, башка халыкларның күңелләренә дә тәэсир итәрлек әсәрләрне дә алырга кирәк иде. Тукаевның бит андый шигырьләре юк түгел. Шигырьләр шигырь белән тәрҗемә ителгән булсалар, тагы да яхшырак тәэсир калдырырлар иде күк тоела. Тәрҗемә кылучыларның үзләрендә шигырь куәте юк икән, хәрфия тәрҗемә[8] аркылы шигырь белән язарга куәте җитә торган икенче бер кешедән тәрҗемә иттерү мөмкин булган булыр иде.

Татар язучыларының әсәрләре русчага тәрҗемә ителү яңа бер эш түгел. Соңгы заманда руслар арасында гына түгел, башка бездән ерак булган, безнең хакта ишетмештән генә белә торган Европа халыклары арасында да (тәгъбир мөмкин булса) «татар ренессансы», татар халкының тәрәккый һәм мәдәният юлына аяк басуы, яңа

[1] Ашмарин – Ашмарин Николай Иванович (1870–1933), тел галиме, тюрколог.

[2] Тәшбиһләр – чагыштырулар.

[3] Өслүб – стиль.

[4] Бәгъзан – бары.

[5] «Арып йокла сары майдай» дигән сүзнең тәрҗемәсе. *(Г. Рәхим иск.)*

[6] *Кириллицада басылган.*

[7] Мәкъсуды – нияте, максаты.

[8] Хәрфия тәрҗемә – хәрефкә хәреф күчерү.

туып килә торган яшь татар әдәбияты белән танышуга һәвәс күреләбашлады.

Татарларның яңа баштан, яшь бер милләт булып, дөньяга тууларына иң элек Европаның дикъкатен җәлеп итүче – мәшһүр төрек мөхибе[1], мөтәвәффа[2] мажар мөстәшригы Вамбери[3] җәнапларыдыр. Ул – дөньядагы һәртөрле төрки халыкларда күреләбашлаган тәрәккый чаткыларын алкышлаучыларның беренчеседер. Аның җиңел кулыннан башлап, Русия татарларының арасында күреләбашлаган мәдәни хәрәкәткә башка Европа мөстәшрикълары да илтифатларын салдылар. Соңгы елларда Европаның иң зур мәдәни учаклары булган Англия, Франция, Германия һәм үзебезнең Русия матбугатында Русия татарларының әхваленә багышланган мәкаләләрне бик җыш[4] очратырга мөмкин иде. Сүземне куәтләү өчен түбәндәге мисалларны китерү җитә дип беләм.

Англиядә чыга торган «The Russian Review» (Русияне тикшерү) исемендәге журналның 1914 елда чыккан беренче санында «Русия мөселманнары» дигән зур гына бер мәкалә басылды. Вильямс әфәнде тарафыннан язылган бу мәкаләне укыганда, бер инглизнең татарлардагы мәдәни хәрәкәтләрнең иң нечкә мәсьәләләренә кадәр белүе хәйран калдыра. Вильямс әфәнде мәкаләсенең башында Европа мөәррихлары[5] арасында бик таралган бер фикерне рәдд итә[6]. Бу – рус халкының татарлар кулы астында торулары русларның тәрәккый итүләренә аркылы төште һәм мәдәнияттә европалылардан артка калуларына сәбәп булды, дигән фикер. Менә шушы фикернең ялгышлыгын, хәтта, киресенчә, татарлар белән катнашу русларның үзләренә аерым оригинальный бер мәдәният ясый алуларына турыдан-туры хезмәт итүен Вильямс әфәнде бик күп җитди тарихи дәлилләр белән исбат итә. Аннан соң татарларда яшь мәдәни кузгалышның тарихын яхшы ук тәфсилләп сөйли, ахырда татар әдбияты хакында да, озын гына туктап, мәгълүмат бирә. Татар әдәбияты турысында бераз хаталары күренсә дә, гомумән, бу мәкалә хәзерге татар тормышының агышыннан дөрест һәм тулы гына бер картина бирә[7]. Мәкаләсенең ахырында татар әдәбиятының нәмунәсе итеп, Тукаевның «Пар ат» шигыре инглизчәгә тәрҗемә ителеп, дәрҗ кылынган. Хәтта бик муаффәкыятьле тәрҗемә кылынган бу шигырьгә Лондонның көндәлек гәзитәләре дә игътибар иткәннәр, имеш.

---

[1] Мөхибе – якын дусты.

[2] Мөтәвәффа – үлгән, вафат булган.

[3] Вамбери – Вамбери Арминий Вамбери (1832–1913), шәркыятчы.

[4] Җыш – еш.

[5] Мөәррихлары – тарихчылары.

[6] Рәдд итә – кире кага.

[7] Бу мәкалә шушы көннәрдә татарчага тәрҗемә ителеп, «Ил» сәхифәләрендә басылачак. (*Г. Рәхим иск.)*

Германиядә Хартманн[1] исемле мөстәшрикъ тарафыннан язылган «Төркиядән гайре сәяси хатлар» исемле әсәрдә Гаяз әфәнде Исхакый хакында байтак мәгълүмат бирелгән иде. Шул ук Хартманның иштиракы белән[2] елда дүрт тапкыр чыга торган җитди бер дарелфөнүн[3] журналда һәрвакыт Русия мөселманнары хакында мәкаләләр булып тора.

Франциядә мөселман галәменә махсус «Revne des muselmans» исемле журналда[4] да җыш-җыш Русия татарларының әдәби вә мәдәни хәлләре турысында мәкаләләр дәрҗ ителәләр.

Үзебезнең Русиягә килсәк, Петроградта берничә елдан бирле рус мөстәшрикъләры тарафыннан «Ислам галәме»[5] исемле айлык журнал дәвам иттерелеп килә. Бу журналның иң күп кыйсеме Русия мөселманнарының тормышларына, аларның мәдәният юлында атлаган адымнарына багышланган була. Журнал укучыларын вакытлы татар матбугаты һәм анда кузгатыла торган мөһим мәсьәләләр белән дә таныштырып тора.

Башка (специальный булмаган) рус матбугатында да, хосусан калын журналларда, татар тормышына һәм татар әдәбиятына байтак урын бирелә. Мисаллар бик күп китерергә мөмкин:

«Журнал Министерства Народ[ного] Просвещения»[6]нең[7] 1905 елда чыккан тугызынчы санында Ашмарин тарафыннан «Казан татарларының хәзерге әдәбияты хакында берничә сүз» исемле мәкалә басылган иде[8].

«Современник»[9, 10] журналының 1911 елгы 4 нче санында «Нәҗип» имзасы белән «Русия татарларының уянуы һәм аларның әдәбияты» исемле бер мәкалә булды.

---

[1] Хартманн – Хартманн Мартин (1851–1918), немец гарәпчесе, ислам белгече. Сүз «Welt des Islams» («Мир ислама») (1912–1918) журналы хакында бара булса кирәк.

[2] Иштиракы белән – катнашлыгы.

[3] Дарелфөнүн – фәнни.

[4] «Revne des muselmans» исемле журналда – журнал исеменең дөрес язылышы: «Revue du monde musulman»(«Обзор мусульманского мира»). Журнал Франциядә 1906–1926 елларда нәшер ителгән.

[5] «Ислам галәме» исемле айлык журнал – «Мир ислама» –1912–1913 елларда С.-Петербургта исламияткә багышлап нәшер ителгән беренче махсус журнал.

[6] *Кириллицада бирелгән.*

[7]«Журнал Министерства Народ[ного] Просвещения» – 1834–1917 елларда Россия империясе Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан оештырылган һәм ай саен чыккан журнал.

[8] Бу мәкалә Зәки Вәлиди тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, китап шәкелендә басылды. (*Г. Рәхим иск.*)

[9] *Кириллицада бирелгән.*

[10] «Современник» – 1911–1915 елларда С.-Петербургта ай саен чыгып барган әдәби, сәяси, фәнни, тарихи һәм иҗтимагый сәяси эчтәлекле журнал.

«Русская мысль»[1, 2] журналының 1912 елгы саннарының берсендә шулай ук татарларның мәдәни хәрәкәте хакында бер мәкалә чыккан иде шикелле.

«Современник»[3]ның 1913 елгы 4 нче санында Гаяз әфәнденең «Шәкерт абый» исемле хикәясе тәрҗемә кылынып басылды[4].

«Заветы»[5] журналының 1914 елгы 6 нчы санында «Алдым-бирдем»нең русчага тәрҗемәсе дәрҗ ителде[6].

Шулай ук «Өч хатын берлә тормыш»ның[7] да тәрҗемә ителгәнлеге хакында 1912 елда рус гәзитәләрендә хәбәр булган иде. Кайда басылып чыкканлыгын белә алмадым.

Гаяз әфәнденең «Сөннәтче бабае» да тәрҗемә кылынган. Шушы арада Петроградта чыга торган «Ежемесячный журнал»[8]да басылачактыр[9].

Аннан башка дәхи[10] Гаяз әфәнденең «Мөгаллимә»се[11] белән моңарчы басылмаган «Отпавший»[12] исемле әсәренең шушы көндә русчага тәрҗемә кылынып ятканлыклары ишетелде.

Күренә ки, безнең мәдәният капкасыннан керүебез – инде вөҗүдкә[13] чыккан бер эш, моңар мең елгы мәдәниятле, ак сакаллы Европа милләтләре шәһадәт бирәләр. Шәһадәт бирү белән генә калмаенча, дустанә кочакларын җәеп, үзләренең иң яшь туганнарын, үги күрмәенчә, араларына алырга хазир торганлыкларын күрсәтәләр.

---

[1] *Кириллицада бирелгән.*

[2] «Русская мысль» – 1880–1918 елларда чыккан әдәби, сәяси журнал.

[3] *Кириллицада бирелгән.*

[4] «Современник»ның 1913 елгы 4 нче санында Гаяз әфәнденең «Шәкерт абый» исемле хикәясе тәрҗемә кылынып басылды. – Сүз Г. Исхакыйның Казанда 1912 елда басылган хикәясе хакында бара. Әлеге хикәя Р. Свердлова тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, «Современник» журналының 1913 елгы 4 нче санында басыла.

[5] *Кириллицада бирелгән.*

[6] «Заветы» журналының 1914 елгы 6 нчы санында «Алдым-бирдем»нең русчага тәрҗемәсе дәрҗ ителде. – Сүз Г. Исхакыйның Казанда 1907 елда басылган драма әсәре хакында бара. 1914 елда С.-Петербургта 1912–1914 елларда чыккан әдәби, сәяси «Заветы» журналының 6 нчы санында Р. Свердлова тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, «Брачный договор» дигән исем белән басыла.

[7] «Өч хатын белә тормыш» – Г. Исхакыйның Казанда 1900 елда басылган беренче драма әсәре. Драманың русчага тәрҗемә ителүе турында мәгълүмат юк.

[8] *Кириллицада бирелгән.*

[9] Гаяз әфәнденең «Сөннәтче бабае» да тәрҗемә кылынган. <...> «Ежемесячный журнал»да басылачактыр. – Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясе 1912 елда Казанда басыла. Рус теленә тәрҗемәсе 1914–1918 елларда С.-Петербургта чыккан айлык әдәбият, фән һәм иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен яктырткан «Ежемесячный журнал»ның 1916 елгы 3 нче (март), 4 нче (апрель) саннарында басылган.

[10] Дәхи – тагын.

[11] «Мөгаллимә» – Г. Исхакыйның 1914 елның августында С.-Петербургта басылган драмасы.

[12] «Отпавший» – сүз Г. Исхакыйның «Зөләйха» исемле драма әсәре хакында бара булса кирәк. Әсәр 1912 елда язылып бетсә дә, 1918 елда гына басылып чыга.

[13] Вөҗүдкә чыккан – бар булган.

Бу – әлбәттә, безнең өчен бик күңелле, күңелебезне күтәрә торган эш. Ләкин безгә шатлыгыбыздан исебез китеп, күзебезне ачып, туктап калырга ярамый. Һаман тырмашырга, көчебез җиткән кадәр алга үрмәләргә тиеш. Безгә мәдәни милләтләр игътибар итәләр икән, без үз тарафыбыздан мөмкин кадәр аларның өмидләрен бушка чыгармаска, чынлап та мәдәни бер милләт булып, шул мөхтәрәм шәехләр арасына керергә истихкаклы[1] икәнлегебезне исбат итәргә тырышырга кирәк. Безнең яңа туып килә торган әдәбиятымызга илтифат итәләр, кызыксынып, аны өйрәнергә тырышалар. Үз телләренә тәрҗемә итәләр икән, безгә инде әдәбиятымызны яңа юлга куярга тотынырга кирәк. Моңар чаклы әле безнең әдәбиятыбыз тар мәгънәсе белән милли иде. Анда кузгатылган мәсьәләләр үз йортыбызның бусагасыннан уза алмый, аның бирә алган тәэсираты да бик сай булып, үзебезнең, гомумән бик сай булган күңелләр безгә генә әсәр[2] итә ала иде.

Эш бу рәвешчә барып торса, башка милләтләр башта кызыксынып әдәбиятыбызга бер күз салырлар да, анда әдәбиятны бөтен дөньядагы мәдәни халыклар өчен уртак мал ясый торган гомуми инсаният гонсырларын күрмәгәч, туеп ташларлар, онытырлар. Әгәр дә без чынлап та үзебезне башка милләт рәтеннән куясыбыз килә икән, әдәбиятыбызның башка милләтләр тарафыннан укылуы безнең милли горурыбызны кытыклый икән, безгә хәзерге көннән башлап әдәбиятыбызны мәгънә ягыннан тирәнәйтергә, үзенең милли төсен югалтмастан, аңар гомуми инсаният элементлары кертә башларга вакыт.

Күз алдыбызда кечкенә генә нәрвәҗ[3] милләте. Бу халыкның бары үзенең әдәбияты аркасында гына Европаның күзенә чалынуы безнең күз алдыбызда гына дияргә ярый. Бу кечкенә милләт салкын шимальдә[4] ничә йөз еллардан бирле яшәгән, яшәгән. Һичберкем аны исенә китерергә дә уйламаган. Аны гүя ки гомуми шау-шу арасында онытканнар. Менә бер заман, XIX гасырның ахырына таба бу халык эченнән чиктән тыш истигъдадлы[5] берничә язучы чыга. Европа халыклары бу көтелмәгән эшкә аптырап, күзләрен ерак шимальгә юнәлтәләр. Ибсен[6], Бьернсон[7], Кнут Һамсуннарның[8] әсәрләре бөтен Европа телләренә тәрҗемә ителеп укыла башлый. Нәрвәҗ әдәбияты гомуми Европа әдәбияты эчендә гражданлык хакы гына алу түгел, аның иң югары баскычына менеп утыра.

---

[1] Истихкаклы – лаеклы.

[2] Әсәр – йогынты, тәэсир.

[3] Нәрвәҗ – Норвегия кешесе.

[4] Шимальдә – төньякта.

[5] Истигъдадлы – сәләтле.

[6] Ибсен – Генрик Ибсен (1828–1906) драматург, шагыйрь һәм публицист.

[7] Бьернсон – Бьернсон Бьернстьерне Мартиниус (1832–1910), шагыйрь, прозаик, драматург, Нобель премиясе лауреаты (1903).

[8] Кнут Һамсун – Кнут Гамсун (1859–1952) язучы, прозаик, драматург, шагыйрь.

Югарыда исемнәре саналган язучыларның әсәрләрен актарып карасак, аларның һәрберсе үзләренең милли, нәрвәҗ тормышын тасвир иткәнлекләрен, каһарманнарының һәрберсе нәрвәҗ исемнәре белән аталганлыкларын күрербез. Димәк, әдәбият тышкы яктан чыкылдаган милли төстә булган хәлдә, шуның белән бергә үк гомуми кешелек дөньясының башын уйларга мәҗбүр итә торган мәсьәләләрне кузгата ала, бөтендөнья халкы өчен уртак булган тойгы вә фикерләрне урталыкка сала ала икән. Шулай булгач, нигә безгә татар әдәбиятының да бервакытлар шулай югары ашачагын өмид итмәскә? Нәрвәҗ халкы арасында андый даһилар иттифакый[1] гына килеп чыкканнар дисезме? – Соң ни өчен татарлар хакында да шул ук сүзләрне әйтергә ярамый? Халкыбызның табигый истигъдадына минем ышанычым бик таза, мәдәниятнең нурлы юлы белән барган вакытта халкыбыз арасыннан һәрвакыт бик зур истигъдадлы кешеләр чыгып торачагына минем иманым камил! Бары тик өмид, сабыр һәм сәбатыбызны[2] югалтмыйк та, Аллага тапшырып, бил баглап, алга атлавыбызда дәвам итик.

*Басмага әзерләде:*
***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

---

[1] Иттифакый – очраклы.

[2] Сәбатыбызны – ныклыгыбызны.

# «ТАТАРСКИЙ КОСТЮМ. РОССИЙСКИЙ ЭТНОГРАФИЧЕСКИЙ МУЗЕЙ»
## альбом-каталогына рецензия

*Татарский костюм. Российский этнографический музей / Авторы текстов, авторы-составители: И.Л. Измайлов, Е.В. Колчина, Л.М. Мишуринская, Р.Р. Султанова, В.Г. Холодная. – Казань: АО «ИД «Казанская недвижимость», 2023. – 320 с., ил. (на тат., рус, англ. языках).*

Татарстан Республикасында милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы кысаларында татар, рус һәм инглиз телләрендә «Татарский костюм. Российский этнографический музей» альбом-каталогы дөнья күрде. Бу – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Россия этнография музееның Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә гамәлгә ашырылган уртак проекты. Проектның кураторы, басманың фәнни мөхәррире – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИнең Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова. Авторлары – Россия этнография музееның әйдәп баручы фәнни хезмәткәрләре – Е.В. Колчина, Л.И. Мишуринская, В.Г. Холодная, шулай ук Казан галимнәре – тарих фәннәре докторы И.Л. Измайлов, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова.

Россиянең иң эре этнография музеенда татарларның төрле этнотерриториаль төркемнәренә караган үзенчәлекле костюм коллекцияләре саклана, алар беренче тапкыр шушы альбом-каталогта күрсәтелә. Биредә тарихи костюм, коллекциянең формалашу тарихы һ. б. турында төрле һәм шактый күп мәгълүмат тупланган. Татар костюмы турында күренекле мәгърифәтче галимнәр Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри хезмәтләреннән алынган өземтәләр дә киң аудиториягә беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Костюмнарның, аларның элементларының күп кенә атамалары кулланыштан чыккан, шуңа күрә татар һәм рус телләрендәге терминнарның кыскача исемлеге бирелгән кушымтаны басманың казанышы дип санарга мөмкин.

Тулы тасвирламалы костюм комплекслары һәм аларның элементлары үрнәкләре халыкның таланты һәм югары сәнгати зәвыгы турында сөйли, күптөрлелек аша татар этносының бердәмлеге ассызыклана. Безнең алда – тукыма җитештерү осталыгын, бизәкләп эшләнгән баш киемнәрен һәм югары сәнгатьле зәркән эшләнмәләрне колачлаган үзенчәлекле халык иҗаты системасы.

Костюм, халыкның милли тәңгәллек маркеры буларак, мәдәниятне тулаем өйрәнүдә мөһим чыганак булып тора. Халыкның мәдәниятен һәм сәнгатен гомуми тарихи үсеш контекстыннан аерып карап булмый. Татарлар, күп тапкырлар күченеп йөрүләренә һәм яңа территорияләрне үзләштерүләренә карамастан, үзләренең иҗатын,

иҗади көчләрен саклый һәм үстерә алдылар, этнос буларак саклану гына түгел, күрше халыкларның мәдәниятенә, сәнгатенә дә зур йогынты ясадылар. Озын тарихи юлда күп нәрсәләр вакыт сынавын узды. Костюм сәнгатендә халыкның костюм комплексының образлы төзелешен аңлавы чагыла, ул заманалар узу белән шомарган, форма, традицияләрдә гәүдәләнеш тапкан, тулаем дөньяны аңлауда халык акылын туплаган.

Монументальлек һәм нәфислек, бөек һәм дәрәҗәле булу, гүзәллек һәм кызларга гына хас нәфислек – болар барысы да татар халык костюмында чагылыш таба. Хатын-кыз костюмына күпкатлылык, аерым кисәкләрдән оешу, төсләр полихромиясе хас. Вакыт белән сыналган бөтен нәрсә – тукымалар, материаллар, техник җитештерү алымнары, ә иң мөһиме – символик-шигъри башлангыч – шул образны тудыруга хезмәт итә. Монументальлек һәм тантаналылык костюмның детальләргә вакланмаган формаларын ассызыклый. Күлмәкнең ябык һәм төгәл формасын җилбәгәй җибәрелгән камзул бераз җанландырып җибәрә. Ювелир бизәнү әйберләре тукыма һәм материалларның ачык бизәкләрен ассызыклый һәм бер үк вакытта бераз йомшарта да. Аларның вазифасы бик катлаулы – татар хатын-кыз костюмы ансамблен композицион бербөтен итү. Йөзекләр, беләзекләр, бәйләвечләр, күкрәкчәләр, муенса, алкалар, чигә асылмалары үзенчәлекле семантик өчпочмак барлыкка китерәләр, ул исә эчке декоратив эшләнешкә һәм символик-магик эчтәлеккә ия барлык бизәнү әйберләрен югарыга – баш киеменә җыя. Зәркән бизәнү әйберләре хатын-кызның йөзен нәфис рамга алып, тулаем костюм ансамблен аның иң мөһим композицион ноктасына – баш киеменә алып чыга. Соңгысы костюм комплексының композицион-образлы йөкләнешен – архаик биек, яисә миниатюр мөгез калфакмы ул – үзенә туплый һәм ансамбльнең бөтен сәнгати корылышын төгәлләп куя. Татар костюмының әлеге һәм башка үзенчәлекләре авторларның мәкаләләрендә һәм җентекләп сайлап алынган төсле рәсемнәрдә чагылыш таба. Шул рәвешле милли кием сәнгате халык декоратив-гамәли иҗатының бербөтен системасы булып күзаллана.

Милли костюмны өйрәнү, үткәндәге тәҗрибәгә мөрәҗәгать итеп, ансамбль төзү сәнгатендәге принципларны, вакыт тарафыннан үзгәрешләр кертелүгә карамастан, мәдәният тарихы дәвамында аңа булган тотрыклы ихтыяҗны төшенергә мөмкинлек бирә. Костюм кешеләрнең сәнгати фикерләү дәрәҗәсен гәүдәләндерә, халык характерының иң ачык чагылышы булып тора.

Альбом авторлары иң бай милли мирасны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итәләр: күн эшкәртү, зәркәнчелек, чигү, сәйлән, алтын һәм көмеш җепләр белән асалап чигү, шулай ук бизәкләп туку кебек татар промыселлары һәм һөнәрләренең иң кыйммәтле һәм үзенчәлекле үрнәкләрен күрсәтәләр. Каталогта XIX гасырның икенче яртысына караган костюм комплекслары һәм аерым кием предметларының сурәтләреннән тыш, аларның кулланышта булу урыны һәм вакыты,

татарларның кайсы локаль төркеменә каравы, материалы, башкару техникасы, үлчәмнәре турында да мәгълүмат табарга мөмкин.

Халык костюмы – хәзерге заман костюмын тудыручыларның иҗатын туендыручы төп чыганакларның берсе. Безнең бурычыбыз – милли үзенчәлекне саклап калу, халык костюмын сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрү. Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ һәм Россия этнография музееның уртак проекты фәнни-тикшеренү, музей-методик, педагогик эшчәнлеккә бәяләп бетергесез өлеш кертә. Бу басманың рәссамнар, дизайнерлар, сәнгать белгечләре, Идел Буе халыкларының костюм комплекслары үсеше тарихы һәм иң элек татар костюмы белән кызыксынган һәр кеше өчен кыйммәте биниһая зур.

***Пудакова Ольга Владимировна,***
*Россия дизайнерлар берлеге, Сәнгать белгечләре ассоциациясе әгъзасы,*
*Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе,*
*«Исаакий соборы» дәүләт музей-һәйкәле белгече*
*(Санкт-Петербург)*

**2024 елның 1–4 октябрендә** Минск шәһәрендә уздырылган «Беларусь Республикасы энергетикасының тотрыклы үсеше: торышы һәм перспективалары» III Халыкара фәнни конференциясендә Рифкать Миңнеханов җитәкчелегендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе делегациясе катнашты. Галимнәр һәм тармак экспертлары энергетика системаларының яшәеше һәм үсешенең актуаль мәсьәләләре турында фикер алышты.

**2024 елның 8 октябрендә** Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә филология фәннәре докторы, профессор Наил Вәлиевнең «Борис Пастернак в Чистополе. 1941–1943. К истокам романа “Доктор Живаго”» китабы тәкъдим ителде. Монография рус шагыйре һәм язучысы Борис Пастернак тормышы һәм иҗатының Чистай чорына багышланган.

**2024 елның 9–11 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуга 85 ел тулуга багышланган «Россия халыкларының телләре, әдәбияты һәм мәдәнияте заманча академик фәндә» Халыкара фәнни форумы узды.

Чарада 200 дән артык галим катнашты. Алар арасында – Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Төмән, Казан, Чувашия, Марий Эл, Башкортстан, Удмуртия республикалары галимнәре.

Форумның беренче көнендә кунаклар Институтның соңгы биш елда ирешкән фәнни казанышлары күргәзмәсе белән таныштылар, тантаналы һәм пленар утырышта, секция эшләрендә катнаштылар.

**2024 елның 9–10 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Хәзерге дөньяда милли телләр һәм телара процесслар» фәнни-гамәли конференциясе узды. Секция утырышларында Азәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстан, Санкт-Петербург һәм Россиянең башка регионнарыннан килгән галимнәр глобальләшүче дөньяда милли телләр һәм телара процесслар; әдәби телләрне аларның тарихи үсеше контекстында өйрәнүгә заманча карашлар; ареаль лингвистиканың хәзерге тенденцияләре һәм үсеш перспективалары; теоретик һәм практик лексикография; цифрлы технологияләр; бердәм белем бирү киңлеген формалаштыру шартларында туган тел һәм әдәбият; XXI гасырның когнитив лингвистикасы һәм лингвокультурологиясе үсеше тенденцияләре турында сөйләштеләр.

**2024 елның 9–10 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Парадигмалар алмашыну шартларында татар фәне: теория, методология, практика» фәнни-гамәли семинары узды. Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан, Россиянең төрле шәһәрләреннән килгән галимнәр татар телен, әдәбиятын, тарихын өйрәнүнең бүгенге проблемалары, татар фәне һәм тюркологиянең XX–XXI гасырларда үсеш юнәлешләре турында фикер алыштылар. Семинар кысаларында Патрис Лумумба исемендәге Россия Халыклар дуслыгы университеты тарафыннан чыгарыла торган «Полилингвиальность и транскультурные практики»

журналының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 85 еллыгы уңаеннан әзерләнгән махсус номеры тәкъдим ителде.

**2024 елның 10 октябрендә** Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы бинасында «Милли тәңгәллекне саклап калу факторы буларак традицион мигъмарият» халыкара фәнни-гамәли семинары узды. Семинар эшендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре һәм аспирантлары, Казан архитектура-төзелеш университетының архитектура һәм дизайн институты, Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы, Казан халык һөнәрләре техникумы студентлары һәм педагоглары, Азәрбайҗан, Үзбәкстан һәм Россиянең төрле өлкәләреннән килгән белгечләр катнашты. Сәнгать белгечләре архитектура теориясе һәм тарихы, төрки, фин-угор, славян халыкларының милли-мәдәни мирасын саклау һәм интерпретацияләү мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

**2024 елның 9–11 октябрендә** «Татар гыйлеме» яшьләр фәнни мәктәбе оештырылды. Ул Урал-Идел Буе халыклары телләренең, әдәбиятларының, традицион мәдәниятләренең үзара бәйләнеше темасына багышланды. Мәктәп эше лекторийлар һәм методик дәресләр, түгәрәк өстәлләр форматында алып барылды һәм катнашучыларга сертификатлар бирү белән тәмамланды.

**2024 елның 11 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Халыкара Күзге фәнни мәктәп оештырылды. Галимнәр төрки телләр аспектында лингвокультурология мәсьәләләре буенча фикер алыштылар. Чараны оештыручылар – П.П. Семёнов – Тян-Шанский исемендәге Халыкара гуманитар университет (Санкт-Петербург) һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Филология фәннәре докторы, Халыкара гуманитар университет ректоры Марина Владимировна Пименова алып барган әлеге Мәктәп Россиядә быел 47 нче тапкыр үткәрелде.

**2024 елның 11 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов төрекмән классик әдәбиятына нигез салучы шагыйрь һәм фикер иясе Мәхтүмколый Фрагиның тууына 300 ел тулуга багышланган «Заманнар һәм цивилизацияләр бәйләнеше – тынычлык һәм үсеш нигезе» халыкара форумында катнашты һәм «Мәхтүмколый Фрагиның 300 еллыгына» юбилей медале белән бүләкләнде.

**2024 елның 17–18 октябрендә** Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Лилия Мөхәммәтҗанова Алматыда (Казакъстан) узган «Дөнья цивилизациясе контекстында төрки халыкларның рухи мирасы: “Алпамыш батыр” эпосы» Халыкара фәнни-теоретик конференция эшендә катнашты. Конференциядә Казакъстан, Үзбәкстан, Төркия, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Монголия һәм Россиядән (Казан, Уфа, Новосибирск) галимнәр катнашты. Конференция кысаларында «Алпамыш» дастанын төр-

ки халыкларның уртак мирасы буларак ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә тәкъдим итү мәсьәләсе күтәрелде.

**2024 елның 19–20 октябрендә** Кырым Республикасының Форос посёлогында «Кырым татарлары тарихының актуаль мәсьәләләре» дип исемләнгән III Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Чараның оештыручысы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты. Конференциядә Татарстан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Кырым Республикасы һәм Ростов-Доннан 80 эксперт, шулай ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Радик Салихов һәм Институт хезмәткәрләре катнашты.

Чыгыш ясаучылар Россия Федерациясе Президентының «Фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләрен һәм иң мөһим фәнни технологияләр исемлеген раслау турында»гы 2024 елның 18 июнендәге 529 номерлы указы үтәлеше контекстында гуманитар тикшеренүләрнең аеруча әһәмиятле булуын билгеләп үттеләр.

Пленар утырышта Кырым татарларының тарихы, шулай ук кырымтатар халкының этномәдәни һәм лингвистик мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

**2024 елның 22–24 октябрендә** Казанда БРИКС саммиты оештырылды. Уналтынчы БРИКС саммитында 35 илдән һәм алты халыкара оешмадан делегацияләр катнашты. Анда катнашучылар арасында БРИКС белән хезмәттәшлек итәргә теләгән дәүләтләрнең лидерлары бар иде. Шулай ук БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш та килде.

13 ил БРИКСның партнёры статусын алды: Төркия, Казакъстан, Үзбәкстан, Алжир, Беларусь, Боливия, Куба, Индонезия, Малайзия, Нигерия, Таиланд, Уганда һәм Вьетнам.

БРИКС илләре саммитның Казан декларациясен раcладылар, аны Берләшкән милләтләр оешмасында (БМО) уртак документ буларак таратачаклар. Декларация дөньядагы хәлләрнең торышына гомуми бәя бирүне үз эченә ала, шулай ук озак вакытлы перспективага хезмәттәшлек юнәлешләрен билгели.

**2024 елның 25 октябрендә** Казанда Казан (Идел Буе) федераль университеты базасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә оештырылган, Россиядә Гаилә елына багышланган «Заманча милли мәгариф: антропологик, дидактик, күпмәдәниятлелек аспектлары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды.

Экспертлар фән, мәктәпкәчә, мәктәп һәм югары белем бирүне үстерүнең актуаль проблемалары турында фикер алыштылар.

**2024 елның 28 октябрендә** Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре 5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбият укытучыларының республика семинары узды. «Туган (татар) теле һәм әдәбиятын укытуның актуаль мәсьәләләре» дип аталган бу чарада Чистай, Алексеевск, Әлки, Яңа Чишмә районнарының милли мәгариф буенча методистлары, татар

теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты.

**2024 елның 29 октябрендә** Казанда Евразия далалары археологиясенең VI халыкара конгрессы узды. Чарада дала Евразиясе халыкларының археологиясе һәм тарихы буенча 120 Россия һәм чит ил эксперты катнашты. Конгресска Азәрбайҗан, Болгария, Казакъстан, Кытай, Кыргызстан, Монголия, Румыния, Төркия, Үзбәкстан һәм Россиянең 23 төбәгеннән галимнәр җыелды.

**2024 елның 29–31 октябрендә** Казан (Идел Буе) федераль университетында V Казан халыкара лингвистик саммит узды. Чара кысаларында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында оештырылган «Хәзерге тел белеме таләпләре һәм юнәлешләре» дип аталган халыкара фәнни конференциядә 20 илдән килгән галим катнашты. Чара университетның 220 еллыгына һәм уку йортында татар теле һәм әдәбияты бүлеге оештырылуга 80 ел тулуга багышлап оештырылды.

**2024 елның 7 ноябрендә** Татарстан Республикасы Милли музеенда татар сәхнәсенең күренекле вәкилләренең берсе, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗановның тууына 90 ел тулуга багышланган «Марсель Сәлимҗанов: тылсымлы театр» күргәзмәсе ачылды. Ул Татарстан Республикасы Милли музее, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының уртак партнёрлык проекты кысасында оештырылды.

Күргәзмәдә 300 гә якын раритет тәкъдим ителде. Режиссёрның хатыны Гөлнара Сәлимҗанова күргәзмәгә гаилә архивыннан 68 әйбер, Г. Камал театры 50 дән артык экспонат (костюмнар, декорация эскизлары һәм легендар Зәңгәр шәл) бирде.

Күргәзмәнең төп өлеше Марсель Хәким улының һәм аның әти-әнисе – ТАССРның халык артистлары Хәким Сәлимҗанов һәм Галия Нигъмәтуллиналарның тормыш юллары һәм иҗатларына багышланган.

**2024 елның 7–9 ноябрендә** Казанда төрки телләрне компьютерда эшкәртү мәсьәләләренә багышланган «TurkLang – 2024» дип исемләнгән Халыкара конференция узды. Чараны оештыручылар – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты (Казакъстан), Истанбул техник университеты (Төркия), Казан (Идел Буе) федераль университеты, Казан дәүләт мәдәният институты, Россия ясалма интеллект ассоциациясе, IEEE Xplore цифрлы китапханәсе. Конференциянең генераль партнеры – Яндекс компаниясе.

Конференциянең максаты – төрки телләрне өйрәнү өлкәсендә фикер алышу һәм тәҗрибә уртаклашу өчен фәнни-оештыру пространствосы һәм технологик база булдыру.

Чарада Россия, Кытай, Япония, Германия, Көньяк Корея, Төркия һәм башка илләрдән 150дән артык белгеч катнашты. Конференциядә лингвистик кушымталар эшләү юнәлешендә яңа нәтиҗәләр тәкъдим ителде. Галимнәр ясалма интеллект куллану мәсьәләләре турында да фикер алыштылар.

**2024 елның 8–10 ноябрендә** «Татарча диктант» бөтендөнья мәгариф акциясе узды. Акциянең төп максаты – татар теленә һәм мәдәниятенә игътибарны җәлеп итү, бөтен дөньяда яшәүче татарларны берләштерү, тел белемен тикшерү, әдәби татар телен кулланучылар даирәсен киңәйтү һәм татар теленә мәхәббәт тәрбияләү. Быел «Татарча диктант» акциясе тугызынчы мәртәбә уздырылды.

**2024 елның 18 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында классик шагыйрь, журналист, меценат, җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев, 1859–1921) тууына 165 ел тулуга багышланган «Дәрдемәнд: шәхес, шагыйрь, фикер иясе» дип аталган Түгәрәк өстәл утырышы узды. Фикер алышуда «XX гасыр башы татар тарихи-иҗтимагый һәм мәдәни мохите контекстында Дәрдемәнд шәхесе һәм аның күпкырлы эшчәнлеге», «Дәрдемәнд – XX гасыр башы татар шигъриятендә яңа юл салучы», «Татар әдәбиятын, сәнгатен һәм журналистикасын үстерүдә Дәрдемәнднең роле һәм аның традицияләре», «Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлар» һ. б. мөһим мәсьәләләр күтәрелде.

**2024 елның 20–29 ноябрендә** Казанда Халыкара «Шәрык базары» төрки эстрада фестивале уздырылды. Ул быел өченче тапкыр оештырылды. Фестивальдә 30 илдән һәм 20 төбәктән илле мәдәният вәкиле катнашты.

Быелгы «Шәрык базары»ның тагын бер яңалыгы – беренче тапкыр «Көнчыгыш һәм Азия илләре белән мәдәни хезмәттәшлек: хәзерге заман торышы һәм перспективалары» дип аталган фәнни-гамәли конференция оештырылу. Чара 26 ноябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә узды.

**2024 елның 4–6 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының 30 еллык юбилеена багышланган Халыкара форум оештырыла. Форумның темасы – «Заманның инновацион яктылыгы контекстында региональ энциклопедистика». Форум кысаларында дөнья һәм Россиянең заманча милли һәм региональ энциклопедистикасы тарихы һәм үсешенә бәйле киң кырлы мәсьәләләр каралыр, «Заманча инновацион яктылыкта региональ энциклопедистика» темасына фәнни-теоретик конференция үткәрелер, «Яшь энциклопедист» конкурсына нәтиҗәләр ясалыр, «Муниципаль энциклопедияләр: методологик якын килү» дип аталган фәнни семинар уздырылыр дип көтелә. Чарада чит илләрдән, Россиянең күпләгән төбәгеннән белгечләр катнашачак.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2024. № 4

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 26.11.2024. Басылды: .11.2024.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият һәм типография адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал Татарстан, Башкортстан Республикаларында, Самара, Ульяновск,
Оренбург, Әстерхан, Төмән өлкәләрендә бушлай таратыла

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуга
85 ел тулуга багышланган «Россия халыкларының телләре, әдәбияты
һәм мәдәнияте заманча академик фәндә» Халыкара фәнни форумы.
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе. 2024 ел, 9 октябрь









Татарстан Республикасы
Фәннәр академиясе президенты
Рифкать Миңнехановка
«Мәхтүмколый Фрагиның
300 еллыгына» юбилей медален
тапшыру. Ашхабад. 2024 ел, 11 октябрь

## Ф. Джумаеваның «Ибн Фадлан “Язмалар”ындагы сюжетларның хәзерге заман Татарстан нәкышендә чагылышы» мәкаләсенә



*Баки Урманче.* Ибн Фадланның Болгарга килүе. Катыргы, темпера, 118×82,5. 1973



*Булат Гыйльванов.* Идел Болгарында ислам кабул итү. Кәгазь, акварель, 35×50. 2005.



*Рөстәм Хуҗин.* 922 елда болгарларның ислам динен кабул итүе. Киндер, майлы буяу. 2005.



*Фәрит Вәлиуллин.* Болгарларның исламны кабул итүе. Мозаикага эскиз. Катыргы, акрил буяу. 100×300



*Рушан Шәмсетдинов.* «Путешествие Ибн Фадлана» китабына иллюстрацияләр. Кәгазь, акварель, темпера. 1999.

## Н.М. Горюнованың «Лениногорск шәһәрендәге скульптуралар» мәкаләсенә



Мәдәният сарае бинасы. Лениногорск



«Аккош күле» фонтаны. Лениногорск

## М.М. Хәбетдинова, Ә.Р. Миндиәрованың «Татар драматургиясе һәм сәхнәсендә С. Гыйззәтуллина-Волжская образы» мәкаләсенә



Гөлҗамал – Асия Галиева, Татарстанның халык артисты



«Гөлҗамал» (реж.Ф. Бикчәнтәев). Г. Камал исемендәге ТДАТ. *Камал театры музее архивыннан*



«Яратып туялмадым» (реж. Р. Әюпов) Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры. *Рәмис Нәҗмиев фотосы*



«Гөлҗамал. Чакыру» (реж. Р. Гәрәев) Г. Камал исемендәге ТДАТ, «Шәрык клубы» интерактив мультимедиа комплексы. *Фаат Гарифуллин фотосы*

## З.М. Бруськоның «Киндер чәчсәң, күлмәк киярсең...: Татар халкының киндер эшкәртү өмәләрен фольклор яссылыгында тикшерү» мәкаләсенә





Киндердән сугылган сөлге

Киндер талку. 1950 еллар

## Л.Ш. Гарипова, Ә.К. Булатованың «Мордовия Республикасы татар авылларына фәнни сәфәр нәтиҗәләреннән» мәкаләсенә



ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Мордовия Республикасы Йенә авылы мәктәп музеенда



Сыркыды авылы. Һ.Такташ музее




«TurkLang – 2024» Халыкара конференциясендә катнашучылар

## Р.Г. Зәкиеваның «Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оешуга 30 ел» мәкаләсенә



Татар энциклопедик сүзлеген тәкъдим итү. Сулдан уңга: Казан шәһәре мэры К.Ш. Исхаков, ТР премьер-министры урынбасары И.К. Хәйруллин, ТР ФА президенты М.Х. Хәсәнов, ТР Президенты М.Ш. Шәймиев

## Яңа китаплар

